1960 елның 5 декабрендә тагы авария була, күпләр нурланыш ала. тирә-юньгә радиация тарала, әмма аны халыкка әйтмиләр.

1962 елның 28 февралендә «Маяк»та тагы авария, тагы нурланыш, тагы тирә-якка көчле радиация тарала.

1962 елның 7 сентябрендә - «Маяк»та авария, нурланыш.

1965 елның 16 декабрендә - «Маяк»та авария, нурланыш.

1967 ЕЛНЫ РАДИОАКТИВ КАЛДЫКЛАР САКЛАНА ТОРГАН КАРАЧАЙ КҮЛЕ ӨСТЕННӘН ӨЕРМӘ ҮТӘ ҺӘМ ТАБИГАТЬКӘ 0,6 МИЛЛИОН КЮРИ РАДИОАКТИВ КАЛДЫКЛАР ТАРАЛА, НӘТИҖӘДӘ, 41,5 МЕҢ КЕШЕ НУРЛАНЫШ АЛА.

1968 елның 10 декабрендә 20нче номерлы заводта плутоний белән бәйле авария була, күпләр нурланыш ала һәм үлә.

1976 елның 11 февралендә радиохимия заводында плутоний белән бәйле шартлау һәм җимерелү була, тирә-юньгә радиация тарала.

1984 елның 2 октябрендә реакторда шартлау була, тирә-юньгә көчле радиация тарала.

1990 елның 16 ноябрендә «Маяк»та шартлау була, көчле радиация тарала, үлүчеләр һәм тән җәрәхәте алучылар була.

1993 елның 17 июлендә «Маяк»ның радиоизотоплар заводында авария була, тирә-юньгә радиация тарала. Бу хакта халыкка берни дә әйтмиләр.

1993 елның 2 августында «Маяк»ның 22нче номерлы сыек радиоактивлар чистарту заводында авария була, радиация тарала.

1993 елның 27 декабрендә радиоизотоплар заводында авария була, тирә-юньгә көчле радиация тарала, әмма халыкка берни дә әйтмиләр.

1994 елның 4 февралендә «Маяк»ның 235нче номерлы заводында һавага радиоактив матдәләр тарала.

1994 елның 30 мартында «Маяк»ның 45нче номерлы заводында һавага радиация тарала.

1994 елның 20-23 маенда «Маяк»ның 235нче номерлы заводында вентиляция буйлап һавага радиация тарала.

1994 елның 7 июлендә «Маяк»ның 40нчы номерлы приборлар заводында радиоактив тап барлыкка килә, тирә-юньгә радиация тарала. Авариянең сәбәпчесе 45нче номерлы заводта канализация агу була.

1994 елның 31 августында радиохимия заводының 101нче бинасында трубадан атмосферага радионуклидлар тарала, моның сәбәпчесе ВВЭР-440 реакторының герметизациясе бетүе була.

1995 елның 24 мартында «Маяк»ның 235нче заводында АД-6531-1 аппаратын плутоний белән нормага караганда 19 процентка артык тутыру була, БУ ХӘЛ ЧАК КЫНА АТОМ-ТӨШ ҺӘЛӘКӘТЕНӘ КИТЕРМИЧӘ КАЛА.

1995 елның 15 августында сыек радиоактив калдыкларны эшкәрткәндә, тирә-юньгә радиацияле су акканы билгеле була.

1995 елның 21 декабрендә термометрик каналны караганда берничә эшче нурланыш ала.

1995 елның 24 июлендә 45нче номерлы заводтан тирә-юньгә радиация тарала, моның сәбәпчесе камерадагы фильтрның януы була.

1995 елның 14 сентябрендә 235нче номерлы заводта, 4нче цехта, радиоактивларны саклау приборлары сафтан чыга, нәтиҗәдә, радионуклидлар суга эләгә һәм 10 эшче нурланыш ала.

1996 елның 20 ноябрендә химия-металлургия заводында, электр җиһазларына ремонт вакытында, һавага көчле радиация тарала, ун еллык радиация нормасының 10 процентын тәшкил итә.

1997 елның 27 августында РТ-1 заводының 4нче номерлы цехында идәндә радиация табы барлыкка килә, моның сәбәпчесе - конвейрдагы мичтән зарарлы эремәнең тулып агуы була.

1997 елның 6 октябрендә РТ-1 заводының 954нче номерлы бинасында көчле радиация тарала, моның сәбәпчесе промышленность өчен тотыла торган су булып чыга.

1998 елны» 23 сентябрендә ЛФ-2 («Людмила») реакторының куәтен 10 процентка күтәргәндә, аерым каналлар ныклыкларын югалталар һәм 10 көн эчендә тирә-юньгә еллык радиация тарала. Реакторны ремонтка туктатырга мәҗбүр булалар.

2000 елның 9 сентябрендә «Маяк»ка сәгать ярым электр бирүне туктатып торалар, МОНЫҢ НӘТИҖӘСЕНДӘ КОТОЧКЫЧ АТОМ-ТӨШ ҺӘЛӘКӘТЕ БУЛЫРГА МӨМКИН ИДЕ. Шуңа күрә Госатомнадзорның Урал регионара бүлеге бу хакта Чиләбе өлкәсе прокуратурасына мөрәҗәгать итәргә мәҗбүр була.

Болар - галимнәргә билгеле булган авария һәм шартлаулар, тирә-юньгә радиация таралу фактлары, ә алар белмичә калганнары күпме? Чернобыль кайдан килеп чыга? Менә шулай даими рәвештә ватыла-җимерелә эшләүдән, куркынычны яшерергә тырышудан, радиация зонасында яшәүче кешеләрнең язмышына карата битараф булудан, һәм, әлбәттә, зур акчаларның колы булудан килеп чыга ул Чернобыль фаҗигәләре. «Маяк»та югарыда санап киткән атом аварияләренең кайсы турында халык вакытында белде, чарасы күрелде, ярдәм ителде? Берсе хакында да үз вакытында дөресен әйтмәделәр, хәзер дә әйтеп бетермиләр. Бу аварияләрнең иң куркынычы 1957 елда булды, һәм ул тарихка «Кыштым фаҗигасе» булып кереп калды. Ул чакта тирә-юньгә Чернобыльдәгегә караганда 200 тапкыр күбрәк радиация тарала, әмма бу хакта халыкка әйтмиләр. Атом болыты Чиләбе, Курган, Төмән, Свердловски өлкәләренә тарала, 300 чакырымга сузылган радиация зонасында 217 торак пункт кала, 270 мең кеше нурланыш ала. Сәбәбен әйтмичә генә, радиация астында калган 42 торак пунктын, 12 мең кешене башка урынга күчерәләр. Шул ук вакытта өчәр, дүртәр мең кеше яшәгән зур-зур татар авыл-

лары үлем зонасы дип игълан ителгән атом территориясендә утырып калалар һәм бүгенге көндә дә шунда яшәп яталар. Биредә яшәүчеләрнең инде күпчелеге үлгән, ә исәннәрнең 80-90 проценты нурланыш һәм рак авыруларыннан газап чигә. Халык тоташы белән чирле, гарип, балалар арасында мутантлар һәм акылга зәгыйфьләр бик күп. «Маяк» берләшмәсенең төп эшчәнлеге әнә шуларда чагыла... Алга таба төп сүзебез дә атом тамгалы шул татарлар турында булыр.

Галимнәрнең әйтүенчә, планлы һәм плансыз ташлаулар нәтиҗәсендә, «Маяк»тан 150 млн. кюри атом калдыклары табигатькә ыргытыла, алардан 267000 кв. км. мәйдан агулана. Шул мәйданда яшәүче 437000 кеше нурланышрадиациягә эләгә. Тагы да төгәлрәк итеп әйткәндә, бер Чиләбе өлкәсендә генә дә миллион ярым кеше даими рәвештә радиация астында яши, нурланышка дучар була. Бүгенге көндә «Маяк» комбинаты дөньяда иң куркыныч, радиациядән иң нык пычранган урын булып исәпләнә. Әйткәнебезчә, биредә бүген 1 миллиард тонна атом калдыклары саклана, «Маяк»ка бүген чит илләрдән дә кирәксез атом ягулыкларын китерүләре билгеле. Биредә 231 атом каберлеге бар, җир астындагы һәм җир өстендәге саклагычларда, күл-сазлыкларда алар үз вакытларын көтеп яталар... Бу күл-сазлыклардан алар даими рәвештә Теча елгасына бәреп чыгалар, үз юлларында утырган татар авылларын агулап, җимергеч эшләрен дәвам итәләр..... «Маяк» берләшмәсе территориясендә сыек радиоактив калдыклар ыргытыла торган 17 махсус сусаклагыч билгеле, алар 30-40 кв. км. мәйданны биләп торалар. 500 мең тонна каты радиоактив сакланган 200 атом каберлеге дә инде 80 процентка тулган. «Маяк» берләшмәсенең районнан тагы 100 гектар җир алулары билгеле, димәк, бу мәйдан да атом каберлекләре белән тулачак, чөнки чит илләрдән күпләп китерелә башлаган атом калдыкларын саклау өчен җир кирәк. Димәк, «Маяк» эшләп торганда, бу тирәдә яшәүчеләр беркайчан да имин булмаячак, бу җирләр, бу сулар, бу кешеләр даими рәвештә радиация һәм нурланыш алып торачак...

Сыек радиоактив калдыкларның саклагычына әйләнгән Карачай күле бүген өлешчә күмелгән, ягъни,

тимер-бетон белән бастырылып куелган. Мондый карарга 1967 елгы давылдан соң киләләр. Бу якларда өермә-давыллар еш булучан, шундыйларның берсе Карачай күле өстеннән дә үтеп киткән. Әйтерсең лә күкләр җирдә үлем белән уйнаучыларны тагы бер тапкыр кисәтергә уйлый, аларга бу уенның нәтиҗәләрен күрсәтә... Нәтиҗә - коточкыч... Тирә-юньгә таралган меңләгән, миллионлаган кюри радиация, нурланыш алган меңләгән кеше, эштән чыгарылган меңләгән гектар җир, туздырылып ташланган дистәләгән авыл... Шушы хәлләрдән соң Карачай күле өлешчә каплап куела һәм радиацияле су... җир астына китә. Бу агулы су, җир асты юллары буйлап, инде Мәшәләк елгасына ук килеп җитә. Галимнәр әйтүенчә, бу тирәдә җир астында 30 кв. км. мәйдандагы 4 миллион куб су радионуклидлар белән агуланган һәм Мәшәләк елгасына саркып ята. Бу радиацияле су 100 метр тирәнлеккә хәтле киткән. Карачай күлендә бүген 120 миллион кюри радиоактив калдыклар саклана, Иске сазлыкта бу агу - 2 млн. кюри... Һәм болар барысы да әкренләп Теча елгасына саркып чыга. Дөресен әйткәндә, биредәге барлык елга-күлләрдә дә радионуклидлар бар. Әмма халык өчен иң куркынычы - «Маяк» берләшмәсе белән Теча елгасы арасындагы радиоактив калдыклар саклый торган махсус сусаклагычлар, ягъни, Теча каскады. 50-60 елларда радиоактив калдыклар саклау өчен махсус буылган бу буалар һәм табигый күлләр теләсә кайсы вакытта тулып, ташып чыгарга мөмкин. Бу агулы су болай да вакыты-вакыты белән Теча елгасына ташып чыга, бөтен тирә-юньгә атом калдыклары тарата. Ә инде көчле яңгырлар явып үтсә, бөтенләй дә җимерелергә мөмкин. Ул чагында Теча-Исеть-Тобол-Обь елгалары аша Төньяк Боз океанына кадәр үтергеч радиация таралачак. «Маяк»тан Теча елгасы буйлап 30 чакырым түбән урнашкан Мөслим авылына бу үтергеч дулкын берничә сәгатьтә барып җитәчәк... Бу Теча сусаклагычлар каскадының бернинди лицензиясез, законсыз, рөхсәтсез эшләп ятканын да әйтергә кирәк...

1957 елдан башлап бүгенге көнгә хәтле «Маяк» комбинаты атнага ике тапкыр радиоактив калдыкларны Теча елгасына ташлап килә. Бу - планлы ташлаулар, дип атала, ә плансызын беркем хисаплап тормый. Кешеләрне һәм таби-

гатьне ничек планлы рәвештә радиация белән агулап буладыр, анысы бөтенләй дә аңлашылмый. Әмма иң аңлашылмаганы шунда, «Маяк» берләшмәсе, кешеләрне радиация белән агулавын белсә дә, аларга бернинди ярдәм күрсәтергә теләми. Хәер, «Маяк» берләшмәсе артында Минатом, хәрби оборона министрлыгы, Россия хөкүмәте торганлыгын да әйтергә кирәк, чөнки «Маяк» корал җитештерә торган дәүләт предприятиесе бит. Димәк, Россия дәүләте үз халкын даими рәвештә радиация белән кырдырып, юк итеп тора. Бу җинаятьчел сәясәт бигрәк тә радиация зонасында яшәгән татар халкына кагыла. Безнең шулай дип әйтергә тулы хакыбыз бар, чөнки 1957-1967 елгы аварияләр нәтиҗәсендә рус авылларын башка урынга күчергәннәр, ә татар һәм башкорт авыллары шушы үле зонада утырып калган. Аларны биредә «тәҗрибә төркеме» рәвешендә, ягъни, атом экспериментлары уздыру өчен калдырганнар, дип әйтергә дә тулы хакыбыз бар. Ягъни, даими рәвештә нурланыш алып торган кешеләрнең сәламәтлеге кайсы якка үзгәрә, генетик үзгәрешләр нәрсә күрсәтә, атом-төш сугышы булган очракта, соңыннан нәрсәләргә аеруча игътибар бирергә кирәк - үле зонада калган татарлар, үз гомерләре бәрәбәренә, әнә шул сорауларга җавап бирергә тиеш булалар. Аларны, Мәскәү һәм Чиләбеләрдән килеп, 40 ел буе махсус өйрәнәләр, тикшерәләр, яшерен мәгълүмат җыялар, әмма үлем көтеп яткан бу татарларның үзләренә берни белән дә ярдәм итмиләр. Россия оборона министрлыгында, яшерен архивларда, больница-лабораторияләрдә нурланыш алган татарлар буенча күп мәгълүмат булырга тиеш. Шуңа күрә бу татарларны бер җиргә дә күчермиләр, чөнки алар дөньяда тиңе булмаган тәҗрибә өчен кирәк...

Үлем индустриясе булган «Маяк» эшләп торганда, биредә яшәүчеләр өчен һәрвакыт зур куркыныч янаячак. Бүген Россиянең атом тәҗрибә өстәлендә татарлар булса, иртәгә бөтен Чиләбе өлкәсе шушы аянычлы хәлдә калырга мөмкин. Шуңа күрә алга таба сүз бары тик «Маяк» берләшмәсен тулысынча туктату, яптыру турында гына барырга мөмкин. Шунысы гаҗәп, шушы хәлләрнең барысын да белгән Россия галимнәре, хокукчылар, экологлар бүгенгесе көндә үлем чыганагы булган «Маяк»ны яптыру

турында түгел, аны өлешчә яхшырту, «куркынычсызга» әйләндерү турында сүз куерталар. Имеш, Карачай күлен тулысынча күмсәң, сыек радиоактив калдыкларны катыру өчен махсус цехлар төзесәң, аларны тиешенчә сакласаң, радиациядән пычыранган биналарны юк итсәң, иң куркыныч 17нче сусаклагычны юк итсәң, Теча каскадындагы суның биеклеген киметсәң, Карачай күле астындагы радиацияле суны юк итсәң (?!)... атом һәләкәте булмаска да мөмкин икән... Бу хакта без югарыда мисалга китергән В. М. Кузнецов китабында әйтелә. (230-231 битләр.) Безгә калса, тирә-якка үлем афәте чәчеп яткан атом монстрын авызлыклау өчен болар гына җитми. «Маяк» берләшмәсе бүген бөтен Урал төбәгенә, Себер киңлекләренә, хәтта бөтен кешелек дөньясын иминлегенә яный. Һәм кешелек, бигрәк тә, бу төбәктә, даими атом куркынычы астында яшәүчеләр, үз алларына шундый сорау куярга тиешләр - бу «Маяк» берләшмәсе аларга кирәкме соң? Биредә, кешеләр иң тыгыз яшәгән бер төбәктә, урман-күлләр арасында, саф сулар чолганышында, дөньяның тыюлык булырлык иң гүзәл җирләрендә - кирәк идеме шундый үлем комбинаты? Атом индустриясе өчен бик кирәк икән, нигә ул берәр кешесез утрауда яки чүлдә төзелмәгән, нигә кешеләр күпләп яши торган урында эшли башлаган? 50 ел элек Сталин тарафыннан эшләнгән бу мәкерле хатаны төзәтергә вакыт җитте бит инде, шушы чорда радиациядән череп, газапланып үлгән меңләгән кеше гомере, юкка чыккан нәселләр, авыллар, агуланган җир-сулар бездән шуны таләп итә! ХӘЗЕРГӘ БИРЕДӘ КҮПЛӘП ТАТАРЛАР ҮЛӘ, ТАТАРЛАР КЫРЫЛА, ӘММА «МАЯК» ЭШЛӘП ТОРГАНДА, БИРЕДӘ БЕРКЕМ ИСӘН КАЛМАЯЧАК, РАДИЯЦИЯ ӘКРЕНЛӘП БАРЫСЫНА ДА БАРЫП ҖИТӘЧӘК. Димәк, бүген сүз бары тик «Маяк»ны яптыру турында гына барырга мөмкин. «Маяк»ны яптыру һәм радиациядән зарар күргән кешеләргә, беренче чиратта, үлем зонасында калган татарларга, тулысынча компенцация түләү, аларны башка урыннарга күчерү турында сүз барырга тиеш. Бу - дәүләт дәрәҗәсендә хәл ителергә тиешле мәсьәлә, әмма астан халык дәшмәсә, дәшми генә үлсә, бу мәсьәлә берничек тә хәл ителмәскә мөмкин.

Исәннәргә гыйбрәт булсын өчен, без радиация астында үлеп бара торган татарларның, татар авылларының язмышын сөйләп бирергә булдык. Укыгыз һәм тетрәнегез - бүген татарлар шушы фаҗигале хәлдә, иртәгә бу язмыш сезгә дә килергә мөмкин. Радиация афәте милләтне тикшереп тормый, министрларга, президентларга да барып җитәргә мөмкин... Барыгызга да, барыбызга да...

Әйе, Россиядә үлем җир астына яшерелгән... Илнең бер башыннан икенче почмагына кадәр йөзгә якын атом-төш материаллары саклау мәйданнары урнашкан, аларның күпчелеге - җир астында. Россиянең атом калдыклары, атом полигоннары белән Урал таулары гына түгел, Төньяк Котып, Яңа Җир утраулары, Кола ярымутравы да тулган... 1961 елда бирედә дөньяда беренчеләрдән булып 58 мегатонлы водород бомбасы шартлатыла, бу - Хиросимага ташланган бомбадан куәте белән 6000 тапкыр артык була! Һавада шартлаган бомба дулкыны җир шарын өч тапкыр әйләнеп чыга... Җир өстеннән 60 километрга атом гөмбәсе күтәрелә... Җир шарының бөтен төньяк өлешенә атом калдыклары ява... Без, Россяидә яшәүчеләр, барыбыз да менә шушы коточкыч шартларда туган, атом калдыклары арасында үскән, көн итәргә азапланган халык инде... Шуңа күрә ил тулы дебильләргә, авыруларга, маньякларга, җинаятьчеләргә бер дә гаҗәпләнәсе юк... Атом-төш коралын үз илендә, үз җирендә җитештереп һәм сынап, Россия үз халкын тоташы белән мутантлар иленә әйләндерде... Галимнәр әйтүенчә, җиргә, суга, һавага, кеше организмына эләккән плутоний бары тик 24 мең елда гына тулысынча юкка чыгып бетә икән... Ә аңа кадәр ул кешенең үзен бетерә...

Россиядә бүген 130 тонна плутоний запасы, 1050 тонна уран, 120000 тонна атом-төш коралы барлыгы билгеле, бу дөньядагы барлык атом-төш запасының яртысын тәшкил итә... Россия - чын мәгънәсендә атом каберлеге иле... 1949 елдан алып, 1990 елга кадәр СССРда 715 атом-төш сынавы уздырылган... Бу атом сынаулары, бу уран-плутоний каберлекләре барысы да кеше сәламәтлеге өчен иң зур куркынычка әйләнеп бара. Котырып корал җитештерүнең, атом белән селтәнүнең нәтиҗәсе бер генә - миллионнарның вакытсыз газаплы үлеме... Бүген Россиядә үлем инде җир

өстенә чыкты, ул үз юлында очраган һәркемне атом чалгысы белән кыра, балаларны, хатын-кызларны, картын-яшен - беркемне кызганып, сайлап тормый... Гади авыл татарларыннан башлап, «Маяк» берләшмәсендә эшләүче иң югары җитәкчеләргә хәтле рактан, нурланыштан үлә..

Бүген инде беркемгә дә сер түгел - кеше организмына эләккән радиоактив калдыклар анда рак авыруын китереп чыгаралар. Менә шуңа күрә атом электр станцияләре, атом полигоннары, атом белән бәйле объектлар тирәсендә яшәүчеләр, радиация тәэсиренә дучар булучылар рак белән башкаларга караганда 6-7 тапкыр күбрәк авырыйлар. Радиация шуның белән дә бик куркыныч, ул күзгә күренми, аның исе, төсе, тәме юк, ягъни, кеше аны кайда, ничек эләктергәнен дә белмичә калырга мөмкин. Без түбәндә сүз алып барачак авыл татарлары белән дә нәкъ шулай килеп чыккан - алар еллар буе радиацияле җирләрдә яшәгәннәрен белмәгәннәр, ә моны белгән атомчылар, ил җитәкчеләре халыкны үлем куркынычы турында кисәтергә кирәк тапмаган... Хәзер исә радиация турында белүчеләр дә, белмәүчеләр дә нурланыштан, рактан үлеп бетеп бара... Үз халкын шушы газаплы хәлгә төшергән СССР дигән ил дә юк, бу хәлләр өчен гаепләргә, сорарга кеше дә юк... Әмма «Маяк» фаҗигасе килер буыннар өчен гыйбрәт булырга тиеш, шуның өчен дә без бу хакта кешеләргә сөйләргә булдык...

ГАЛИМ ФИКЕРЕ:

«Радиация, чыннан да үлем куркынычына тиң. Зур дозаларда ул тукымаларның җитди зарарлануына китерә, ә кече доза исә кешедә рак һәм генетик үзгәрешләр китереп чыгарырга мөмкин. Бу үзгәрешләр нурланыш алган кешенең балаларында, оныкларында, бөтен нәселендә чагылырга мөмкин. 100 грей нурланыш алган кеше берничә сәгать эчендә үлә, ә 10нан 50 грейга кадәр нурланыш алган кеше бер-ике атнадан ашказаны-эчәкләренә кан савып үлә... Балалар радиациягә бигрәк тә сизгер. Сеңгер тукымалары аз гына доза нурланыш алудан да сөякләр үсүдән туктарга мөмкин. 10 грей доза нурланыш алганда исә баланың скелеты гарипләнергә мөмкин. Баланың мие нурланышка эләксә, аның хәтере юкка чыгарга, холкы үзгәрергә

мөмкин, ә сабый балалар исә акылга җиңеләергә һәм тилерергә мөмкиннәр... Әгәр нурланышка авырлы хатын эләксә, бигрәк тә карындагы бала сигез атнадан унбиш атнага кадәр булса, ягъни, баланың баш мие формалашканда, ул чагында акылга зәгыйфь бала туарга мөмкин.» (Кадыров М. Г., «На путях к духовно-экологической цивилизации», Казань, 1996г., стр. 96-97.)

Әйткәнебезчә, Россия бүген төрки-татарлар яшәгән бөтен җирләрне дә атом полигонына әйләндерде, казах һәм Ырынбур далаларын атом бомбалары белән актарып ташлады, Идел-Урал арасын атом, химик, бактереологик корал саклау базлары белән тутырды... Болар барысы да җирле халык белән килешенмичә, аларга үлем куркыныч турында берни әйтми эшләнде һәм эшләнеп ята. Сүзебез дәлилле булсын өчен, 1954 елда Ырынбур далаларында дәүләт халыкка каршы эшләгән бер җинаять турында язып үтәбез. Биредә, җирле халыкка берни әйтмичә һәм аларны беркая күчермичә, алар өстендә атом бомбасы шартлатыла. Күрәсез, «Маяк»та эшләнгән атом бомбаларын хәрбиләр ерак алып китеп тормыйлар - шул ук төрки-татар җирләрендә, Ырынбур һәм казах далаларында сынап карыйлар. Тоцкийдагы атом сынавы да коточкыч була, чөнки бирегә ташланган атом бомбасы үзенең көчке ягыннан Хиросима һәм Нагасакига караганда да ике тапкыр куәтлерәк булып чыга. Бу хакта «Коммерсант Дели» газетасының 1998 елгы 25 апрель (№ 75) саны менә нәрсә яза:

«Утром 14 сентября 1954 года над Тоцким полигоном, находящимся в Оренбургской области, была сброшена с самолета с высоты 8 км атомная бомба. На высоте 350 м от земли она взорвалась. Её мощность была 400 килотонн тротилового эквивалента, что почти в два раза больше, чем у бомб, сброшенных на Хиросиму и Нагасаки. Прошло почти полстолетия, но несмотря на относительно чистую сейчас окружающую среду в зоне Тоцкого ядерного взрыва, только за промежуток времени от 1985г. по 1993г. был отмечен сильный рост онкологических и прочих заболеваний населения. По данным специалистов Уральского отделения РАН, у населения, живущего вблизи полигона, злокачественные новообразования органов дыхания стали всречать-

ся чаще, чем до взрыва бомбы на 258%, щитовидной железы на 260%, рака кожи на 131%, а заболеваний лимфо и кроветворных систем на 670%. Общие онкозаболевания детей возросли в 2 раза, смертность населения с 1964 года по 1991 год увеличилась в 2,3 раза. У жителей обнаружен повышенный уровень хромосомных нарушений, практически такой же, как в Брянской области на территории Чернобыльского следа».

Әйе, биредә барысы да дөрес, әмма әйтеп бетермәгән бер нәрсә бар - өсләренә атом бомбасы ыргытылган, һәм нәтиҗәдә, инде рактан үлеп бетеп баручылар, алар - ТАТАРЛАР... Татар җирләрендә - «Маяк»та эшләнгән атом бомбасы татар җирләрендә, татарлар өстендә сынала... Халык, үләр өчен һәм тәҗрибә өчен, радиацияле зонада калдырыла... Нәкъ Чиләбе өлкәсендәге татар авыллары кебек... Россия татарларны атом казанына салып кайната...






# ИКЕНЧЕ БҮЛЕК

## Атом атавында

Кунашак — Чиләбе өлкәсендәге бердәнбер милли район. Рәсми мәгълүматлар буенча, биредә яшәүчеләрнең нибары 7 проценты гына славяннар, калган 92 проценты - төрки халык, ягъни, татарлар һәм башкортлар. Радиациядән иң нык зыян күргән һәм бүген дә шул сәбәпле зур газаплар кичерүчеләр дә шулар. «Маяк» берләшмәсе шушы Кунашак районына урнашкан, өстә — тарихы меңеллык татар авыллары, аста — фаҗигасе меңелларга барачак үлем индустриясе... Бу төбәктә яшәүчеләрнең 80-90 проценты рак һәм нурланыш авыруларыннан газап чигә. Радиация сәбәпле әҗәл чире алучыларның да күпчелеге — татарлар. Биредә яшәүче татарлар — атом тоткыннары һәм Россия уздырган атом геноцидының корбаннары. Безнең болай дип әйтергә тулы хокукыбыз бар, чөнки татарларның радиацияле үле зонада тормышлары шул хакта сөйләп тора. Без, Бөтендөнья татар конгрессының махсус төркеме — хокукчы-юристлар Роза Фәрдиева, Җәмил Сафиуллин, Гөлназ Хөснетдтнова, Татарстанның атом куркынычсызлыгы комитеты рәисе, эколог-галим Альберт Гарапов, «Татарстан — яңа гасыр» телевидениесе журналисты Фирдүс Гыймалтдинов, телеоператор һәм мин — Бөтендөнья татар конгрессының Башкарма комитеты әгъзасы, язучы Фәүзия Бәйрәмова, Чиләбе өлкәсенең Кунашак районына, татарларның хокуклары кысылу мәсьәләсен тикшерергә-

өйрәнергә дип бирегә килдек. Безнең биредә күргәннәребез һәм ишеткәннәребез җан тетрәндергеч иде. Без биредә ахырзаман авылларын күргән кебек булдык, атом фаҗигасеннән соң дөньяның, тереклекнең нинди буласын күзалладык, үзләрендә үлем тамгасы йөрткән татарларның соңгы сүзләрен васыять кебек тыңладык, мутант, тумыштан гарип балаларны күреп, өнсез калдык... Болар барысы да атом радиациясе тәэсире, «Маяк» эшчәнлегенең ачы нәтиҗәләре иде... Әйе, биредә һәр авыл, һәр чишмә, һәр кеше, һәр зират бөтен дөньяга кычкырып тора - биредә тереклек өстеннән коточкыч тәҗрибә уздырылган... Биредә кешеләрнең бар хокуклары да аяк астына салып тапталган, изелгән, юк ителгән... Кешенең Аллаһтан бирелгән иң зур хокукы - яшәргә хокук, әмма биредә татарларның гомерләренә атом хуҗа... Кешенең сәламәт яшәргә, чиста табигатькә, ризыкка хокукы бар, әмма биредә татарлар даими рәвештә радиация астында яшиләр, атом калдыклары ташланган суны эчәләр, радионуклидлы туфрактан туклана-лар, радиацияле һаваны сулыйлар, нәтиҗәдә, коточкыч чирләр белән авырыйлар һәм зур газаплар белән үләләр... Кешенең үз милли телендә белем алырга, үз динен тотарга да хокукы булырга тиеш, әмма милли район дип йөртелгән Кунашак районында бер генә саф татар мәктәбе дә юк, берничә авыл мәктәбендә татар теле атнага бер тапкыр бары тик предмет буларак кына кертелә... Калганы барысы да рус телендә. Гомер буе ислам динен тоткан халык 70-80 ел эчендә диннән дә читләштерелде, борынгы мәчетләр мал абзарларына әйләндерелде, татарларның дин әһелләре, гыйлем ияләре юк ителде... Шуның өстенә, «радиацияне чыгара» дигән ялган белән, татар авылларын очсызлы аракы белән тутырганнар, халыкны көчләп эчәргә өйрәткәннәр, болай да бәхетсез, авыру халыкның кулына аракы тоттырганнар... Бу да Россия хөкүмәтенең мәкерле сәясәте булган - радиациядән кырылып бетмәгән татарлар эчеп үләргә тиеш булган... Әмма борынгы тамырлары Нух пәйгамбәр заманнарына, Атилла кебек татар каһарманнарына, төрки-татар каганатларына, Алтын Урда, Нугай-Урал татарларына барып тоташкан халыкны хәтта атом да алып бертерә алмый... Алар, борынгы төрки Атлантида кебек, инде

мәңгелеккә китеп ятсалар да, үзләре турында бөтен дөньяга хәбәр биреп калдыралар, бөтен дөньяга чаң сугалар... «ДӨНЬЯГА АТОМ ҺӘЛӘКӘТЕ ЯНЫЙ! БЕЗ, ТАТАРЛАР, АТОМ ФАҖИГАСЕ КОРБАННАРЫ! БЕЗНЕҢ ЯЗМЫШЫБЫЗ СЕЗГӘ ГЫЙБРӘТ БУЛСЫН, БАШКАЛАРНЫ САКЛАП КАЛЫРГА ЯРДӘМ ИТСЕН...»

**КЫЗГАНАМ ШУЛ АВЫЛНЫ**

Атом коралы ясаган
«Маяк» ширкәте шартлаган
Мөслим авылына багышлана.
И мескен авыл. Утыра
Тимер чыбык эчендә,
Үләннәре котырып үскән,
Җил исә бар көченә.
«Анда барма! Моны эчмә!»,
«Ашамагыз боларын!».
Кисәтеп тора игъланнар
Кызларын һәм улларын.
Карт-коры ята түшәктә,
Үлем сәгатен көтеп.
Ыңгыраша авырулар,
Җаннарыңны өшетеп.
Нәрсә соң монда - авылмы
Әллә каберстанмы?
Кайдан килгән каза соң бу,
Дошманнамы, дустанмы?
Кайчан гына гөрләп торган
Матур татар авылын,
Бер мизгелдә агулаган
Күренмәс чир давылы.
Илгә корал ясаган, дип,
Шул ширкәтне яклыйлар.
Чит илләр ишетмәсен, дип,
Бездән серен саклыйлар.
Зур максат өчен, янәсе,
Корбаннар кирәк бит ул.
Сугышка кергәч ярасыз
Чыгучы сирәк бит ул...

Без татарга төшә инде
Күсәкнең иң авыры.
Гарип кешене күргәндәй
Кызганам шул авылны...
*ДАМИР ГЫЙСМЕТДИН.*

Әйе, РОССИЯНЕҢ АТОМ АРХИПЕЛАГЫНДА беренче утрау - борынгы зур татар авылы Мөслим... Ул «Маяк»тан нибары 30 чакырым ераклыкта, Тыныч (Теча) елгасы буена түбәнгә урнашкан. Авыл моннан 1500 еллар элек, һуннар заманында ук булган булырга тиеш, чөнки әле 1895 елда биредә һун татарларының борынгы алтын хәзинәләре табыла һәм Петербургка озатыла... Бу тирәләрдән борынгы төрки курганнар, каберлекләр, хәтта шәһәрлекләр табылуын да әйтергә кирәк. Шушы ук Чиләбе өлкәсендәге 4 мең еллык тарихи Аркаим шәһәрлеге дә - һун татарларының мирасы. Биредә төрки-татарлар дистә мең еллар яшәгәннәр, зур дәүләтләр һәм шәһәрләр тотканнар, зур рухи мирас һәм таза нәсел калдырганнар. Һәм бүгенге көндә шушы борынгы милләт, тиңсез мәдәният, тере, тырыш татарлар атом индустирясе тарафыннан аягүрә череп үлүгә дучар ителгән! Бу хәл бер тарларга гына түгел, бөтен кешелек дөньясына каршы юнәлдерелгән җинаять, дип бәяләнергә хаклы...

Кайчандыр гөрләп торган Мөслим авылы бүген чәнечкеле тимер чыбык белән уратып алынган. Имеш, шул рәвешле халыкны радиацияле Теча елгасыннан саклыйлар. Ә халык кая барсын, башка суы булмагач? Аның малтуары да шушы елгада, бала-чага да җәй буе шунда, йорт кирәк-яраклары өчен дә халык суны шуннан ала... Ә бу елгага «Маяк»тан 150 миллион кюри радиоактив калдыклар ташланган, хәзер дә яр буйларында нурланыш нормадан мең тапкыр артык урыннар бар... Халык менә шушы шартларда яшәргә мәҗбүр ителгән, шушы атом утравына бәйләп куелган... Шуның шомлы нәтиҗәсе буларак, авыл башында 6 зират куркыныч шаулап утыра... Анда һәр көн я»а кабер казыла... Җирендә, суында, һавасында радиация мыжлап торган Мөслим авылы, тирә-юньгә кара нурлар таратып, үлем көтеп ята... Авыл шактый таракау һәм

искергән, башка урынга күчерүне өмет итеп, кешеләр яңа йортлар салмыйлар... Нәтиҗәдә, берәм-берәм зиратка күчеп баралар...

1957 елда, «Маяк»та шартлау булганнан соң, Мөслим авылын да башка урынга күчерергә хәл итәләр. Әмма, ни сәбәпледер, авыл күчерелмичә кала, мыскыл иткәндәй, Теча елгасының бер ягыннан икенчесенә берничә йортны күчерәләр дә, авыл күчерелгән, дип, хисап бирәләр. Халыкка дөресен әйтмиләр, алда аларны нинди үлем куркынычы көткәнен кисәтмиләр. Мөслим халкының кинәт кенә күпләп үлә башлавын, чирләвен исә аларның үзләреннән күрәләр, имеш, татарлар эчә, начар туклана, туганнар арасында өйләнешеп, кан катнаштыра, имеш, шуңа күрә күпләп үләләр, нәселләре корый... Мең еллар буе ат кебек таза булган, һәр гаиләдә унышар бала тәрбияләп үстергән, эчүнең нәрсә икәнен белмәгән, динен, телен, нәселен саклап калган татар XX гасыр азагында гына шулай кыргыйга әйләнеп киткән икән... Татарларның башларына гел шулай түкеп, чүкеп торалар, башкаларны да шуңа ышандырырга тырышалар. Коточкыч сер бары тик Чернобыль фаҗигасеннән соң, үзгәртеп кору елларында гына ачыла - Мөслим авылы менә инде ярты гасырга якын радиацияле үле зонада яшәп ята икән бит! Теча елгасына «Маяк»тан радиоактив калдыклар агып ята икән, 1957-1967 елларда да Мөслим авылы радиациядән иң зур зарар күрүчеләрнең берсе булган! Менә шуңа күрә үлем күп, менә шуңа күрә авыл халкының 80-90 проценты - гарип һәм авыру, менә шуңа күрә балык койрыклы балалар, мисез сабыйлар туа башлаган икән... Бу хәлләрне белеп тетрәнгән авыл халкы дәррәү күтәрелә, башка урынга күчерүне таләп итә башлый. Авылда бер-бер артлы иҗтимагый оешмалар, хокукый-экологик берләшмәләр барлыкка килә, башта - «Ак тычканнар», «Атом тоткыннары», соңрак - «Набат», «Теча», «Айгөл» оешмалары... Авыл халкы бары бер генә таләп куя - үзләрен башка урынга күчерүне. Уртак кайгы авылда яшәүче татарларны, аз санлы русларны, башкортларны берләштерә, аларның хатлары, жалобалары, таләпләре белән Чиләбе, Мәскәү кабинетлары тула, Мөслим фаҗигасе турында хәбәр хәтта чит илләргә дә бәреп

чыга... Авылга бер-бер артлы Америкадан, Япониядән, Голландиядән галимнәр, белгечләр килеп төшә, үзе дә җимерелеп барган совет империясе аларны бу зонага кертмәс өчен бөтенесен дә эшли. Әмма Мөслим фаҗигасен инде указ-карарлар белән генә каплап куеп булмый, татарларның ярдәм сорап кычкырган авазлары бөтен дөньяга яңгырый, бөтен дөньяны тетрәтә... Кыштым фаҗигасе Хиросима һәм Чернобыль белән янәшә куела...

1991 елның июнендә, президент сайлаулары алдыннан, Мөслимгә Борис Ельцин килә һәм авыл халкына ярдәм итәргә вәгъдә бирә. Әмма халыкка бу вәгъдәнең өлешчә булса да үтәлешен тагы 2 ел көтәргә туры килә. Халыкның көчле басымы, мөрәҗәгатьләре, халыкара оешмаларның бу эшкә катнаша башлавы Мәскәүне кайбер чаралар кылырга мәҗбүр итә. 1993 елның 25 маенда Мәскәүдә «О социальной защите граждан, подвергшихся воздействию радиации вследствии аварии в 1957 г. на ПО «Маяк» и сбросов радиоактивных отходов в р. Теча» дип аталган Федераль Закон кабул ителә. Бу закон нигезендә Мөслим авылының радиациядән зарар күрүчеләре чернобыльчеләр белән тәңгәлләштерелә һәм алар кебек үк льгота-ташламаларга ия була. Законны тормышка ашыру йөзеннән, 1993 елның октябрендә Россия хөкүмәте шул ук исемдәге махсус карар да кабул итә. Бер караганда, авыл халкын басып торган атом бозы кузгала кебек - Мәскәү хәтле Мәскәүдә алар өчен махсус закон чыгаралар, карар кабул итәләр... Закон белән хөкүмәт карары бар икән, димәк аның үтәлеше өчен зур акчалар да бүленеп бирелгән. Шулай булгач, инде закон кабул ителеп, ун ел үткәннән соң да, нигә Мөслимдә бернинди үзгәреш юк соң? Авыл һаман күчерелмәгән, шушы радиацияле зонада үлеп ята, кешеләргә чернобыльче статусын да бик сайлап кына, инде үлем чигенә килеп җиткәч бирәләр, льгота-ташламалар бик аз, хәтта дару алырга да җитми? Моңа җавап бер генә, чөнки бу - Россия. Монда кәгазъ язылса да, эш эшләнми, законнар үтәлми, акчалар урлана, кеше гомере чебен гомеренә дә тормый...

Авыл халкының, югарыда санап киткән хокукый-экологик оешмаларның бик нык йөрүләре сәбәпле, дөньяга

тагы бер карар пәйда була. 1994 елның 24 ноябрендә Чиләбе өлкәсенең хакимият башлыгы «О переселении жителей села и станции Муслюмова Кунашакского района» дип аталган күрсәтмәгә кул куя. Аның буенча авыл халкы Кунашак районы чикләрендә күчерелергә тиеш була. 4 мең кеше яшәгән Мөслим авылы халкы өчен район үзәге Кунашакта 60 квартиралы бер таш йорт төзелә, авылның аерата радиацияле урынында яшәгән кешеләр шунда күчерелә. Әмма - тагы мәкер, тагы Россиядәгечә! Мөслим авылыннан башка урынга күчерелүгә, бу авырулардан бөтен льгота-ташламаларын тартып алалар, шул таш бүлмәләрендә бикләнеп үлем көтәргә калдыралар! Ягъни, нурланыш белән авырыйсыңмы син, рактан газап чигәсеңме - башка җиргә күчүгә, бөтен ташламаларыңны югалтасың... Шушы акчаларга гына карап торган гарип-горабага бу хәл үлем белән бер була... Һәм халыкның бер өлеше, шушы льгота-ташламалар артыннан кабат Мөслимгә кайта, инде бөтенләйгә, үз туган җиренә ятып үлү өчен кайта... Гаҗәп хәл бит - әйтерсең, хөкүмәт махсус рәвештә мөслимлеләрне шул радиацияле җиргә бәйләп куя, аларның аннан китүен теләми, китсә, бу бичараларның бөтен льготаларын тартып ала, ярдәменнән ташлый... Кайбер эколог-галимнәрнең: «Бу татарлар радиацияле җирләрдә тәҗрибә үткәрү өчен кирәк», дигән сүзләре, чыннан да, дөреслеккә чыга ахыры. Бу хакта Чиләбе өлкәсенең танылган экологы, хокук яклаучы Наталья Миронова менә нәрсә дип яза:

«Какую же нравственность должно иметь государство, его службы здравоохранения и санитарного надзора, чтобы в течение 40 лет НАБЛЮДАТЬ (!) людей - стариков, женщин, детей в условиях проживания на твердых радиоактивных отходов и потребления ими пищи, загрязненной радионуклидами». («На путях к духовно-экономической цивилизации», Казань, 1996, стр.29.)

Шулай итеп, барысы да үз урынында утырып кала - агуланган авыл да, көчле нурланыш алган авырулар да, радионуклидлар агып яткан Теча елгасы да, радиация чыганагы булган «Маяк» та... Авылда берни үзгәрми, бары тик зиратлар һәм үлүчеләр саны гына арта. Бүгенге көндә Мөслимдә радиациядән зарар күргән 3968 кеше исәпләнә, шуларның

204е — нурланыш авыруы белән авыручылар, калганнарында рак, йөрәк һәм башка авырулар. Шушы хәтле чирле кешегә 25 урынлы бер участок больницасы, инде анысын да ябу турында сүзләр йөри. Больницада 1 группа инвалидлар, нурланыш алган каты чирле кешеләр ята, әмма монда андый авыруларны дәвалау өчен бернинди дә шартлар юк. Биредә, гомумән, берни дә юк, авырулар кирәкле даруларны, шприцларны, хәтта система аппаратларына хәтле үзләре белән алып киләләр. Хөкүмәт бу авыруларга биргән 200-300 сум льгота акчасы менә шушыларга китеп бара. Авылның меңләгән рак авырулы кешесенә нибары бер врач... Ә Чиләбе, Мәскәү врачлары исә, үз максатлары өчен, үзләренә кирәк вакытта гына авылга килеп, кешеләрнең каннарын анализга алып йөриләр, аларны өлкәнең һәм башкаланың аерым больницаларына ябып куеп, тикшерәләр һәм өйрәнәләр... Тикшерү нәтиҗәләрен исә халыкка әйтмиләр. Мөслим халкын Чиләбедә тәҗрибә уткәрә торган этләр һәм тычканнар белән янәшә бүлмәләрдә тотулары да билгеле. Татарларның газапланып җан бирүләренә әнә шул мәхлүклар гына шаһит була...

Авыручыларга карата тагы бер сәер хәл күзәтелә - аларга рак диагнозын куймас өчен бөтенесе дә эшләнә. Авыруларны гел алдап-йолдап, төрле чирләр дип тартып-сузып йөртәләр, аларга рак диагнозы иң соңгы очракта гына, үләр алдыннан гына куела. Бу исә хөкүмәткә артык акча түләмәс өчен һәм рак авыруларын киметеп күрсәтү өчен кирәк. Россия врачлары бу авыл халкыннан барысын да яшерәләр. Бары тик галим-экологлар, хокукчылар, дөнья җәмәгатьчелеге ярдәме белән генә, атом фаҗигасенең нәтиҗәләре билгеле була. Менә алар - Россия хөкүмәтенең, хәрбиләрнең, намуссыз врачларның татарлар өстеннән 50 ел буе алып барган атом-төш тәҗрибәсе нәтиҗәләре:

## АТОМ ТАМГАЛЫ ТАТАРЛАР

Бүгенге көндә Мөслим авылында һәр дүрт баланың берсе - мутант, ягъни, генетик яктан гарип.

Һәр бишенче бала йөрәк һәм сулыш юллары, һәр алтынчы бала ашказаны һәм эчәк чире белән газаплана.

Мәктәп яшендәге балаларны» 70 проценты акылга зәгыйфь, аларның баш миләре үсми яки анда су капчыгы...

Хәтта 1997 елны туган балаларның да каннарында атом тамгасы - хроник нурланыш бар.

Мөслим авылында балалар туганда ук патология белән туалар, ягъни, кайсының баш мие, бөере үсми, кайсының йөрәк, башка органнар дөрес урнашмаган була. Әйтик,

1997 елда 47 бала туа, шуның 30ы - патология белән. (67,8 %)

1998 елда 57 бала туа, шуның 28е - патология белән. (49,1 %)

1999 елда 45 бала туа, шуның 43е - патология белән. (95,5 %)

МӨСЛИМ АВЫЛЫНДА 90% МӘКТӘП БАЛАЛАРЫНДА АНЕМИЯ, КӨЧЛЕ ХӘЛСЕЗЛЕК, ИММУНИТЕТ НОЛЬГӘ ТИГЕЗ.

Мөслим авылында «РЕБЕНОК-ИНВАЛИД» дигән белешмәгә ия 3 яшьлек сабыйлар бар, алар хөкүмәттән ай саен 40 сум ярдәм алалар...

Мөслим авылында балалар генетик яктан олыларга караганда да зуррак зыян күрәләр. Алар организмына эләккән радиация 300 ел буе дәвам итәргә мөмкин, ягъни, 40 БУЫН НӘСЕЛ ГАРИП, ЧИРЛЕ БУЛАЧАК...

Мөслим авылында инде бөтен гаиләләре, нәселләре белән үлеп бетүчеләр бар. Биредә үлүчеләр саны туучыларга караганда ике тапкыр артыграк. Әйтик,

2000 елда 39 кеше туа, 76 кеше үлә;

2001 елда 58 кеше туа, 81 кеше үлә;

2002 елда 64 кеше туа, 96 кеше үлә;

2003 елның 4 аенда 19 кеше туа, 32 кеше үлә...

МӨСЛИМ АВЫЛЫНДА КЕШЕНЕҢ УРТАЧА ГОМЕР ОЗЫНЛЫГЫ — 40-45 яшь...

Биредә рак белән авыручылар саны башка төбәкләргә карганда 17-23 процентка күбрәк...

Биредә лейкимия, ягъни, кан рагы белән авыручылар саны, җан башына исәпләгәндә, Хиросима һәм Нагасакидан соң, дөньяда икенче урында тора!!!

Мөслим авылында ракның нинди генә төрләре юк! 1960 елдан 2002 елга хәтле Мөслим халкы өстеннән чын

мәгънәсендә рак эпедимиясе үтеп киткән, биредә халык үпкә, ашказаны, эчәк, аналык, күкрәк, кан, бавыр, баш мие, бугаз, үңәч, бит, тире, сөяк, тел, биз, сулыш юллары, талак, йөрәк ракларыннан үлгән! Болар - тиешле дарулар, тәрбия, акча булмаганнан тилмереп, газапланып үлгән татарлар... Татарлар, дим, чөнки йөзләгән кешедән торган бу үлем исемлегендә руслар берничә генә кеше. Мисал өчен, менә 2002 елда рактан үлүчеләр исемлеге:

АБДУЛЛИНА НАИЛӘ ЗИННӘТ кызы;
ӘГЪЗӘМОВА МӘДИНӘ ГАТИЯТУЛЛА кызы;
БАЙБУЛАТОВ МИННИҖАН РАМАЗАН улы;
БАРАНОВСКИЙ АРКАДИЙ К.;
ВӘЛИЕВ НУРУЛЛА МӨХИБУЛЛА улы;
ВАФИНА ЗАҺИРӘ ГАБДРАХМАН кызы;
ҖИҺАНДАРОВ БУЛАТ;
КАРЕЛИНА ВАЛЕНТИНА ПАВЛОВНА;
КИДРАЛИЕВ НӘБИ;
МИФТАХОВ КАШАФ;
НАСЫЙРОВА ХӨМӘЙРӘ ГАЙНЕТДИН кызы;
РӘХМӘТУЛЛИНА ГАЛИЯ МӘННӘН кызы;
СӘЕТХУҖИН АБДУЛВӘЛИ СӘГЫЙТЬ улы;
САФИЕВА РИВА;
СОЛТАНОВ АБДУЛМӘҖИТ;
ТИМЕРГАЗИН МОТЫЙГУЛЛА СОЛТАНҺАДИ улы;
ШӘЙХИСЛАМОВ ХАЛИТ.

Авыр туфрагыгыз җиңел булсын, газиз дин кардәшләр, милләттәшләр... Җир йөзендә күргән тәмуг газапларыгыз ахирәт көнегезгә дә ияреп бармасын, җаныгыз мәңгелек тынычлыкта булсын...

Нурланыш авыруы белән хисапта торучылар һәм үлүчеләр белән дә шул ук хәл - аларның 95 проценты - татарлар һәм башкортлар, берничә генә рус кешесе... Татарларның җир тетрәтеп яшәгән ирләре - КАҺИРОВЛАР, ҖИҺАНДАРОВЛАР, СОЛТАНОВЛАР, ХӘЯТОВЛАР, РӘХМӘТУЛЛИННАР, ГАЛИМОВЛАР, ГЫЙЛӘҖЕВЛАР, СӘЕТХУҖИННАР, ФӘЙЗРАХМАНОВЛАР, ВӘЛИЕВЛАР, МИФТАХОВЛАР - алар берсе дә юк инде... Йөзләгән, меңләгән атом корбаны бу дөньяда юк инде... Моны татарларга карата уздырылган ЭТНИК ГЕНОЦИД, димичә, тагы

ни дисең?! Меңнәрчә еллар буе шушы җирләрнең төп хуҗасы булган, дәүләтләр тоткан, затлы нәсел калдырган татарлар менә шулай үз җирләрендә, үз өйләрендә радиациядән агуланып үләләр. Һәм шушы җинаять өчен беркем җавап бирми!!! Күктә бер кош, диңгездә бер балык, җирдә бер бөҗәк юкка чыкса, бөтен кешелек җәмәгатьчелеге аякка баса. Ә монда милләт хәтле милләт, авыл хәтле авыл, нәсел хәтле нәсел күз алдында юкка чыгып, үлеп ята!

Мөслим авылыннан яшь кенә бер хатынның тилмереп әйткән сүзләре һаман онытылмый:

«Без үлемнән курыкмыйбыз, - диде ул. - Без рактан газапланып ятудан куркабыз... Ә бит шундый матур итеп яшәргә була иде...»

Әйе, аларның матур итеп яшәргә, дигән тормыш хыялларын үлем индустриясе тармар итеп ташлаган... Аларның иң якыннарын, иң газизләрен тартып алган - ата-аналарын, балаларын, туганнарын, сөйгән ярларын, үз гомерләрен...

...Без бу урында Мөслим татарларының яшәү һәм үлем тарихларын урнаштырабыз. Аларны хәзергә исәннәр язган, үз куллары белән язганнар... Аларда нәсел һәм гаилә тарихлары да, шушы хәлгә калуларына ачы рәнҗеш тә, яшәргә соңгы өмет тә чагыла... АТОМ УПКЫНЫНА КИТЕП БАРГАН ТАТАР АТАТЛАНТИДАСЫНЫҢ СОҢГЫ АВАЗЫ, СОҢГЫ ХӘБӘРЛӘРЕ... Укыгыз һәм тетрәнегез, укыгыз һәм гыйбрәт алыгыз, укыгыз һәм уйланыгыз... Бүген - алар, ә иртәгә?..

## ХӘЯТОВЛАР ГАИЛӘСЕ

«Мин, Хәятова Гөлфирә Шәйдулла кызы...

Елга (Теча) белән бәйле беренче балачак хәтирәм - ул чәнечкеле тимер чыбык иде... Елганы без тимер чыбык аша һәм ул чактагы иске агач күпердән күрә идек. Әти-әни безне елгага җибәрмәскә тырыша иде. Әмма нигә анда барырга ярамагынын аңлатмыйлар, мөгаен, үзләре дә белмәгәндер. Без, балалар, күпергә менеп, елга утраучыкларында үскән чәчәкләрне карарга ярата идек, алар, нигәдер, бик җете ал төстә иде... Елгадагы балыкларны да күзәтә идек, алар күп була иде, ә су, карап торышка, бик чиста күренә иде. Әмма әти-әниләр бу елганы «атомлы» дип

әйтәләр иде, соңыннан, мәктәптә физика үтә башлагач, атомның нәрсә икәнен аңладым, елга атомы белән башка атомнар арасында нинди аерма бар икән соң, дип уйлана башладым. Әти-әниләр 1957 елгы авария турында сирәк сөйлиләр иде, бу хакта сөйләгәндә дә пышылдауга күчәләр иде. Ничектер, әни шулай сөйләде: 1949 елдан елганың суы бозылган, ул яшел төскә кергән, ә алар аннан эчәргә су ала торган булганнар, кер чайкаганнар... Ул чагында әле чәнечкеле тимер чыбык булмаган. Елгадан аларны Нигай исемле кеше куып торган, белмим, бу рәсми каравыл булдымы икән, әллә ул үзе сизенеп балаларны кудымы икән? Соңыннан ул «Нигай тиле» дигән кушамат алды, чөнки кешеләр аңламыйлар иде - ничек инде ул елгага йөрергә ярамый? Кешеләр елгадан башка тормышларын күз алдына да китерә алмыйлар иде...

Миңа әби еш кына елганың элек нинди булуы турында сөйли иде. Аның сөйләве буенча, елга элек киң һәм тирән булган. Әмма ул суның кайда китүен әйтә алмый иде, аны япканнар (буганнар), дия иде. Әнием белән башка авыла баргач һәм тимер чыбыксыз елга күргәч кенә мин үзебезнең елга белән нәрсәдер булганын аңладым. Ул авылның елгасына якын барырга мөмкин һәм анда милиция дә тормый иде... Елгабызда нидер барын белсәк тә, без барыбер анда су коена идек (ә тагы кая барасың)? Җәен кер чайкый идек, каз һәм бозауларны биредә йөртә идек... Чөнки без бернәрсә дә белми идек...

Ул елларда (60-70нче еллар) нурланыш авыруын белмиләр иде, «елга авыруыннан үлде», дип әйтәләр иде. Күршебез Саҗидәнең әнигә сөйләгәнен хәтерлим - ахырысы, авариядән соң, аларны Мәскәүгә алып киткәннәр, анда аннан «Елга авыруы» тапканнар, арка миеннән пункция алганнар... 1992 елда ул бугаз рагыннан үлде...

Бөтен классыбыз белән бер кыз өчен борчылуыбыз истә калган. Анда ак кан авыруы, ягъни, лейкемия иде. Аны Мәскәүдә дәваладылар, ул аннан иптәш кызларына хатлар яза иде. Ул кыз үзенең үләсен белә иде һәм 18 яшендә үлде... Мин инде аның исемен дә, фамилиясен дә хәтерләмим, Ленин урамында торганын гына беләм. Безне ул чагында аның үлеме тетрәндергән иде...

Мөслим мәктәбенә һәр елны ФИБтан (Физика-Биология институты филиалы) врачлар килеп, тикшерүләр үткәрәләр иде. Истә калганы шул - авыз эчендә микрофон кебек нәрсә тотасың, һәм ул прибор нидер күрсәтә. Безгә аның нәрсә икәнен әйтмәделәр, әмма олыларның сөйләве буенча, бездә шулай нурланышны тикшерүләрен аңладым. Мөгаен, ул дозимер булгандыр. Төгәл генә әйтә алмыйм...

Кешеләрнең бик күп үлүләре истә калган. Моның сәбәпчесе - елга, дип сөйлиләр иде. Мин үскән урам зур түгел, ике урамны - Ленин һәм Пушкин урамнарын тоташтыра. Анда нибары 12 йорт иде, ягъни, 12 гаиләгә 70ләп кеше яши иде. Минем күз алдымда гына да 31 кеше үлде - ике айлык баладан башлап, өлкәннәргә кадәр... Бу - 12 гаилә өчен коточкыч сан. Үлүчеләр арасында 70тән узган бер генә кеше дә юк иде, белүемчә, үлүчеләрнең 20се 50 яшькә кадәр иде...

Теча елгасы, дигәндә, мин менә шуларны хәтерлим.... Минем өчен бу - куркыныч сүз...

Минем әнием, чыгышы белән Хуҗина Земфира, озак яшәүчеләр гаиләсендә туган. Аның әтисе Фазлый бабай 84 яшендә үлгән. Бабайның кыз туганнары барысы да 90 яшьтән артык яшәделәр, берсе 97 яшендә үлде. Минем әбием Мәгъфүрә 1911 елда туган, әле дә исән, начар йөрсә дә, Коръәнне күзлексез укый. Ягъни, минем әнием физик яктан нык, сау-сәламәт гаиләдә туган. Әмма балалар үскәндә, алар нәкъ Теча елгасы ярында яшиләр, аннан соң да елгадан ерак күчмиләр. 1949 елда әнигә 12 яшь була, ул елгадан эчәр өчен һәм кирәк-яракларга ничек итеп су ташуы турында еш сөйли иде. Ул елгада кер чайкаган, су кергән. Шунда ук сыерлар йөргән, каз-үрдәкләр йөзгән. 1968 елдан башлап минем карт әбием үзенең 4 баласын, бабайны һәм оныгын, бер киявен, ике киленен җирләгән... Аларның күбесе авырып үлгән.

Карт әбиемнең балалары:

1. НУРИӘХМӘТ - 62 яшендә үпкә рагыннан үлде, аның хатыны 1989 елда үлде;

2. ЗАН - Үзбәкстанның Алмалык шәһәрендә, 36 яшендә, бронхлардан үлде;

3. ЗЕМФИРА (минем әнием) - 62 яшендә үлде. Аның ашказаны асты бизе эшләүдән туктады.

4. РИФКАТЬ - 51 яшендә йөрәк авыруыннан үлде.

Аларның һәрберсенең авыруы төрле, боларны берничек тә нәсел авыруы, дип әйтеп булмый. Бу нәселдә кешеләрнең гомере кыскарганнан-кыскара бара. Минем үземдә дә көчле анемия, канымда эритроцитлар күп.

Минем әтием РӘХМӘТУЛЛИН ШӘЙДУЛЛА, гаиләдә икенче бала була. Аның олы абыйсы 1949 яки 1950 елны 19 яшендә үлә, әтинең әйтүе буенча, ниндидер үпкә авыруыннан. МИНЕМ ӘТИ 1999 ЕЛДА, 68 ЯШЕНДӘ, ҮПКӘ РАГЫННАН ҮЛДЕ. Аның энесе Кәрәмәтулла 57 яшендә инсульттан үлде. Аннан алда гына аның 23 яшьлек улы Мөхтәр бөере авырып үлгән иде. Әти ягыннан әбинең калган 7 баласы хәзергә исән, әмма бу озакка барырмы - бер Алла белә...

Минем әтием ягыннан әбием Заһурә 1911 елда туган һәм хәзер дә исән. УЛ БАБАЙНЫ, ӨЧ БАЛАСЫН, ИКЕ ОНЫГЫН ҖИРЛӘДЕ... Әби үзе озын гомерле булды, әмма аның балалары иртә үләләр, ә оныклары исә тагы да яшьтән китәләр...

Минем әти-әнием 1955 елда өйләнешкәннәр һәм икесе дә бер елда - 1999 да үләләр... Әни әтидән 4 кенә ай артык яшәде. Алар гомер буе авырдылар. Бөтен авыруларын хәтта санап та бетереп булмый...

Әти 1999 елда инсульт кичерде, аңына килеп йөри башлады, әмма гел авырды. Үпкәсе шешкән, дип диагноз куйдылар. Без бары тик 1998 елның маенда гына анда үпкә рагы икәнен белдек. Анда нурланыш авыруы булуы турында 1999 елның февралендә, үлеренә 20 көн калгач кына документ килде, һәрхәлдә, без белешмәләрне 1998 елның маенда ук аларга җибәргән идек. Әти бик газапланып үлде, наркотиклар җитмәде, мөгаен, ул аларга инде ияләнгән дә булгандыр. Ул балалары, карт анасы һәм хатыны күз алдында җан бирде...

Минем әнием - Земфира гомер буе авырды, ләкин врачлар беркайчан да аңа җитди диагноз куймадылар, киресенчә, үлеренә бер ел кала, аңа авыруының радиация белән бәйләнеше юк, дигән белешмә бирделәр. Гипертония, үт куыгы, бөерләр һәм үпкәләр - болар барысы да әнинең авырулары. Һәр елны, кайвакытта, елына икешәр тапкыр, ул

ФИБта дәваланды, алар язып биргән даруларны эчте. 1999 елның июнендә аны, үпкәсе шешкән, дип, өлкә больницасына салдылар, әмма бөтен эчен шеш басканын белделәр. Әнигә ашыгыч операция ясадылар, чөнки үте кинәт күп таралу сәбәпле, аның ашказаны асты бизе эшләми башлаган иде. Әнинең ашказаны асты бизен алып ташладылар, әмма бу ярдәм итмәде, ул ун көннән үлде... Аңа әле 62 яшь тә тулмаган иде...

Әти белән әнинең 42 ел уртак тормышта биш балалары туа. Бүгенге көндә шуларның өчесе исән.

Мин иң олысы, 1956 елның 14 июлендә тудым. Миндә хроник пиелонефит, йөрәк чире, тамыр-буын авырулары, хәтта сау-сәламәт тешләрем дә коела, һәрвакыт аңкавым шешә, бик тиз арыйм һәм хәлсезләнәм.

Гаиләдә икенче бала Фәрит иде, ул 1958 елда туды һәм 1992 елда 34 яшендә үлде. Аның йөрәге авыру иде, йөрәге кан әйләнешен көйли алмый башлады һәм нәтиҗәсе үлем белән бетте. Шушы көнгә хәтле мин туганымны югалту кайгысы белән килешә алмыйм, үз йөрәгем дә гел яралы...

Өченче туганым Рафит 1959 елда туды. Ул бала чакта да бик күп авырды, хәзер дә авыру. Аның гипертония кризислары була.

Дүртенче туганыбыз Эльвира иде. Ул 1961 елның 23 февралендә туды һәм шул ук елның 9 маенда үлде. Диагнозы - тумыштан йөрәк чире.

1962 елда Венера сеңелебез туды. Аның һәрвакыт башы авырта, бронхит. Әмма яхшы итеп тикшерү үткәне юк.

Минем 8 туганнан туганым арасында бер генә сәламәт кеше дә юк, алар турында «Мондыйларны космонавтлыкка алмыйлар», диләр. Космонавтлыкка түгел, алар армиягә дә яраксыз. Туганда ук патология белән - җенес органнарында шеш, кан басымы, күз авыруы һәм башка чирләр белән туучылар бар.

Мин, ХӘЯТОВА ГӨЛФИРӘ ШӘЙДУЛЛА кызы (тумышым белән Рәхмәтуллина), 1957 елны ХӘЯТОВ РАФИТ МӘҮЛЕТ улына кияүгә чыктым. Иремнең ата-анасы рактан үлделәр. Әтисе Хәятов Мәүлет - бронхлар рагыннан, әнисе Хәятова Мөхтәрәмә - туры эчәктә рактан. Ул шулай ук шикәр чире белән авырды, үпкәләре сәламәт түгел иде.

Минем 42 яшьлек ирем инде 4 операция кичерде, бишенчесен тәкъдим иткәннәр иде, без баш тарттык.

Беренче операция - 1991 елның апрелендә ашказанына;

Икенче операция - 1991 елның октябрендә ашказанында кислота ясый торган бизен алдылар;

Өченче операция - 1997 елның ноябрендә ашказанына һәм эчәгесенә;

Дүртенче операция - 1999 елның маенда умыртка баганасына.

Ул хәзер дә гел авырый, әмма ФИБ врачлары аның бу авыруларын радиация белән бәйле түгел, дип исбатлыйлар. Шуның өстенә, аңа әле яшь чакта ук хроник бронхит, дигән диагноз куелган булган.

Безнең өч балабыз бар.

Зур улыбыз Артур 1976 елны туганда ук патология белән туды. Аның уң як бөерендә дифлозий, ягъни, аның уң як бөере үсмәде, әчтерхан чикләвеге зурлыгында гына калды, ә сулы үсте. Шулай ук аңа пиелонефрит диагнозы куелды. Хәзергә аның кан басымы әйбәт, врачлар барысы да яхшы булыр, диләр. Әмма аның кан басымы үзгәрә башлауга, аңа операция ясарга кирәк булачак. Мин аның гомере өчен бик куркам. Теләсә нинди вирус, инфекция, агулану яки көчле дару төзәтә алмаслык хәлгә китерергә мөмкин.

1980 елгы кызыбыз Юлия кардиологка хисапка басарга тиеш. Аның йөрәге башка кешеләрнеке кебек урнашмаган, ул бер якка кыйшайган. Врачлар әйтүенчә, аның йөрәгендә ишемия авыруы башланырга мөмкин. Аның бөерләре дә киңәйгән.

1982 елгы улыбыз Дениста күренеп торган патология юк, әмма аның иммун системасы бик зәгыйфь. Ул бик еш авырый, бер генә эпедимияне дә калдырмый.»

Менә шундый нәсел, гаилә тарихы, туу һәм үлем, авыру тарихлары... Рактан газапланып үлгән ата-аналар, аларның чак өстерәлеп йөргән балалары, авыш йөрәк, черек бөер белән туган оныклары... Истәлекләрнең ахырына больницалардан төрле белешмәләр, үлем таныклыклары теркәлгән...Һәм бер генә очракта да бу авыруларның төп сәбәпчесе итеп радиация күрсәтелмәгән, нурланыш диагно-

зы куелмаган, ташлама-льготалар бирелмәгән. Инде бөтен нәсел күз алдында череп, үлеп бара, врачлар исә һаман аларның үзләрен гаеплиләр, һаман атомчыларны яклыйлар, аларның җинаятьләрен каплыйлар. Кеше үлгәнче шулай сузалар, ә үлгәч мәеткә инде льготалар да, дарулар да, кайдадыр күчү дә кирәкми... Язмыш аларны тын гына авыл читендәге зиратка күчереп куя...

Ә «Маяк», «Маяк» нишли? Кешеләрне шулай газапланып яшәргә һәм тилмереп үләргә мәҗбүр иткән «Маяк» берләшмәсе ник бу хәлләрне күрми, үз корбаннарына ярдәм итми?! Ул бит хәзер миллиардлар белән эш итә - дөньяның 15 иленә изотоплар сата һәм дөньяның күп илләреннән үзенә атом калдыкларын сакларга ала. Бу хәтле байлык, мөмкинлекләр белән, әгәр теләсәләр, алар Мөслим халкын айга күчереп куя алырлар иде, бу бичараларны дөньяның иң яхшы больницаларында дәвалап, үз гөнаһларын бераз булса да юа алырлар иде... Юк, «Маяк» боларның берсен дә эшләми, янәшәсендә генә үлеп яткан татар авылларын ул күрмәмешкә салыша, бу кырылуның радиация сәбәпле икәнен танымый. Ә намуссыз врачлар, өлкә һәм районның сатлык, лоббист түрәләре атомщикларны яклый, мөгаен, «Маяк»ның майлы калҗасыннан аларга да өлеш чыгадыр. Әмма ул өлеш башкача да килергә мөмкин бит - аларның үзләренә дә кара нурланыш булып, яман шеше булып, әҗәл чире булып... Тилмереп үлгән кешеләрнең күз яшьләре аларны да бер көн килеп тотарга мөмкин... Кеше кайгысында, кеше гомере хакына зур акчалар эшләп ятучылар болар турында уйлыйлармы икән?

Әмма, бик сирәк очракларда булса да, өлкәнең медицина учреждениеләре Мөслим татарларының үлем очракларын радиация белән бәйләргә мәҗбүр булалар. Шундый сирәк очракларның берсе Хөснетдиновлар гаиләсенә карый, шуңа күрә без бу нәсел тарихына да җентекләбрәк тукталып үтәргә булдык. Чөнки шушы гаилә мисалында бөтен авылның фаҗигасе чагыла һәм биредә яшәүчеләрнең барысы да, бернинди тикшерүләрсез, «Радиациядән зарар күргән» дип бәяләнергә хаклы. Менә ул гаиләнең яшәү һәм үлем тарихы:

ХӨСНЕТДИНОВЛАР ГАИЛӘСЕ

Гаилә башлыгы - ХӨСНЕТДИНОВ ГЫЙЛЬМЕТДИН НУРЕТДИН улы;

Аның хатыны - ХӨСНЕТДИНОВА РӘШИДӘ ЗАКИР кызы;

Аларның балалары - РОЗА (1952 елгы), ФӘРИТ (1953 елгы), МАРАТ (1956 елгы), МИДХӘТ (1958 елгы), МАРС (1960 елгы).

Гаилә 1951 елдан Мөслим станциясендә, Центральная урамында, 106нчы йортта яши.

Балалар Мөслим станциясенең 96нчы мәктәбендә укыганнар.

ВӘЛИЕВА РОЗА ГЫЙЛЬМЕТДИН кызы истәлекләреннән:

«Мин зур эшче гаиләсендә туып үстем. Без гаиләдә 5 бала идек. Бер күренеш истә калган. Миңа ничә яшь икәнен хәтерләмим, елның кайсы вакыты икәнен дә онытканмын. Әмма өлкәннәрнең бер хәбәрдән бик нык хәвефләнгәннәрен хәтерлим: Теча елгасындагы бөтен балык өскә калкып чыккан һәм яр буен тутырган иде. Ир-атлар ул балыкны өйләренә дә алып кайталар. Безнең ишек алдында да 3 балык эленеп торды, алар бик зур балыклар иде, чуртанмы, җәенме шунда... Без, балалар, барып, аларны тоткалап та карадык. Әмма ул балыкларны беркем дә ашамады. Аннан, берничә ел рәттән, Мөслим участок больницасыннан безнең урамга кызыл тәреле машиналар килә башлады. Өлкәннәр ул вакытта өйдә юк, барысы да тимер юлда эшли, иртән китәләр, кич кенә кайталар. Балалар исә үзләре генә кала. Машинага 5-6шар бала утыртып, станциядән 5 чакырым читкә алып китеп, безне үлчиләр, тикшерәләр, авызларыбызны ачтыралар, тагы әллә нәрсәләр... Аннан без җәяү өйгә кайтып китәбез, машина исә яңа төркем балаларны алып килә. Нигәдер, өлкәннәрне тикшермәделәр, балаларны гына карадылар. Врачлар чит кешеләр - руслар иде, чөнки безнең участок больницасында, нигездә, татарлар һәм башкортлар гына эшли. Бу врачлар кайдандыр килгән булырга тиешләр. Әмма безгә дә, безнең әти-әниләргә дә беркем бернәрсә аңлатып тормады.

Әти 1951 елдан 1988 елга кадәр тимер юлда эшләде. Аның эш стажы - 37 ел, әнинеке - 26. Шундый зур гаиләне ашату өчен, мал-туар тотарга да туры килде. Эшчеләргә махсус печән чабу урыннары бирелмәгән иде, шунлыктан, печәнне Теча елгасы тугайларында әзерләделәр. Башта бу эш тыелган иде, елга милициясе печәннәрне дә яндырып йөрде, штрафлар салалар иде. Елга буенда печәнне, нигездә, тимер юл эшчеләре чаба иде. Чөнки колхоз һәм совхозларда эшләүчеләргә печәнлек җирләр бирәләр, ә тимер юлчыларга - юк. Шуңа күрә тыелган урыннарда «урлашып» чабарга туры килә иде. Ә инде 1985 елдан соң, Көньяк Урал атом электростанциясен төзәргә агитация башлангач, Теча елгасы буйларында бөтен кешегә печән әзерләргә рөхсәт иттеләр...

1969 елны мин укырга Курган өлкәсенә киттем, анда эшләдем, кияүгә чыктым, анда кызыбыз Эльмира һәм улыбыз Илдар туды. 1987 елда кабат туган якларга әйләнеп кайттык, безне нәкъ елга буена, 101 км дагы тимер юл күпере янына урнаштырдылар. Ә ул урын радионуклидлардан иң нык зарар күргән җир булып чыкты. Бу радиациягә иялəнү 1,5-2 ел буе барды. (Без барып тикшердек - ул урында радиация хәзер дә 1500 мкр/ч, бу - нормадан мең тапкыр артык, дигән сүз. Ф. Б.)

Эштән өйгә кайтканда, мин үзем дә, ирем дә хәлсезлек, баш әйләнүе тоя башлый идек. Ярты юлга җиткәндә, аяклар тотмый башлый, утырып, ял итәргә туры килә, аннан соң гына юлны дәвам итәсең. Өйгә кайтып җиткәч, диванга ава идек. Сине курку биләп ала, әйтерсең лә, югарыдан упкынга очасың...

Мин үзем башта медицина учреждениеләренә күренмәдем, ә ирем Вәлиев Рәхимҗан Чиләбегә тикшерелергә барды. Аңа, барысы да яхшы, дигәннәр. Ул чагында кызыбыз Эльмирага - 10, улыбыз Илдарга 9 яшь иде. Бер елдан икесендә дә анемия таптылар, алар Курган өлкәсеннән саусәламәт килгән балалар иде...

Тагы бер елдан, ягъни, 1988 елда, улыбызның мантуга уңай реакция булды. Өч ел рәттән шулай. Аннан соң ул Чиләбедә туберкулез диспансерында ятты, ике ай Миасста санаторийда булды. Менә берничә ел инде ул туберкулез дис-

пансерында хисапта тора. Хәзер улыбызда гастрит, гайморит, гепатит... Ике балабызның да организмы бик зәгыйфь, иммунитет нольгә тигез.»

ЕЛГА БАШЫ — НӘСЕЛ БАШЫ — АВЫРУ БАШЫ:

«ХӨСНЕТДИНОВ ГЫЙЛЬМЕТДИН НУРЕТДИН улы.

193О елның 15 январендә, Мөслим авылында туган. 1955 елдан күкрәге авыртуга зарлана башлый. Чиләбе туберкулез диспансерында, ФИБта, тимер юл больницасында ята. Хәле яхшырмый. 1997 елның февралендә үпкәсендә рак табалар. 1997 елның 17 декабрендә, 67 яшендә үлә.

ХӨСНЕТДИНОВА РӘШИДӘ ЗАКИР кызы.

1931 елның 15 маенда Мөслим авылында туа. 30 ел буе врачларда хисапта тора. Диагнозы: гипертония. 1999 елның 10 январендә беренче инсульт кичерә, шул елның 10 августында икенче инсульт була. Ике атна телсез ята. 1999 елның 23 августында 68 яшендә үлә.

ХӨСНЕТДИНОВА (ВӘЛИЕВА) РОЗА ГЫЙЛЬМЕТДИН кызы.

1952 елда туа. 1993 елда аналыгында миома табалар, 1994 елда операция ясыйлар. 1995 елда авыз эчендә киста табалар, операция ясыйлар. Бик еш авырый, башы сызлый, тиз салкын тия, көчле хәлсезлек, ябыклык, авырлык җитмәү.

ХӨСНЕТДИНОВ ФӘРИТ ГЫЙЛЬМЕТДИН улы.

1953 елда туа. Яшь чагыннан ук гастрит була, кырык яшьтән соң гел салкын тиеп чирли. Моның өстенә, анда остеохондроз. Фәритнең 1978 елгы улында - пилонефрит, 1980 елгы кызында - гастродуанит.

ХӨСНЕТДИНОВ МАРАТ ГЫЙЛЬМЕТДИН улы.

1956 елның 10 февралендә туа. Туганда, аягында алты бармак була. 5-6 яшендә аңа операция ясыйлар. 1998 елда Маратта тире рагы табалар. 1998 елның декабрендә аңа беренче операция ясала, 1999 елда - икенче операция була. 2000 елның февралендә ул 43 яшендә үлә. Аның ике кызында да - гастродуанит һәм анемия.

ХӨСНЕТДИНОВ МИДХӘТ ГЫЙЛЬМЕТДИН улы.

1958 елда туа. 4 ел гаиләсе белән Теча елгасы буенда, 101 км да яши. Берничә ел рәттән хроник панкреатит белән

һәм врачлар аңлата алмаган авыру белән авырый. Ул эшли башласа, ягъни, аз гына көч куйса, шунда ук температурасы күтәрелә, тәнендә авырта торган йомшак шешләр барлыкка килә. Тикшерүләр бернинди нәтиҗә бирми. Аның хатыны Рамиләдә - анемия, врачларда хисапта тора, 16 яшьлек кызларында - гастрит.

ХӨСНЕТДИНОВ МАРС ГЫЙЛЬМЕТДИН улы.

1960 елгы. 90нчы елларда яшәү өчен Саратовка күчеп китә. Анда берничә ай яши. Әмма организмы ияләнә алмый. Анда башка төр радионуклидлар белән пычранган территория була, һәм врачлар киңәше белән, Марс яңадан Чиләбе өлкәсенә әйләнеп кайта. Соңгы вакытта аның бөерләре, буыннары авырый. Ике кызында да зәгыйфь иммунитет.

ИСХАНОВА (ВӘЛИЕВА) ЭЛЬМИРА РӘХИМҖАН кызы.

1977 елда туа. 1987 елдан Мөслим станциясендә яши. 8 ел Теча елгасы буенда, елгадан 100 метр ераклыкта яши. Берничә елдан анда анемия табалар, аның бугаз бизләре дә зурайган, буыннары авыру.

ВӘЛИЕВ ИЛДАР РӘХИМҖАН улы.

1978 елгы. Тубдиспансерда хисапта тора, гастродуанит, ашказанында әчеткеч түбән, анемия. Иммунитет нольгә тигез.

ИСХАНОВА ДИАНА РӘИС кызы (Эльмираның кызы) - 1997 елгы. Диагнозы анемия».

Бу - бер нәселнең нибары 70 еллык тарихы.... Радиациядән газап чигүче дүртенче буын... Әби-бабалар инде рактан гүргә кергән, ата-ана, туган-тумача больницадан чыгып тормый, операция арты операция ясата, оныклар больницаларда хисапта тора, ә дүртенче буын - 7 яшьлек Дианада инде тумыштан анемия, хәлсезлек, көчсезлек... Дөресен әйткәндә, боларның барысында да бер диагноз - бабалары һәм этиләре Гыйльметдин абзыйда булган радиация чире, нурланыш авыруы. Бу - бер Хөснетдиновлар нәселендә генә түгел, бөтен Мөслим авылында шулай, әмма врачлар, мең төрле башка диагноз куеп, нурланышны, ракны, радиация нәтиҗәләрен яшерергә тырышалар. Әйткәнебезчә, бик сирәк очракларда, үлер алдыннан яки үлгәч кенә, авыру-

ның дөрес сәбәпчесен күрсәтергә мәҗбүр булалар. Хәзер сезнең игътибарга шундый бер тарихи белешмәне тәкъдим итәбез. Ул Хөснетдинов Гыйльметдин абзый үпкә рагы белән үләргә нәкъ 20 көн кала, 1997 елның 28 ноябрендә, Чиләбе шәһәре өлкә клиник больницасында, эксперт советы тарафыннан бирелә.

*«РЕШЕНИЕ ЭКСПЕРТНОГО СОВЕТА*

*Региональный Межведомственный Экспертный Совет на заседании № 13 от 11.11.97 г. рассмотрел представленную медицинскую документацию на Хуснутдинова Г. Н., 1930 года рождения, проживающего на территории, загрязненной радионуклидами, об установлении причинной связи заболеваний (смерти) с радиационнымы и другими неблагоприятными факторами воздействия в результате радиационной аварии (или выполнения работ) на ПО «Маяк».*

*УСТАНОВЛЕН ДИАГНОЗ: Центральный рак верхней доли левого легкого Т4 № 2МО.*

*ЗАКЛЮЧЕНИЕ: Заболевание (инвалидность) связано с радиационным воздействием во время проживания на территории, загрязненной радионуклидами в результате радиационной аварии на ПО «Маяк».*

*Председатель МЭС ТЮКОВ Ю. А».*

Әйткәнемчә, менә шундый белешмәне, ягъни, «Маяк»та булган авария сәбәпле, радиациядән зарар күрде, дигән документны бүген тикшермичә дә ҺӘР МӨСЛИМЛЕГӘ бирергә була, чөнки аларның барысының да бу хәтле авыруларының сәбәпчесе - «Маяк» берләшмәсе, радиация. Күргәнебезчә, кайбер очракларда хөкүмәт, соң булса да, бу татарларның радиация сәбәпле үлүләрен танырга мәҗбүр. Әмма исәннәр өчен мондый ташланма юк. Татар, кайда да, үзенең хаклы икәнлеген үлеп аңлатырга тиеш... Бигрәк тә - Россиядә... Мөслим авылы бүген дә радиациянең нәкъ үзәгендә - Теча елгасы буенда утыра. Без үз күзләребез белән күрдек - радиация 100 - 1000, хәтта 1800 мкр/ч булган урыннарда маллар йөри, малайлар елгада балык тота, кешеләр яши... Ә кая барсыннар? Кешеләр шун-

дый шартларга куелган - алар өчен Россиядә башка җир, башка су, башка тормыш табылмаган... Без Мөслим җирле үзидарәсендә башка урынга күчерүне сорап язган йөзләгән гариза күрдек, алар арасында хәтта 10 кешелек ишле гаиләләр дә бар иде... Нинди зур фаҗига - кеше үз теләге белән туган җирләрен ташлап китәргә гариза яза, үтенә, китүне өмет итә... Моннан йөз ел элек, патша Россиясенең җәберләренә түзә алмыйча, бер төркем татарларның Төркиягә күчеп китүләрен хәтерләтә бу күтәрелеш... Әмма кешеләрнең үзләре кубарылып чыгып китәргә акчалары юк, чөнки күпләр 1100 сум пенсиягә яшиләр. Авылда эш юк, яшьләр юк-бар акча өчен көн дә Чиләбегә барып йөрергә мәҗбүрләр. Атом радиациясе сәбәпле, авылның 431 гектар сөрү җирләре, 336 гектар печәнлек-болынлыклары, 95 гектар көтүлек җирләре яраксызга чыгарылган - анда үле зона. Шулай итеп, гомер буе җирдә яшәгән, җир белән тамагын туйдырган авыл халкы бүген җирсез дә, сусыз да калган, чөнки радиациянең туфракта 300, хәтта 1000 ел буе саклануы билгеле... Татарларның тормышларын җәһәннәмгә әйләндергән «Маяк» берләшмәсе, Россия хөкүмәте, бу халыкка бер тиен ташлама бирмәс өчен судларга хәтле барып җитә... Үз халкыңны шул хәтле куралмас өчен, аларның газабына җансыз, битараф калу өчен кем булырга кирәктер?!

Шушы хәтле зур гаделсезлеккә, атом геноцидына каршы ярсып көрәшкә ташланган фидакарь җаннар да яши Мөслим авылында. Шуларның берсе һәм беренчесе - Мөслим участок больницасы баш врачы ГӨЛФӘРИДӘ ГАЛИМОВА. Шушы авылда туган кыз бала, соңыннан Чиләбедә яшәп, югары медицина белеме алса да, эшләргә туган авылы Мөслимгә кайта. 1981 елдан ул Мөслим участок больницасында акушер-гинеколог булып эшли башлый, 1986 елдан больницаның баш врачы була. Авылдашларының шул хәтле күп үлүләре Гөлфәридәне тетрәтә, ул моның аерым сәбәпләрен эзли башлый. Әмма ул кайда гына мөрәҗәгать итсә дә, аның шик-шөһбәләрен юкка чыгарырга тырышалар, имеш, бер нинди куркыныч юк, халык гомуми авырулардан үлә, авыру һәм үлүләренә кешеләр үзләре гаепле... Яшь врач моның белән килешергә теләми, ул Чил-

әбе, Новосибирский врачлары һәм галимнәре белән элемтәгә керә, авыл халкын махсус тикшертә башлый. Ул арада 1986 елда дөньяны Чернобыль трагедиясе тетрәтә, нурланыш, радиация турында хәбәрләр Мөслимгә дә килеп җитә. 1989 елда Гөлфәридә Галимова үз авыруларының яшерен мәгълүматларын ачуны таләп итеп, Чиләбенең биофизика институты филиалына (ФИБ-4) мөрәҗәгать итә, әмма бу белешмәне бары тик 1992 елда гына алуга ирешә. Бу мәгълүматлар котчыгарлык була - ГӨЛФӘРИДӘ ГАЛИМОВА БОЛЬНИЦАСЫНДА ЯТКАН 1216 КЕШЕДӘ НУРЛАНЫШ АВЫРУЫ БУЛГАНЫ БИЛГЕЛЕ БУЛА... Авыл врачының мондый активлыгы Россиянең шымчылык органнарына охшамый, чит ил галимнәре белән аралашкан өчен, аны хәтта дәүләт серен ачуда гаеплиләр, эшеннән читләштереп торалар. Әмма үз халкын өзелеп яраткан, аны» белән бергә чирләгән һәм газап күргән татар хатыны берни алдында да туктап калмый - ул бөтен киртәләрне җимереп, кешелек дөньясына мөрәҗәгать итәргә, Мөслим фаҗигасе турында хәбәр бирергә өлгерә. Гөлфәридә Галимова ярдәмендә 1992 елда төбәктә «Движение за ядерную безопастность» оешмасы төзелә, аңа хәтле «Кыштым-57» оешмасы эшли башлый. Соңыннан аның катнашында авылда «Ак тычканнар», «Атом тоткыннары» хокукый-экологик оешмалар барлыкка килә. 1989 елда Гөлфәридә Галимова Киев шәһәрендә узган чернобыльчеләрнең беренче съездында катнаша, 1993 елда Алма-Атада атом-төш афәтенә каршы уздырылган зур халыкара конгресста катнаша, 1994 елда Брянский, Красноярский шәһәрләрендә үзе кебек үк фидакарьләр белән очраша, Мөслим фаҗигасе турында сөйли, кешеләрне бу афәттән кисәтә.

Киң җәмәгатьчелек эшчәнлеге белән бергә, Гөлфәридә Галимова фәнни-практик эшчәнлеген дә туктатмый. Ул Новосибирский галиме, генетик Нина Александровна Соловьева белән берлектә, «Мөслим синдромы» дигән проект өстендә эшли һәм аның өчен Грант ИСАР ала. Бу тикшерүнең төп максаты булып нурланыш алган гаиләләрдә балаларның генетик яктан кан үзгәрешен өйрәнү тора. Тикшерүләр нәтиҗәсе сискәндерерлек була - мондый балаларда геннар үзгәреше өч ярым тапкырга артыграк булуы

ачыклана! 29 процент тикшерелгән халыкта, радиация тәэсирендә, хромосом үзгәрешләр барлыкка килгәне билгеле була. «Мөслим синдромы» шуны күрсәтә - радиация афәтенә эләккән кешеләрнең генетик статуслары үзгәрә, нәсел чирләре һәм хроник патология, ягъни, тумыштан гариплек барлыкка килә, бу авырулар аларның балаларына, оныкларына, бөтен нәселгә дә тапшырыла...

Авыл врачы Гөлфәридә Галимова сөйләгәннәрдән:

«Америка радиобиологы генетик Джон Гофман исәпләвенчә, ана карынында ук нурланыш алган кешенең гомер буе генетик тамгасы кала. Мондый кеше өчен күзәнәкләрнең генетик яктан нык үзгәреше хас, бу исә йөрәк һәм тамыр, психик, нерв авыруларына китерергә мөмкин.

Безнең илдә исә кеше сәламәтлегенең радиациягә мондый бәйлелеге исәпкә алынмады. Беричә ай элек кенә бөтенесен үз урынына куя торган приказ барлыкка килде. Медицина җитәкчелеге, ниһаять, таныды - Саша Морозовтагы кебек акыл зәгыйфьлеге (микроцефалия), ягъни, минең кечерәюе бала ана карынында вакытта аналары радиация алган кешеләрдә күзәтелә икән.

Үземнән исә шуны өсти алам, әтисендә хроник нурланыш булса, бала да каты авыруларга дучар була. Яңа Корман авылында хроник нурланыш белән авыручы Фәйзулла Фәйзуллинның 1985 елда улы Рәмзис туа. Соңрак бу бала бик көчле баш авыртуыннан зарлана башлый, йокысызлыктан интегә. Тикшерү нәтиҗәләре шуны күрсәтә: балада гидроцефалия булып чыга, ягъни, минең бер өлешен су алып тора. Баланы Чиләбедәге белгечләргә дә күрсәтеп карыйлар, әмма алар бернишли алмауларын әйтәләр.

Шушы ук Яңа Корманда, авыл урамында, инвалидлык арбасына утырган бер яшь кешене очратырга мөмкин. Ул - Рамил Габдуллин, 1963 елгы. Аның әтисе Нәсиб Габдуллин - хроник нурланыш авырулы, әнисе үлгән, Рамилне башта әбисе караган, әмма ул да үлгән. Хәзер Рамилне авыру әтисе һәм үги әнисе карый. Аны интернатка да җибәреп булмый, чөнки церебраль параличлы балалар өчен андый интернат юк.

Шундый ук авыру Мөслим авылында да бар, ул - Рафит Фәхретдинов, 1985 елгы. Балада тумыштан патология иде,

ул церебраль параличлы. Һәр җәйне аны Чиләбегә, махсус санаторийга илтәләр. Бала үзен биредә калдырып китkән әнисенә: «Мине биредә үләргә калдырасың», дип әйтә... (Александр Тихоновның «Муслюмово - деревня на ядерной свалке» дигән китабыннан. Чиләбе, 1995 ел, 7 бит.)

Әмма, ни кызганыч, Гөлфәридә Галимованың больницасын ябарга җыеналар. Тирә-юньдәге 5 мең рак, нурланыш авырулы кешеләргә бер участок больницасы бар, хөкүмәткә хәзер ул да кирәк түгел. Аны фәкыйрьлек чигенә китереп терәгәннәр, ташлаганнар, онытканнар. Бу больница да ябылса, кешеләргә урамда тәгәрәп үләргә генә кала... Россия хөкүмәте, «Маяк» берләшмәсе кешеләр өстеннән менә шундый җинаятьчел тәҗрибә алып бара, аларның үлеп бетүләрен читтән тыныч кына карап тора...

Әмма кешеләрнең, тәҗрибә тычканнары кебек, тыныч кына бу дөньядан китәселәре килми. Алар яшәү өчен тиңе булмаган көрәш алып баралар, «Маяк» белән судлашалар, төрле оешмаларга язалар, бөтен дөньяга чаң кагалар. Хәтта баш миенең яртысында сулы капчык йөрткән, үзәк өзгеч авырулардан газапланган Рәмзис Фәйзуллин да үзен һәм авылдашларын яклап, Россия президенты Путинга һәм премьер-министр Касьяновка хатлар язган. Әмма Россия җитәкчеләре үзләре үк гарип калдырган 16 яшьлек татар баласына җавап биреп торуны кирәк тапмаганнар. Һәм Рәмзис, чит ил журналистлары аша, шушы хаты белән бөтен дөньяга мөрәҗәгать иткән. Менә ул татар баласының дөньяга әйтер сүзе:

*Россия Президенты Владимир Путинга.*

*Россия Федерациясе премьер-министры Касьянов әфәндегә.*

*Минем исемем Рәмзис Фәйзуллин. Мин инвалид булып тудым. Хәзер миңа уналты яшь, мин, үземнең яшьтәшләрем кебек, мәктәпкә йөрим, әмма миңа анда бик начар, чөнки мине балалар үртиләр. Мин бик еш авырыйм. Башкалар кебек булмаганым өчен минем күңелем рәнҗи. Минем башкалар кебек буласым килә, башкаларга охшыйсым килә. Минем кызлар белән йөрисем килә, әмма алар миннән читләшәләр һәм минем белән очрашудан баш тарталар. Мин үземә охшаган балаларым булуын теләмим.*

*Менә шуңа күрә мин чит илләрдән безнең җирләргә радиоактив калдыклар кертүгә каршы. Нигә министрлар һәм башка акча бик кирәксенгән кешеләр, ул атом станцияләрен Мәскәүдә яки Мәскәү өлкәсендә төземиләр соң?*

*Без радиациядән шул хәтле зур зарар күрдек, безнең авылда һәр атнаны кем дә булса рактан үлә. Атом калдыкларын илгә кертергә рөхсәт биргәнче, нигә парламент әгъзалары шушылар хакында яхшылап уйламыйлар икән? Зинһар өчен, безнең киләчәгебез хакында уйлагыз». («Это не жизнь! Жизнь, отравленная радиоактивными отходами.» «Гринпис», 2002, стр.10-11.)*

Һәм Рәмзис Фәйзуллин, эфир аша, чит илләрнең парламентларына атом калдыкларын Россиягә җибәрмәүләрен үтенеп, мөрәҗәгать итә. Әйе, Россия парламентариеләренең рөхсәте белән, инде Россиягә чит илләрдән атом калдыклары кертелә башлады. Аларны саклау һәм эшкәртү өчен туп-туры «Маяк»ка китерәләр, чөнки Россиядә бу хәте атом калдыгын сакларлык башка урын юк. Германия, Япония, Швецария, Болгария, Тайвань, Испания, Венгрия, Көньяк Корея, Чехия, Иран һәм Кытайдан Россиягә 20000 тонна атом калдыгы кертергә торалар. Россия моның өчен 20 миллиард доллар акча алачак. Бу акчаның бер өлешен зур түземсезлек белән «Маяк»та көтәләр, чөнки банкротлыкка чыгып барган атом калдыклары чүплеген, җимерекләрне шушы акчалар белән капламакчы, торгызмакчы булалар. Акчаның иң зур өлеше, әлбәттә, Мәскәүдә, атомчылар, сәясәтчеләр, яңа байлар кесәсендә калачак... Ә шушы атом чүплегендә яшәргә мәҗбүр булган Мөслим авылы халкына, Рәмзисләргә мәңге бетмәс авырулар, җан газаплары гына калачак бит!

Форсаттан файдаланып, без дә Рәмзис кебек, дөнья праламентларына, сәясәтчеләргә, зыялыларга мөрәҗәгать итәбез:

ЗИНҺАР ӨЧЕН, ҮЗЕГЕЗНЕҢ АТОМ КАЛДЫКЛАРЫГЫЗНЫ РОССИЯГӘ ҖИБӘРМӘГЕЗ!!! РОССИЯДӘ АЛАРНЫ САКЛАУ ӨЧЕН БЕРНИНДИ ДӘ ШАРТЛАР ЮК, МОННАН БАРЫ ТИК ХАЛЫК КЫНА ЗАРАР КҮРӘЧӘК! ӘГӘР «МАЯК» ТАГЫН ШАРТЛЫЙ КАЛА ИКӘН, УЛ ЧАГЫНДА БИРЕДӘ ЯШӘҮЧЕЛӘР ГЕНӘ

ТҮГЕЛ, СЕЗ ДӘ ЮККА ЧЫГАЧАКСЫЗ! ЧӨНКИ «МАЯК»ТАГЫ АТОМ КАЛДЫКЛАРЫ ИНДЕ БОЛАЙ ДА МИЛЛИАРДЛАР БЕЛӘН ҮЛЧӘНӘ, СЕЗ ДӘ КИТЕРЕП АУДАРСАГЫЗ, ҖИР БУ ХӘТЛЕ АГУНЫ КҮТӘРӘ АЛМАЯЧАК! БЕР ҖИРГӘ ШУШЫ ХӘТЛЕ АТОМ-ТӨШ МАТЕРИАЛЫН ТУПЛАРГА ЯРАМЫЙ, БУ БИТ БӨТЕН КЕШЕЛЕКНЕ, ҖИР ШАРЫН ЮК ИТҮГӘ КИТЕРЕРГӘ МӨМКИН! КИРЕСЕНЧӘ, «МАЯК»НЫ АШЫГЫЧ РӘВЕШТӘ ЯБЫП, АНДАГЫ АРТЫК АТОМ КАЛДЫКЛАРЫН БАШКА УРЫНГА КҮЧЕРҮ ТУРЫНДА УЙЛЫЙ БАШЛАРГА КИРӘК. СОҢЫННАН БИК СОҢ БУЛЫРГА МӨМКИН...

Шушы авылда туып үскән ирле-хатынлы тагы ике көрәшче турында сөйлисем килә, алар - үзләрендә нурланыш тамгасы йөрткән Госман һәм Рамилә(Миля) Кәбировлар. Хәзер алар Чиләбе шәһәрендә яшиләр, Госман Кәбиров - «Теча» экологик оешмасы рәисе, Мөслимдә әтисе исемендәге мәчетне булдыручы, хатыны Рамилә - «Айгөл» иҗтимагый оешмасы җитәкчесе. Алар ярдәмендә авылга күп кенә чит илләрдән галимнәр, сәясәтчеләр килгән, алар үзләре дә күп урыннарда булып, Мөслим фаҗигасе турында кешеләргә сөйлиләр, дөнья җәмәгатьчелеген атом афәтеннән кисәтәләр. Ирле-хатынлы Кәбировларның бу өлкәдә эшчәнлекләре санап бетергесез. Милләт үзенең менә шундый фидакарь, актив кешеләре белән яши, упкын чигенә килеп җиткәндә дә, өметен өзми, яшәү өчен көрәшә. Ә хәзер сүзне аларның үзләренә бирик.

МИЛӘҮШӘ КӘБИРОВА СӨЙЛӘГӘННӘРДӘН:

«Теча елгасы буенда кешесез калган зонаның чигендә үк - атом-төш чүплеге өстендәге иң беренче авыл - татар төбәге Мөслим урнашкан. Мин үзем әлеге авылда тудым. Әни һәм без - аның газиз балалары - атом-төш түрәләренең барлык ялгышлары өчен сәламәтлегебез белән түләдек. Ә бәлки әле алар өчен бу ялгыш та булмагандыр. Атом-төш җитештерү берләшмәсе турында карар кабул итүчеләр кешеләрнең язмышы, сәламәтлекләре һәм тормышлары турында кайгыртуны үзләренең бурычлары дип санамаганнардыр. Безнең гаилә мисалы очраклы хәл түгел, ә гадәти мисал гына.

1948 елдан башлап атом-төш калдыклары Течага чыга башлый. 1950 елны елгада су коенуны, аннан су алуны тыялар. Елга тирәсен тотып алып, яр буена милиционер да бастырып куялар. Әлеге милиционер минем әти иде. 2 елдан аңа «1нче дәрәҗә нурланыш авыруы» дигән диагноз куела һәм ул җиде елдан якты дөнья белән бәхилләште. Бу вакытта гаиләдәге иң кечкенә балага - миңа өч яшь булган. Шулай итеп без җиде бала үзе дә авыру әни кулында калдык. Безне ашатырга, киендерергә кирәк иде һәм әнигә карап торырга җиңел тоелган эш тәкъдим иттеләр. Ул шул ук Теча елгасында су сыйфатын тикшереп торучы булып эшли башлады. Ә без, билгеле, аңа булыша идек. Безгә моның куркыныч икәнлеген беркем дә аңлатып тормады, ә тикшерүгә алынган үрнәкләр өйдә, балалар ятагы астында сакланды. Нәтиҗәдә, безнең бишебездә нурланыш авыруы, ике абыебыз яман шеш авыруыннан үлде. Тик безнең гаилә дәүләттән бернинди дә ярдәм ала алмады.

Халык бик еш авырый башлады. Чөнки Мөслим авылында яшәүчеләрнең бөтен тормыш-көнкүреше төбенә радиоактив калдыклар утырган елга белән бәйләнгән. Әмма совет медицинасы авыл халкының авыруына нурланыш күләменең гадәттән тыш югары булуы сәбәпче икәнлеген ачарга теләмәде.

Дистәләрчә кеше яман шешкә охшаган авырудан үлде, ә табиблык документларына - гомуми авыру, дип яздылар. «Маяк» җитештерү берләшмәсендәге һәлакәтне кайчанга кадәр гади кешеләрдән яшереп тоткан булырлар иде икән? Монысын әйтүе кыен. Әмма 1986 елда Чернобыльдә фаҗига килеп чыкты. Бу һәлакәт киң җәмәгатьчелекнең аңын уятырга этәргеч ясады, иҗтимагый оешмалар барлыкка килә башлады. Вакытлы матбугатта радиация йогынтысында барлыкка килүче нурланыш авыруы турында ачыктан-ачык яза башладылар. Үзәк һәм чит ил матбугатында Мөслим фаҗигасе турында да язмалар күренде.

Шулай да, радиация җирле халыкның сәламәтлегенә артык зыян китермәде, дигән рәсми фикерне әле дә хупларга тырышалар. Тик дөреслекне җир астында яшереп тоту мөмкин түгел. Җирле хастаханә табибы Гөлфәридә Галимова үзенең авыруларын бәйсез диагностика үзәгендә тик-

шертүгә ирешә. Тикшерүләр нәтиҗәсендә яңа авырулар табылды.

Безгә иҗтимагый хәрәкәткә кушылганнан соң гына дөреслекне дәлилләү насыйп булды. 1992 елда «Атом-төш куркынычсызлыгы хәрәкәте» барлыкка килде. Ул Новосибирскийның генетика галимнәре белән бергә хезмәттәшлек итә башлады. Нурланыш алучылардан туган балаларның каннарына генетик тикшерү уздырылды. Нәтиҗәләр коточарлык иде, һәр дүртенче бала хромосомалар үзгәреше буенча мутант булып туган!

Минем ирем, «Атом-төш куркынычсызлыгы хәрәкәте» советы әгъзасы буларак, «Маяк» җитештерү берләшмәсен судка бирергә тәкъдим итте. Башта әни моңа кул гына селтәде. Янәсе, аларны җиңеп буламы соң?! Аннан риза булды. Без дөреслекне дүрт ел эзләдек. Гаиләбездәге барлык кешеләрне дә нурланыш тәэсирен өйрәнүче институтта тикшерделәр. «Маяк» белән тыгыз бәйләнештә эшләгәнлектән, әлеге институт бездәге авыруларны нурланышка бәйләмәү өчен бөтен көчен куйды.

Медицина һәм суд юлларында йөрү безнең күп нәрсәләргә күзебезне ачты. Дәүләт безнең җимерелгән сәламәтлегебез өчен җаваплылыкны үз өстенә алырга теләми икән бит. Үз хокукларыбызны үзебез яклап, бердәм булсак кына нәрсәгәдер өметләнергә була икән. Һәм без, дәүләт башбаштаклыгы корбаннары, берләшергә булдык. Безнең янга киңәш сорап кешеләр килә башлады. Алар арасында балалы хатын-кызлар да күп иде. Ул балалар «Маяк» җитештерү берләшмәсе эшчәнлегеннән зыян күрүче өченче буын вәкилләре. Шулай итеп, «Айгөл» иҗтимагый оешмасы туды. Мин аның җитәкчесе. Без нурланыш алган яки нурланыш тәэсирендә төрле авыруларга дучар балалары булган хатын-кызларны бергә берләштерәбез. «Айгөл» ай чәчәге дигәнне аңлата. Ни өчен оешманы әлеге исем белән атадык соң? Беренчедән, бу хатын-кызларга хас булганча бик матур яңгырашлы исем. Тик бу атамага күңелне өшетә торган икенче мәгънә дә салынган. Әлеге чәчәк гадәти чәчәкләр кебек кояш нурлары астында үсми. Ә атом-төш кышына охшаган өрәк сыман ак тынлык астында ачыла.

Без нурланыштан зыян күрүче гаиләләргә генетик тикшерү уздыруны дәвам итәргә булдык. Форд фондының

матди булышлыгы белән Россия Фәннәр академиясенең Вавилов исемендәге гомуми генетика институты белән килешү төзедек. Нәтиҗәләр галимнәрне дә аптыраашта калдырды - 1997 елда туган балаларның каннарында нурланыш тамгалары күренә. МОННАН БЕР ГЕНӘ НӘТИҖӘ ЧЫГАРЫРГА БУЛА - 50 ЕЛ УЗГАННАН СОҢ ДА ХАЛЫК НУРЛАНЫШ АЛУЫН ДӘВАМ ИТӘ!

Россия хөкүмәте күптән түгел илгә эшкәртү һәм озак вакытлар саклау өчен чит илдән радиацияле калдыклар кертү турында карар кабул итте. Шул уңайдан «Маяк» җитештерү берләшмәсе һәлакәте нәтиҗәләрен яңадан тикшерү урынлы булыр иде. Халыкның сәламәтлегенә өстәмә куркыныч тудырудан кем генә файда күрер икән?

Чиләбе өлкәсендә якынча 3 миллион 200 мең кеше яши. Шуларның миллион ярымыннан артыгы әйләнә-тирә мохитнең зарарлануы һәм радионуклидлы азык-төлекләр белән туклану сәбәпле, нурланыш тәэсирен һәрдаим сизеп тора. Халык шулай итеп сәламәтлек өчен гаять куркыныч урында яшәргә мәҗбүр. Эшкә яраксыз кешеләр, инвалидлар көннән-көн арта, монда яшьләрнең үлүе гадәти хәл була башлады. Табиблык тикшеренүләре халык арасында яман шеш авырулары, бала таба алмау, балаларда тумыштан гариплек арта баруын күрсәтә.

Радиациягә балалар аеруча сизгер. Нурланышның бик аз гына микъдары да балаларның сөякләре үсешен тоткарларга яки бөтенләй туктатырга сәләтле. Ә бу скелет үсешенең нормадан калышуына китерә. Тикшерү узган мәктәпкәчә яшьтәге һәм кече сыйныфларда укучы балаларның 70 процентында баш миенең дисфункциясе нәтиҗәсендә барлыкка килгән психик тайпылышлар күренә. Бу яшь буынны» һәм гаиләнең зур бәхетсезлеге.

Популяция һәлакәте үсә. Бу турыда генетика галимнәре дә кисәтә. Теча елгасы радиоактив матдәләр белән пычрануга 45 ел үткәннән соң халыкны тикшергәндә күзәнәкләрнең бозылуы ачыкланды. Ә бу аларның зур нурланыш алулары һәм эчке нурланыш нәтиҗәсендә радиация тәэсиренең һаман дәвам итүе турында сөйли. Шунысы аяныч, нурланыш балаларга әти-әниләренә караганда да күбрәк генетик зыян китергән.

Икенче Бөтендөнья сугышы геноцид тудырган булса, салкын сугыш экоцид - әйләнә-тирә мохитне җимерүгә кадәр барып җитте.

БЕЗ, АТОМ-ТӨШ ҖИТЕШТЕРҮ КОРБАННАРЫ, ҮЗЕБЕЗ ТУРЫНДА ДӨНЬЯГА БЕЛГЕРТЕРГӘ ТЕЛИБЕЗ, БЕЗ СЕЗДӘН ЯРДӘМ КӨТӘБЕЗ».

Әйе, Рамилә Кәбированың әтисе Нурмөхәммәт Шаһиәхмәтов авылда беренчеләрдән булып нурланышка дучар була һәм 1962 елда кан рагыннан үлә. Әмма анда рак һәм нурланыш икәнлеген үләр алдыннан гына әйтәләр, һәрхәлдә, бу диагноз ФИБ врачларына инде 1952 елда ук билгеле булса да... Бу хакта миңа Рамилә Чиләбе шәһәренең радиация тәэсирен өйрәнү институтына - ФИБка баргач әйтте. Ул әтисе җан биргән 13нче номерлы палатаны күрсәтте. Тәкъдирнең тетрәндергеч нәтиҗәсен карагыз - нәкъ шушы шушы больницада, нәкъ шушы 13нче номерлы палатада 1998 елда Рамиләнең әнисе Сәрвәр апа да җан бирә... Аның өстендә ниндидер яңа дару сынап карыйлар, һәм ул аны күтәрә алмый... Бу больницада, нурланыш авыруы буенча тикшерелеп, Рамилә үзе һәм аның ире Госман Кәбировлар да дәваланалар, әмма алар 13нче номерлы палатада ятудан кискен рәвештә баш тарталар. Рамиләнең әйтүенчә, ФИБта авырулар өстендә төрле яңа дарулар сынап карыйлар икән, аның әнисе дә ниндидер яңа дару эчкәннән соң йөрәге янып үлгән... Бу институт-больницаның үз серләре бик күп, биредә кешеләр өстендә төрле куркыныч тәҗрибәләр үткәрүләрен дә сөйлиләр. Радиациянең тәэсире биредә турыдан-туры кешеләр өстендә үткәрелә һәм өйрәнелә. Әле беркайда да сыналмаган көчле дарулар биредәге авыруларга бирелә икән, ягъни, алар үлмәсә, башкаларга да бирергә мөмкин, алар үлсә - радиациягә сылтыйлар... Радиациядән зарар күргән татар авыллары халкы да шушы больницада ята, аларның әйтүенчә, биредә үлгәннәрне ярып, бөтен эчке әгъзаларын алып калалар икән... «Күмәргә җип-җиңел гәүдәләре генә кайта», дип сөйләделәр безгә болар хакында Мөслим һәм Татар Караболагы авылларында...

Бу юлы да ФИБта радиацияле татар авылларыннан күп кеше ята иде. Без аларга милли һәм дини китаплар тарат-

тык, күчтәнәчләребезне бирдек, сораганнарына Коръән укыдык... Кем белә, аларның бәлки соңгы тапкыр Коръән тыңлауларыдыр, Аллаһ сүзләрен ишетүләредер... Алар безне тәрәзәләргә сарылып, моңлы карашлары белән озатып калдылар... Чыгып китәр алдыннан, Мөслим авылыннан 76 яшьлек нурланыш авырулы Хәсәнова Фәрзәнә әби, бәхилләшкән кебек, шигырь юллары әйтте:

Утырдым, кый, көймәнең читенә,
Карадым, кый, суның төбенә.
Су гына төпләрендә һич кара юк,
Ходай кушканнарга чара юк...

Безнең кулыбызга 1962 елны Мөслим авылы кешесе тарафыннан үләр алдыннан язылган бер бәет-мөнәҗәт тә килеп керде. Укучылар игътибарына аны да тәкъдим итәсебез килә, чөнки радиация сәбәпле үлгән милләттәшебезнең соңгы җан авазы бит ул...

## АВЫРУ ЗАРЛАРЫ

Озын көннәрдә, салкын төннәрдә,
Яткыза безне үлем хәлләре.
Якты дөньяда кала исмебез,
Күземне йомсам, күзләрем тала,
Бар якыннарым дөньяда кала...
Җәйләргә чыксам, йөрермен, дидем,
Хуш исләр иснәп, терелермен дидем.
Якты дөньяда йөреп туймадым,
Туймасам да мин мәңге тормамын...
Яхшылыгымны искә алыгыз,
Җомга көннәрдә хәер салыгыз.
Күңелем үсмәде, кулым бармады,
Хәсрәтләр, уйлар миннән калмады.
Авыр булса да дөнья көтәргә,
Читен хәл икән ташлап китәргә.
Ерак җирләрдән күрергә килегез,
Озатып калыгыз, фатиха бирегез.
Җаным чыкканда, янымда торыгыз,
Шәһәдәт белән үтсен, диегез.
Җан чыгулары кичләрдә булса,
Төннәр саклагыз, авырсынмыйча.

Тәнем-буемны үлчәп алыгыз,
Юып пакълагач, кәфен салыгыз.
Тәнем бик зәгыйфь, каты тотмагыз,
Кире кайтмамын, ашыктырмагыз.
Каберем өстенә таш утыртмагыз,
Агач утыртып, кошлар кундырыгыз.
Каберем өстенә үләннәр үссен,
Гүрем өстенә иманнар төшсен.
Хушландырыгыз зифа буйларым,
Бу дөньяларда актык туйларым.
Йокым килмәде озын төннәрдә,
Ризык җыймадым актык көннәрдә.
Иптәш калмаган, түшәк җәймәгән,
Күлмәк тегелгән акбүз җәймәдән.
Караңгы гүргә кемнәр кергезгән,
Кара туфракта черер бу тән.
Бигрәк уфтанам иптәшем юкка,
Куеп киткәннәр мәңгелек йортка.
Ялгыз калганмын, исән булыгыз,
Атна кичләрдә дога кылыгыз.
Юлдаш ит, Ходай, нурлы иманым,
Хәмед башладым ошбу сүзләрем.
Ядъкар итегез йомсам күзләре,
Бу дөньяларда соңгы сүзләрем.
Хәмед соңыннан сыгынам Аллага,
Салават әйтәм рәсүлуллага.
Ниләр языйым, бетте сүзләрем,
Сезләргә булсын якты сәламем...

ГОСМАН КӘБИРОВ СӨЙЛӘГӘННӘРДӘН:

«Мин сезгә бер сер ачарга телим. Теча елгасы тугайларында дөньяда тиңе булмаган тәҗрибә уздырыла. БУ ЭКСПЕРИМЕНТНЫҢ ТӨП МАКСАТЫ — ГАДӘТИ ШАРТЛАРДА ДАИМИ РӘВЕШТӘ НУРЛАНЫШ АЛЫП ТОРГАН КЕШЕЛӘР БЕЛӘН НИ БУЛАСЫН АЧЫКЛАУ. Чөнки атом-төш сугышыннан соң һәр исән калган кеше өчен махсус шартлар тудыра алмаячаклар. Әмма мин шуннан куркам, безнең үзебездән инде илнең генофондына куркыныч яныйдыр. Чөнки бу зонадан чыгып киткәннәр

мутантлар үрчетүне дәвам итәләр һәм радиациягә ияләнеп яшәүгә бернинди өмет юк. Үләселәр инде үлде, исәннәр исә үзләрендә радиоактив тамга йөртәләр - ул канда, дицентрик рәвешендә саклана. Элек генетик анализ ярдәмендә Чыңгыз-хан яки Тутанхамон нәселеннән булуыңны исбатларга була иде, хәзер исә күп мөслимлеләр үзләренең кем баласы яки атасы булуын да исбатлый алмыйлар. ДӨНЬЯ ҖӘМӘГАТЬЧЕЛЕГЕ ТЕЧА ЕЛГАСЫ ТУГАЕНДАГЫ ХӘЛНЕ ҮЗ КҮЗӘТҮЕ АСТЫНА АЛЫРГА ТИЕШ, ЮКСА, ИҢ КУРКЫНЫЧ ФИЛЬМНАРДАН ДА КУРКЫНЫЧ ХӘЛЛӘР БУЛЫРГА МӨМКИН. Бүгенге көндә «Маяк»та 1 миллиард кына түгел, 2 миллиаррд кюри атом калдыклары саклана. Хәзер чит илләрнең дә атом калдыкларын бирегә кертә башладылар. Безне, биредә яшәүчеләрне, чит ил долларларына сатып җибәрделәр... Җитәкчеләр «Маяк»та авария булганы юк, дип оятсыз рәвештә ялганлыйлар, әмма без белгәне генә дә анда 250 авария булган! Атомчылар, үзләрен аклау өчен еш кына: «Анда 2-3 кеше үлгән икән, шуннан нәрсә? Аның каравы без дөньяны атом сугышыннан саклап калдык», дип лаф орырга яраталар. Ә ул 2-3 үлгән кеше минем атам, туганнарым булса, нишләргә?! Россиянең атом бомбасы әле бер чит дошманын да үтермәде, ул Россиянең үз халкын - безне үтерде... Безнең өстә тәҗрибә үткәрделәр...»

Әйе, юрист, эколог-мәгърифәтче Госман Кәбиров дөрес, әмма коточкыч нәтиҗәгә килгән - Мөслим авылы халкы радиацияле зонада махсус, тәҗрибә үткәрү өчен тотыла. Россия хөкүмәтенең теләге булганда Мөслим халкын әллә кайчан башка урынга күчерергә була иде. Әмма аларны күчермиләр, аларны махсус күзәтеп, организмдагы үзгәрешләрне өйрәнеп торалар. Алар Россия белгечләре өчен бик кыйммәтле материал, үз тәннәрендә бөтен атом тарихын йөрткән төп чыганак. Алар атомщиклар һәм галимнәр куйган күп сорауларга җавап бирәләр - даими рәвештә радиация дозасы алып торган кешенең организмы кайсы якка үзгәрә, кешенең генетик кодын радиация кертеп ничек җимерергә, үзгәртергә була, бу мәкерле белемне ничек итеп үзеңә кирәкмәгәннәргә каршы кулланырга? Монда сүз инде аерым авыллар, нәселләр, милләтләр турында гына бар-

мый, сүз башка дәүләтләр, илләр, цивилизацияләр язмышы турында бара... Мөслим татарлары, үзләре дә белмәстән, Россия империясенә менә шушы сорауларга җавап табарга булышалар, аның төп атом сыналучысы булып торалар.

Мәсьәләнең икенче ягы да бар. Хокукчы-эколог Госман Кәбиров әйткәнчә, радиацияле бу татарлар хәзер үзләре дә радиация чыганагы булып торалар. Ягъни, алар хәзер үзләре тирә-якка радиация тарата, чөнки аларның сөякләрендәге радионуклидлар кешене эчтән җимерү белән бергә, тышкы дөньяга да нурланыш тараталар. Шуңа күрә бу кешеләрне дөнья буйлап таратмыйча, бер урындарак туплап торырга тырышалар кебек. Әмма монда сүз бер Мөслим авылы турында гына бармый бит, Чиләбе өлкәсендә миллион ярым кешенең нурланыштан зарар күрүе билгеле. Алар барысы да, иртәме-соңмы, башкаларны да нурландыру чыганагы булырга мөмкиннәр. Россиядә тулы бер өлкәләр үле зонага әйләнергә мөмкин... Үлем җир астыннан өскә чыга, радиация булып, кешеләрнең тәннәренә үтеп керә, кешеләр, үзләре дә сизмәстән, башкаларны нурландыру, үтерү чыганагына әйләнәләр... Коточкыч чынбарлык, коточкыч киләчәк..

Моның нәкъ шулай икәнлеген иң беренче булып Мөслим авылында яшәүчеләр аңлый. Алар үзләре өчен генә түгел, кешелек дөньясы өчен дә тиңе булмаган көрәш башлыйлар. Атомчылар белән бергә-бер, йөзгә-йөз калып, алардан бөркөлеп торган үлемнән дә курыкмыйча, бу фидакарьләр атомчыларның кара эшләрен бөтен дөньяга фаш итәләр. Мөслим авылында яшәүче руслар һәм татарлар бер булып, үз хокуклары өчен көрәшкә ташланалар. Шундыйларның берсе - ГАЛИНА КОНСТАНТИНОВНА ПАШНИНА белән мин әле 1996 елның мартында, Казан шәһәрендә уздырылган Атом-төш куркынычсызлыгы конференциясендә очрашкан идем. Шул чагында ук ул бу хәлләрне «Халыкка каршы игълан ителмәгән атом-төш сугышы» дип атады. Чәчләренә чал кергән бу пенсионер-укытучы ханымның җан ачысы белән сөйләгән сүзләрен биредә дә китереп үтәбез.

ГАЛИНА КОНСТАНТИНОВНА ПАШНИНА - пенсионер укытучы, Мөслим авылы:

«...Без 40 ел буе үзебезгә каршы тыныч заманда атомтөш сугышы игълан ителгәнен белмичә яшәдек. Игълан ителмәгән бу сугыш Теча елгасы буенда яшәүче меңләгән кешене юк итә торды, ә врачларга бу турыда артык шауламаска кушылды. Бернәрсә белмәгән Мөслим халкы ничә еллар буе радиация 200-600 микрорентген булган Теча суында коенды, шунда керен юды, балыгын тотты, тугайларында печән чапты... Мал-туар әле бүген дә шул Теча елгасы буйларында йөри, шуның суын эчә, ә без шул хайваннарның сөтен эчәбез, итен ашыйбыз һәм нәтиҗәдә, рактан кырылабыз. Кешеләр үпкә рагыннан, эчәк чирләреннән, аккан авыруыннан күпләп үлә, балаларның борыннанрыннан шаулап кан китә, алар мәктәптә бик сүлпән һәм 45 минут дәресне чак утыралар.

Авылда бала табу бик нык кимеде, ә үлем туудан күбрәк. Теча елгасында су коенган, балык тоткан яки балыгын ашаган күп кенә ир-атлар һәм хатын-кызлар инде беркайчан да әти-әни булу бәхетен кичермәячәкләр. Яшь хатыннар күп очракта 9 ай авырларын күтәрә алмыйлар, тапкан очракта да, балаларында гемоглобин бик түбән була, аннан ул кан рагына әйләнә. Төрле илләрнең галимнәре уздырган тикшерүләр күпләрне тетрәндерерлек. Мөслимлеләрнең хромосомнарында дицентриклар табылган, бу исә организмга яңа радиация килеп торуын күрсәтә. Бу хакта Новосибирский шәһәреннән галим-генетик Нина Соловьева әйтә. Бары тик безнең өлкәнең санэпидстанция врачлары гына бөтен дөньяны Мөслимдә хәлләр яхшы, дип ышандырырга тырышалар. Бу врачлар Теча елгасы ярларының каты радиоактив калдыклардан торганын, анда яшәүчеләрнең нурланыш дозасы алуларын, бөтен карталарда да Чиләбегә кадәр плутоний эзе төшерелгәнен белмиләрме икәнни?

Менә шуңа күрә радиация һәлакәте булган урыннарда нәсел чирләре артуын һәм хроник патология очракларын көтәргә кирәк. Мөслим участок больницасында рак белән хисапта торучылар өлкәгә караганда өч тапкыр артык, ә сәламәт кешеләр нибары 7 генә процент. 46 процент бала даими авыручы булып исәпләнә. 50 процент халыкта анемия. Бу бәладән кешеләр генә түгел, табигать тә зур зыян

күрде. Игълан ителмәгән бу сугыш Мөслим авылының 431 мең гектар җирләрен тартып алды, халык 300 мең гектар җирләрне сугара алмый. Бу тирәдәге 8 авыл, 224 хуҗалык юкка чыкты. Ә Кунашак районы турында сөйләгәндә, бу игълан ителмәгән атом сугышы 30 авылны, 20 мең гектар җирне юк итте, шушы 30 ел вакыт эчендә 20 мең кеше туган-үскән җирләреннән таратылды.

Безнең авыл советы территориясендә хәвефле, куркыныч хәл килеп туды. Экологияне торгызу буенча эшләр бик начар алып барыла. Теча елгасын чистарту буенча Челябинский -65 *(«Маяк». - Ф. Б.)* шәһәре бернинди эш алып бармый, торак пунктлар белән дә шул ук хәл. Төзелеш индустриясе буенча, халыкның сәламәтлеген кайгырту һәм табигатьне торгызу буенча бернинди җитди эш эшләнмәде. Радиациядән зарарланган урыннарда халык бик начар яши, ә бит алар башкаларга караганда яхшырак шартларда яшәргә тиеш. Өлкә һәм район хакимияте, безнең җирләрдә радиоактив калдыкларны саклап һәм эшкәртеп, бары тик байлык, керем турында гына уйлый, ә кешеләрнең сәламәтлеге, табигать турында кайгыртмый. Бу кеченә генә җир кисәге иң пычранган һәм иң онытылган, ташландык бер почмак булып тора. БУ — МЕДИКЛАРНЫҢ КЕШЕЛӘР ӨСТЕННӘН ТӘҖРИБӘ УЗДЫРА ТОРГАН ПОЛИГОНЫ БУЛЫП ТОРА. Монда, кешеләрнең ихтыярына каршы, аларга Көньяк Урал атом станциясе төзелешен тагарга җыеналар, бу җирләрдә атом калдыкларын саклау һәм эшкәртү каралган. Халыкның сабырлыгын сынау дәвам итә...

Без бик зур авырлыклар белән хөкүмәттән үзебезгә карата аерым льготалар, ярдәм күрсәтүгә ирештек. Әмма бу ярдәмнең күп өлеше безгә килеп җитмәде. Россия хөкүмәте тарафыннан безнең өчен бүленгән миллиардлаган сум акчаны өлкә һәм район җитәкчелеге үзләренчә бүлгәләп бетерделәр. Кунашак районында бу акчаларга Мәдәният йорты салынды, юллар асфальтланды, телевышка ремонтланды, АТСлар, йортлар төзелде... Ягъни, район җитәкчелеге Мөслимгә һәм аның меңләгән авыруларына бөтенләй катнашы булмаган башка программа белән эш итте Безнең шушы көнгә хәтле зарар күрү турында таны-

кыкларыбыз юк, һәм дәүләт безгә бурычын кайтарып бирергә җыенмый. Безне тәҗрибә «ак тычкан»нарына әйләндерүләрендә безнең гаебебез юк бит, шулай ук радиациядән агуланган җирләрдә яшәргә мәҗбүр итүләренә дә без гаепле түгел. Хәтта хөкүмәт тикшерүләре дә шуны күрсәтте - безгә дигән 8 миллиард 692 миллион акча башкага киткән. Безнең протестларыбыз, йөзләгән жалобаларыбыз, телеграммалар, менә 5 ел буе безгә игътибар итүләрен сорап ялваруларыбыз бюрократик һәм мафиоз струтураларга бәрелеп, чәлпәрәмә килде.

Шуңа күрә мин бүген, шушы зарарлы төбәктә яшәүче буларак, сездән шундый нәтиҗә ясавыгызны сорыйм: БЕЗГӘ ҮЗ ХАЛКЫНА КАРШЫ ЮНӘЛДЕРЕЛГӘН СУГЫШ КИРӘКМЕ? БЕЗГӘ ДАИМИ РӘВЕШТӘ ТИРӘЮНЬНЕ АГУЛАП ТОРГАН, КЕШЕЛӘРГӘ ҺӘМ ТАБИГАТЬКӘ ЗУР ЗОЛЫМЛЫК ЭШЛӘГӘН АТОМ ЭЛЕКТР СТАНЦИЯЛӘРЕ КИРӘКМЕ?

УРАН-ПЛУТОН ИНДУСТРИЯСЕ ЯШӘП КИЛГӘНДӘ, ЭКОЛОГИЯНЕҢ ТОТРЫКЛЫ БУЛУЫ ТУРЫНДА СӨЙЛӘВЕ КЫЕН. Һаваны, җирне чистартырга кирәк, эчәр суларыбызны саклау мөһим, алар бездә инде болай да кимегәннән-кими бара... Елгалар да инде хәзер табигатьне бизәми, сөендерми, ә үзендәге пычрак белән һәммәсенең котын ала.

Барлык төбәкләрнең галимнәре шушы мәсьәләләр өстендә эшләсеннәр иде. Бүгенге көндә бер Чиләбе өлкәсе өчен генә түгел, Россиянең һәр төбәге өчен табигатьне саклау буенча махсус программалар кирәк.»

Галина Пашнинаның сөйләгәннәре дөрес икәнлеген без Мөслим авылына баргач күрдек. Әйе, биредә барысы да ташландык хәлдә. Халыкка яңа су чыганагы табарга вәгъдә биргәннәр - ул табылмаган, яшьләргә бассейн төзәргә ышандырганар - ул юк, яңа көтүлек урыннары юк, яңа төзелешләр юк... Халык җир белән күк арасында асылынып калган хәлдә яши. Авыл халкын үзен дә әллә ничә төрлегә бүлгәннәр. Нурланыш авыруы булганнар бераз льгота ала һәм башка җиргә күчәргә хаклары бар, ә хәзергә бу авыру табылмаганнарга берни дә юк. Ә бу авыруны исбатлау өчен бөтен гомереӊ үтеп китәргә мөмкин, аны бик сирәк очрак-

та, үләр алдыннан гына билгелиләр... Ә инде авылга Россиянең миллионнары килеп җиту-җитмәү мәсьәләсенә килгәндә, район җитәкчеләре моны тулысынча инкарь иттеләр. Аларның әйтүенчә, район мондый акчаларны күрмәгән. Шулай булырга да бик мөмкин, чөнки Россиядә күп нәрсә кәгазьдә генә кала бит. Акча бүленеп бирелсә дә, ул урынга хәтле килеп җитми, аны югарыда урлашып, бүлешеп бетерәләр... Мөслим авылына исә пычрак су, радионуклидлы туфрак, агуланган һава, газаплы тормыш кала...

## «РЕЙТЕР» АГЕНТЛЫГЫ УРАЛДАГЫ РАДИАЦИЯЛЕ ТАТАР АВЫЛЛАРЫННАН ЯЗМА БИРӘ:

«Рия Хамматованың казлары һәм мөгезле эре терлеге Теча елгасы буенда йөри. Ә бу елга - Россиядәге иң үтергеч чыганакларның берсе. Уралдагы эссе җәйләрдә аның оныклары монда җиләк җыя, үтә күренмәле суларында коена. Алар тирәсендәге тугайлар - дөньяда булган иң радиоактив урыннарның берсе. Шул уңайдан күптән түгел Казанда Голландия фоторәссамы Роберт Кнотның күргәзмәсе узган иде. Ул шул авылларда яшәүчеләрне фотога алган. Кнот авыл халкыны» киләчәккә өмет белән яшәвенә гаҗәпләнгән. «Кайбер урыннарда монда нурланыш 1000 тапкыр күбрәк. Тик Хамматовларны һәм аның авылдашларын рәсми яктан күчереп утыртырга җыенучы күренми. Бәхетсезлек очракларын танып өчен совет хәкүмәтенә ярты гасыр вакыт кирәк булган. Ә бу арада халык күпләп нурланыштан үлә торган. Биредә кайбер кешеләр Хиросима, Нагасаки трагедиясе корбаннары кадәр нурланыш алган», - дип яза Клара Ферреира-Марквес. «Күпчелек авыл халкы бу бәлане 1980 еллар ахырында килгән Михаил Горбачевның хәбәрдарлык, ачыклык сәясәтенә кадәр белеп бетермәгән дә.» Теча елгасы буенда яшәүче Рия Хамматованың аяк буынары үтереп сызлый. Аның буыннарына нурланышлы стронций-90 утырган. Ул пенсиясенә «бер доллардан бераз гына артык өстәмә ала». Шул ук вакытта авыл халкы «Рейтер» хәбәрчесенә күчәргә теләмәүләрен дә белдергәннәр: «Бакчасыз калсак, без ничек тамак туйдырырбыз?», - дигәннәр. Мөслим авылы янында Корман авылы булган. Элек шул

авылда яшәп, бүген Мөслимдә торучы Рафит Фәйзуллинда анемия, даими талчыгу синдромы. Аның 18 яшьлек улы Рәмзис баш тартмасында сулы капчык белән туган - гидросефалис. Бу чирдән кешеләрнең башы артык зурая.

1993 елда РФ хөкүмәте үз гаебен таныган. Җирле «Маяк» комбинатында СССРның беренче атом бомбасы өчен 1949 елда плутоний җитештергәннәр. Шул вакыттан бирле 450000 кешегә нурланыш эләккән, дип санала. Чиләбе өлкәсене» Мөслим авылына һәм тирә-якка «Маяк» комбинаты 1948, 1951, 1958 елларда күпләп радиация тараткан булган.» *(2003* ел, 27 март.)

Бу урында экологларның, галимнәрнең, җәмәгать эшлеклеләренең атом-төш сынауларына, радиация нәтиҗәләренә, Мөслим авылына кагылышлы кайбер җитди фикерләрен китереп үтәбез.

НИКОЛАЙ ИЛЬИНСКИЙ - профессор, Нью-Йорк Фәннәр академиясенең хакыйки әгъзасы:

«Шунысын әйтергә кирәк, атом-төш шартлаулары вакытында һәм атом-төш аварияләре булганда, тирә-якка кыска гомерле радионуклидлар тарала. Бу радионуклидлар кешенең организмына эләккәч, аның генетик структураларына аерата сиздерерлек удар ясыйлар. Бу очракта гадәти физик алымнар белән үлчәп, кешенең күпме доза нурланыш алганын белү, нигездә, мөмкин түгел. Безнекеләрнең түгел, ә япон һәм немец галимнәренең тикшерү нәтиҗәләрен укыганнан соң, Теча елгасы янында яшәгән кешеләрдән бүген дә нурланыш килеп торганын беләсең. Бу нурланыш аларның сөякләрендә утырган радиоактив стронцийдән шулай тарала икән.» *(«*На путях к духовно-экологической цивилизации», Казань, 1996, стр.1*06.)*

НИНА АЛЕКСАНДРОВНА СОЛОВЬЕВА - биология фәннәре кандидаты, Россия Фәннәр академсиясенең Новосибирский бүлеге галим-генетигы:

«Мөслим авылының бишенче буынында һәр дүртенче бала - генетик үзгәрүләр сәбәпле, мутант. Екатеринбург медицина институтыннан Шилко һәм Зеленцова мәгълүматлары күрсәтүенчә, Теча елгасы буенда урнашкан авылларда өлкәннәр һәм балалар арасында авыручылар бик күп. Алар сәламәт кешеләрнең бик аз - нибары 7 про-

цент кына булуын күрсәтәләр. 50 процент халыкта анемия табыла. Бу хәвефле билгене без, ачылган урыны буенча, «Мөслим синдромы» дип атадык. Бу уңайдан шунысын да әйтергә була, Мөслим синдромы Чернобыль һәм Кайнар синдромына охшаш, алар да атом һәлакәте булган җирләрдә ачылган иде.» (Күрсәтелгән хезмәт, 107 бит.)

РОССИЯ АТОМ-ТӨШ КУРКЫНЫЧСЫЗЛЫГЫ ФЕДЕРАЛЬ ҮЗӘГЕ ГАЛИМНӘРЕ ФИКЕРЕ:

«Теча елгасы тугаена гамма һәм бетта белән югары пычрану хас (1000 мкр/ч һәм 200 бета частиц/мин см). Үлчәү нәтиҗәләре шуны күрсәтте, Теча елгасы радиоэкология ягыннан критик кискен хәлдә. Теча елгасының югары агымында плутоний составы көчле - 24нче ноктада ул 827-/-248 Бк/кг. Теча елгасының Мөслим авылы янындагы тугаенда хәл хәвефле.» (Күрсәтелгән хезмәт, 106 бит.)

Күрәсез, галимнәр бер тавыштан, Теча елгасы буенда һәм Мөслим авылында яшәү өчен куркыныч булуын кисәтәләр. Ә өлкә чиновниклары алар әйткәннең киресен исбатларга тырышалар, ягъни, Мөслим авылында яшәү өчен куркыныч түгел, дип баралар. Безнең кулыбызда шундый рәхимсез җавапларның берсе. Бу - бер өлкә түрәсенең генә рәсми җавабы түгел, ә аның артында торучы атомщикларның да, хәрбиләрнең, Россияи хөкүмәтенең дә ачык фикере. АЛАР менә шундый фикердә булган өчен, Мөслим авылы һаман күчерелми, халык кырыла тора, миллэт юк ителә...

ГЕННАДИЙ НИКОЛАЕВИЧ ПОДТЕСОВ - Чиләбе өлкәсенең хакимият башлыгы урынбасары:

«Мөслим авылы һәм станциясендә халык ала торган радиация дозасы елына бер миллизиверт кына тәшкил итә. Дөньяда һәм Россиядә кабул ителгән нормативлар буенча, бу радиация зонасында яшәүчеләрне күчерү мәҗбүри түгел. Үз теләкләре белән Мөслимнән китүчеләр исә бөтен льготаларын югалталар.» («Челябинский рабочий», 1998, 10.07.)

Менә шулай - Мөслимнән китсәң дә бөтенесен югалтасың, калсаң да бөтенесен югалтасың... Халык почмакка китереп терәлгән, борыла да алмый. Бик теләсә дә, кубарылып чыгып китеп, каядыр барып урнаша да алмый - акчасы

юк. Менә шулай - халык инде радиациядән үлеп бетеп бара, ә алар, өлкә түрәсе әйткәнчә, «радиацияне тиешле нормада гына алганнар» икән, шуңа күрә, аларны күчерү дә мәҗбүри түгел икән... Әйткәнебезчә, бу җавап бер Подтесовныкы гына түгел, аның артында «Маяк» берләшмәсе, атомчылар, хәрбиләр, намуссыз врачлар, Россия хөкүмәте тора. Мөслим авылы халкына каршы Россиянең үлем индустриясе - АТОМЧЫЛАР ҺӘМ ХӘРБИЛӘР ТОРА... Бу хакта әле 1995 елның 13 апрелендә үк «Комсомльская правда» газетасына язып чыккан Ольга Музафарова мең тапкыр хаклы:

«АТОМНОЕ ЛОББИ В СОЮЗЕ С ВПК СИЛЬНЕЕ ВСЕХ НА СВЕТЕ ПРАВИТЕЛЬСТВ И ПРЕЗИДЕНТОВ», дигән иде ул...

Атлантида кебек атом упкынына китеп яткан Мөслим авылыннан, мөслимлеләрдән ярдәм сорап кычкырган авазлар бөтен дөньяга тарала... Бирегә сайлаучылар эзләп килгән Мәскәү сәясәтчеләре аларга Татарстанга яки Төньяк Кавказга күчәргә тәкъдим итәләр... Моның астында яткан нечкә мәкерне тоясыздыр - сезгә, чирле татарларга урын я әнә канлы Чечняда, я үзегезнең «бәйсез» Татарстаныгызда... Ә халыкны шушы хәлгә төшергән Мәскәү нишли, үз халкын яклыйсы урында, атомчыларны яклап яткан Чиләбе нигә читтә кала, бу хәл өчен нигә «Маяк» җавап бирми - анысы билгесез... Билгеле, Татарстан хөкүмәте, миллионлаган татар халкы бәлада калган милләттәшләренә кулларыннан килгәнчә булышыр, иншаллаһ! Шуның өчен без, Бөтендөнья татар конгрессы вәкилләре, үз тормышыбызны куркыныч астына куеп, радиацияле татар авыллары буйлап йөрдек, махсус приборлар белән радиация нормасын тикшердек, өйләрдә, мәктәпләрдә, мәчетләрдә, музейларда, больницаларда булдык, Чиләбе өлкәсендә милләттәшләребезнең хокуклары кысылу буенча зур материал тупладык, аларны халыкара судларга тапшырыр өчен әзерләдек. Бирედә яшәүче татарларга без күп итеп милли һәм дини китаплар алып бардык, Татарстан исеменнән, кыйммәтле дарулар тапшырдык, Татарстан югары уку йортларында шушы районнан студентлар укыта башлау турында килештек. Безнең юрист-

адвокатларыбыз, радиациядән зарар күргән татарларны яклап, Чиләбе өлкәсендә барган судларда катнашты. Татарстан телевидениесеннән бу хәлләр турында махсус тапшырулар күрсәтелде, татар матбугатында бу темага җитди мәкаләләр басылып чыкты. Дөрес, Чиләбе өлкәсендәге милләттәшләребез Татарстаннан күбрәкне, ягъни, үзләрен аннан күчерүдә ярдәм итүне көтәләр. Әмма бу бик җитди мәсьәлә, федераль дәрәҗәдә хәл ителә торган эш. Бөтендөнья татарларының мәьәләләре бары тик Татарстан ярдәмендә генә хәл ителә ала икән, димәк, Мәскәү эшләгән җинаятьне, фаҗигане дә Казан төзәтергә тиеш була. Бу хакта бездән меңләгән милләттәшләребез ялвара, бу хакта бездән Урал артында, атом утравында калган татарлар сорый... Менә аларның Татарстан Президенты Минтимер Шәймиевка язган чираттагы хатлары:

«Хөрмәтле Президент әфәнде!

Без Сезнең эшегез күп икәнен аңлыйбыз, әмма куәтле нефть һәм самолет төзелеше секторлары, КамАЗы булган Татарстан татарларны «Маяк» тирәсендәге куркыныч урыннан ата-бабалар җиренә күчерә алмыймы? Татар энциклопедик словарыннан күренгәнчә, анда 13 яки 7 генә кеше калган, бетеп бара торган авыллар бар икән бит. Пугачев яуларында катнашкан Мөслим татарларының милләт алдында хезмәтләре бар бит! Аларның бүгенге хәлләре - бөтен милләт өчен җан ярасы! Зинһар өчен, аларны Атом утравыннан алыгыз! МЧСның докладыı буенча, имеш, анда бернинди дә куркыныч юк, әмма балалар һаман авыруларын дәвам итәләр. Нигездә, бөтен экологлар да бер фикердә - комбинат тирәсе иң куркыныч зона булып кала бирә. Ышаныгыз, чыгымнар үзен аклаячак! Бу Татарстанны татарлар белән ныгыту да, Татарстан Республикасының авторитетын Бөтен Дөнья татарлары арасында ныгыту да булып торачак.

Хөрмәт белән, Гайнуллина Фәридә Бәдретдиновна, Сакаев Айрат Равильевич, Османова Гафирә Камалетдиновна, Сакаева Гөлнара Равильевна, Корбанов Марат Хәсәнович, Мәскәү шәһәре. 01.12. 2002 ел.»

Язмамның Мөслим турындагы бүлеген авылның экология музее мөдире В. Ф. Ожогинаның шигыре белән тәмам-

ларга уйлыйм. Мөслим фаҗигасен дөньяга белдерү, башкаларны да бу бәладән кисәтү өчен ул бик күп эшләр башкара. «Набат» дип аталган экология оешмасы һәм музей булдыру, бу хакта китап-брошюралар чыгару, мәктәп балалары белән экология темасына очрашулар оештыру, конференцияләр уздыру, радиация корбаннары хөрмәтенә Хәтер Аллеясе утырту - болар барысы да В. Ф. Ожогина җитәкчелегендә эшләнгән эшләр. Шигырьләреннән күренгәнчә, аның үзенең дә иң кадерле кешеләрен радиация юк иткән, атом кабергә керткән...

## ПИСЬМО К ЗЕМЛЯКАМ

Я убит не под Ржевом,
Ни в кровавой Чечне,
А убит я в деревне
На родной стороне.
Здесь и пули не свищут,
Нет глухих канонад,
Но по прежнему матери
Здесь хоронят ребят.
Молодых и веселых,
Полных светлых надежд,
Но в их жизнь хлопотливую
Вторгся атома след.
Я хотел очень жить,
Видеть дочку свою,
А познал только боль,
Да могильную мглу.
Но не падайте духом!
Засучив рукева,
Смело в бой в идите
Защищайте права!
Право жить и любит,
Право солнце встречать!
Чтобы отправляясь
Не бояться не встать.
Но в борьбе той священной
Не забудь обо мне,

Честен будь ты с собою
Завещаю тебе.

*ОЖОГИНА В. Ф. сентябрь 2000 г.*

Маяком называют цинично ПО,
Для людей же в округе оно, как бельмо.
Посылает Маяк не спасенья лучи,
Стронций, цезий, плутоний - его палачи!
Незаметно подкравшись,
разят всех подряд,
На столеть потянется меченных ряд.

*ОЖОГИНА В. Ф. сентябь 2001 г.*

**ЗЫЯЛЫЛАР ФИКЕРЕ:**

«ВСЕ, ЧТО СВЯЗАНО С РАЗВИТИЕМ АТОМНОЙ ЭНЕРГИТИКИ В РОССИИ, НАСКВОЗЬ ПРОПИТАНО ЛОЖЬЮ И СМЕРТЬЮ».

«...ЯДЕРНАЯ ТЕХНОЛОГИЯ ЭНЕРГЕТИЧЕСКОЙ И ВОЕННОЙ ПРОМЫШЛЕННОСТИ ГРОЗИТ ИСТРЕБЛЕНИЕМ ЖИЗНИ НАШЕЙ ПЛАНЕТЕ».






# ӨЧЕНЧЕ БҮЛЕК

## Атом корбаннары

Безнең алдагы сүзебез Татар Караболагы авылы турында. Район үзәгеннән 60-70 чакырымнарда урнашкан зур бу татар авылының хәле Мөслимнекенә караганда да фаҗигалерәк. Ул 1957 елда «Маяк» шартлаганда радиация зонасында кала, әмма радиациядән зыян күргән булып исәпләнми. Бу авылны әле 1959 елны ук башка урынга күчерергә дигән карар чыга, әмма ул күчерелмичә кала. Алай гына да түгел, Татар Караболагы авылы башка урынга күчерелгән булып исәпләнә, моның өчен кемнәрдер югарыда зур акчалар ала һәм авылны бөтен карталардан да сызып ташлыйлар... Әмма авыл бар, ул һаман радиацияле үлем зонасында утыра, әмма радиациядән зарар күргән булып исәпләнмәгән, Мәскәүнең махсус закон һәм карарлары да, ташламалары да аларга кагылмый. Аларны икенче урынга күчерү турында сүз дә бармый. Без, Татар Караболагы авылына да барабыз, дигәч, район җитәкчеләре безгә кат-кат, «Ул авыл радиациядән зарар күрмәгән бит, анда радиация белән бәйле проблема юк», дип исбатларга тырыштылар. Әмма без куркыныч зонада яшәгән милләттәшләребезнең тормышын үз күзләребез белән күреп, дөреслекне ачыкларга булдык һә ташландык юллардан ташландык авылга чыгып киттек... Моңа кадәр без Татар Караболагы авылы турында башка төрле хәбәрләр дә ишеткән идек инде...

«РЕЙТЕР» АГЕНТЛЫГЫ УРАЛДАГЫ РАДИАЦИЯЛЕ ТАТАР АВЫЛЛАРЫННАН ЯЗМА БИРӘ:

«...Татар Караболагы авылында яшәүче 640 кешенең 500е рак белән авырый. Дөрес, кайчандыр 4 мең кеше яшәгән бу авылны картадан 43 ел элек үк сызып ташлаган булганнар. Әмма биредә кешеләр көн күрүен дәвам итә. Сәламәтлек саклау министрлыгы архивларына алар «ХРОНИК НУРЛАНЫШ ТӘЭСИРЕНДӘ КОНЦЕРОГЕН ҺӘМ ГЕНЕТИК ҮЗГӘРЕШЛӘРНЕ ӨЙРӘНҮ МӨМКИНЛЕГЕН АЧУЧЫ ТӨРКЕМ» буларак теркәлеп калганнар. Ягъни, тәҗрибә астындагы күселәр кебек. Бу максаттан үлгән кешеләрне дә тынычлыкта калдырмаганнар. «Тирәюньдә мөселманнар яши. Коръән мәетләрне тиз арада һәм ярмыйча күмәргә куша. Тик кеше үлү хәбәрен ишетүгә үк, ниндидер кешеләр килеп, аларны алып киткәннәр һәм берничә көннән генә кайтарганнар», - дип язган иде Гринпис хәрәкәте чыганагы. Мәетләрнең организмларын тикшергәннәр. Шулай ук җирле хатын-кызлар да баланы «триллердагы кебек» таба торган булган. Аларны махсус бала табу йортлары гына кабул иткән. Бәби тууга, аны әнисенә күрсәтмичә, күрше бүлмәгә озата торган булганнар. Ягъни. гарип баланы күрмәсеннәр өчен. Әти-әниләр: «Күмәр өчен булса да бирегез», - дип ялварганнар. Тик алар кулына гарип балаларын тоттырмаганнар. Тик бер акушерка берничә мутант эмбрионны һәм гарип бәби мәетен спиртка салып саклап кала алган. Аны ул Горбачев заманында чит ил кешеләренә күрсәткән. Әлбәттә, ул арада аның экспонатларын конфискацияләгәннәр. Тик фотолары инде дөньяга чыгып өлгергән.

Тик заводта Чернобыльдән дә куркыныч шартлау ясый алырлык матдәләр кала бирә әле. Биредә радиация бүген дә Чернобыльнекеннән 10 тапкыр күбрәк, дип раслый «Рейтер».

Шул ук вакытта Россия җиңел генә чит илләрнең атомтөш калдыкларын саклауга салырга җыена. Хәбәрчегә «Маяк» вәкиле Евгений Рыжков: «Хәтта теоритик яктан караганда да бернинди дә куркыныч юк», - дип әйткән. Тик ул комбинаттагы калдыкларны яраксызландырырга акча юклыгын таныган. «Ач калган атом-төш лоббисы исә үз

иленә калдыклар кертергә рөхсәт иткән. Ул кабаттан да «Маяк»та эшкәртеләчәк», - дип яза «Рейтер». 27 март, 2003 ел.»

Әйе, бу авыл инде картада юк, әмма ул гамәлдә бар һәм менә каршыбызда таралып, җан биреп ята... Аның тирәягында радиацияле күлләр һәм сазлыклар, авыл кырыеннан радиацияле Караболак елгасы агып ята... Кайчандыр биредә 4 мең кеше яшәгән, хәзер - 600. Авыл читендә инде 8 зират, алар барысы да тулы... Соңгы елларда гына 1,5 мең кеше үлгән, халык, нигездә, радиациядән һәм рактан кырыла, әмма аларга башка төрле диагноз куела. Татар Караболагы авылының радиациягә эләкмәвен исбатлау өчен органнар барысын да эшлиләр, шул исәптән, көчле авыручыларга да бармак аша гына карыйлар. Ә авыл халкының «Маяк»тан зыян күрүләрен исбатлау өчен, авыруларыннан кала да, исбатларга дәлилләре җитәрлек. Шуның беренчесе - 1959 елның 29 сентябрендә Чиләбе өлкә советы башкарма комитетында кабул ителгән карар. Укучылар игътибарына без аның Татар Караболагына караган өлешен тәкъдим итәбез:

**РЕШЕНИЕ**

*исполнительного комитета Челябинского областного Совета депутатов трудящихся. № 546сс от 29 сентября 1959 г. О проведении дополнительных мероприятий в зоне радиоактивного загрязнения*

В связи с промышленным радиоактивным загрязнением значительной части территории Багарякского, Каслинского и Кунашакского районов и реки Теча, протекающей по территории Кунашакского и Бродокалмакского районов, в дополнение к ранее принятым мерам с целью создания в этих районах условий, обеспечивающих безопасность проживания людей и правильное ведение хозяйства, исполнительный комитет областного Совета депутатов трудящихся РЕШАЕТ:

1. Жителей населенного пункта Багаряк в количестве 2894 человек переселить в район станции Тахталым Кунашакского района, для чего предприятию п/я 21 построить необходимое количество жилых домов с надворными постройками, культурно-бытовых и административно-

хозяйственных учреждений, аналогично имеющимся в населенном пукте Багаряк. Производственные предприятия имеющиеся в населенном пункте Багаряк построить в местах по согласованию с облисполкомом.

2. Жителей населенного пункта Татарская Караболка Кунашакского района в количестве 2700 человек переселить на территорию 8 отделения Тахталымского совхоза в д. Аширова Аливкуловского сельсовета Кунашакского района, для чего предприятию п/я 21 построить жилые дома с надворными постройками, культурно-бытовые и административно-хозяйственные учреждения, аналогично имеющимся в населенном пункте Татарская Караболка.

3. Переселение жителей из населенных пунктов Багаряк и Татарская Караболка со строительством жилых домов на станцию Тахталым и в д. Аширова закончить в 1960 году. Строительство административно-хозяйственных, культурно-бытовых учреждений и производственных предприятий закончить в 1961 году.

*Председатель Челябинского облисполкома (Г. Бездомов), Секретарь облисполкома (П. Карпенко)»*

Русларда «Бумага стерпит», дигән сүз бар. Әйе, кәгазь барысына да түзә. Күрәсез, рәсми карар бар, анда акка кара белән бу территорияләрнең радиациядән зарар күргәнлеге хакында язылган, Багяряк һәм Татар Караболагы авылларын икенче урынга күчерергә карар бирелгән. Әмма бу ике татар авылы да шул радиацияле зонада калдырылган... Һәм аларның 50 ел буе ярдәм сорап кычкыруларына, аһзарларына беркем дә игътибар бирми... Чөнки рәсми хакимият өчен алар инде күптән юк...

Чиләбедә дә, район үзәге Кунашакта да бүген бер авыздан, Татар Караболагы радиациядән зарар күрмәгән, дип баралар. Югыйсә, архив материаллары бөтенләй башкача сөйли бит, бу җансыз түрәләргә дөреслекне белү өчен 45 ел элек язылган рәсми белешмәләрне алып уку да җитәр иде. Алардан күренгәнчә, Татар Караболагы авылы - 1957 елгы радиацион шартлаудан иң нык зыян күргән урыннарның берсе һәм аны кичекмәстән башка урынга күчерергә кирәк, диелгән. Ул гына да түгел, бу кара исемлеккә зур татар авылы Багаряк та кертелгән, ул да радиациядән коточкыч

зур зарар күргән, ул да күчерелмәгән, урынында утырып калган... Язмабыз дәлилләр таләп иткәнгә күрә, без бу урында тагы бер рәсми белешмәне китереп үтәбез:

**ДЛЯ СЛУЖЕБНОГО ПОЛЬЗОВАНИЯ**

*Заместителю председателя Челябинского облисполкома тов. МАМОНТОВУ Е. В.*

**СПРАВКА**

«По данным филиала НИИРГ от 25/У1-59 г. в районе населенных пунктов Багаряк и Татарская Караболка наблюдается высокая плотность загрязнения территории сел, заливной поймы и самой реки «К» (Караболак - Ф. Б.), а также заболеваемость среди жителей этих населенных пуктов.

Комиссия филиала НИИРГ считает, что дальнейшее проживание населения в селах Багаряк и Татарская Караболка опасно и рекомендует немедленное их отселение.

Стоимость отселения села Багаряк составит 753х0, 13 - 97, 9 млн. рублей.

Село Татарская Караболка имеет всего 604 хозяйства с населением 2638 человек. Стоимость отселения села Татарсткая Караболка составит 604х0, 13 - 78 млн. рублей.

По постановлению Совета Министров СССР от 12/Х1 - 57 г. № 1282 - 387 п. «5» Министерство здравоохранения СССР, Министерство среднего машиностроения и академии Наук СССР, обязаны в течении года изучить возможность проживания населения в зоне загрязнения.

Никаких рекомендации от этих трех ведомств нет, жители наскеленных пунктов расположенных по реке «К» (Караболка - Ф. Б.) и «Т» (Теча - Ф. Б.) продолжают проживать, заболеваемость имеет место, поступают многочисленные жалобы с просьбой на отселение, в том числе от жителей села Нижнее-Петропавловское.

Обисполком располагает только заключениями и рекомендациями филиала НИИРГ, которое сводятся к немедленному отселению населенных пунктов Багаряк, Татарская Караболка и Ниж. Петропавловское.

*Главный инженер отдела Челябинсого облисполкома Э. РАСК. 6 февраля 1960 г».*

Күрәсез, галимнәр кискен рәвештә, кичекмәстән, радиациядән көчле зарар күргән Татар Караболагы һәм Багаряк авылларын башка урынга күчерергә тәкъдим итәләр. Әлбәттә, алар бу фикергә урыннарда радиация фонын үлчәп, мәсьәләне җитди рәвештә өйрәнеп киләләр. Күрәсез, Чиләбе өлкәсе җитәкчелеге дә бу мәсьәләне кат-кат күтәреп, уңай хәл итәргә тырышып карый. Әмма кемнәргәдер бу татар авылларының радиацияле зонада утырып калулары кирәк була. Бу хәл Россия чиновникларының очраклы бер гамьсезлекләреме, әллә аңлы рәвештә шушы җинаять юлына баруларымы? Россия хәрбиләренә, атомчыларына, врачларына бу татар авыллары тәҗрибә кыры буларак кирәк булган, дип әйтергә безнең бүген тулы хакыбыз бар. Һәм Россия хөкүмәтен шушы җинаяте өчен җавапка тартырга да хакыбыз бар...

Теча елгасы якын булу сәбәпле, Мөслим авылы халкы инде статус-льгота мәсьәләләрендә кайбер мәсьәләләрне хәл итә алган. Шундый ук радиацияле Караболак елгасы буенда утырган Татар Караболагы авылы халкына моны исбатлау бик авыр. Әйткәнебезчә, авыл чын мәгънәсендә атом сазлыгы буенда утыра, анда бүгенге көндә 85 мең кюри атом калдыклары сакланганлыгы билгеле. Авыл халкының әйтүенчә, биредә эт башы зурлыгында мутант бакалар барлыкка килгән. Авыл янында радиоактив калдыклар сакланган күл дә булган, анда тәннәре тишекле, үлекле балыклар пәйда булган. Каяндыр, кемнәрдер килеп, бу күлне тиз генә күмеп киткәннәр, агулы суын тишеп, җир астына җибәргәннәр... Халыкның әйтүе буенча, радиацияле ул су Караболак елгасына бәреп чыккан булырга тиеш. Узган ел Караболак елгасында кер чайкаганда, Гайсина Оксана исемле кыз, елга суыннан зарарланып, берничә көн эчендә газапланып үлә. Аның тәненнән итләре умырылып-умырылып чыга, күз алдында сөягеннән итләре аерыла... Бу елга хәзер кышларын да катмый икән, үзенә бер төрле хәвефле яшелләнеп, төтенләп ята... Әмма халык шул су буенда яшәргә мәҗбүр, шунда мал-туар йөри, шул тирәләрдән печән әзерлиләр... Чөнки халыкның башка елгасы, болыннары, көтүлек җирләре юк... Биредә көчле радиация барлыгын алар беркемгә дә исбат итә алмыйлар...

Хәер, 1999 елда биредә Америкадан радиобиологлар булып, өйләрне һәм кешеләрне тикшереп, Татар Караболагында радиациянең торышын һәм тәэсирен өйрәнеп китәләр. Соңыннан алар Америкадан Татар Караболагындагы күп кенә өйләрдә, радиация көчле булу сәбәпле, яшәргә ярамаганлыгы турында белешмәләр җибәрәләр. Ә халык кая барсын - Америка кәгазе бездә закон түгел бит. Шул «яшәргә ярамый» дигән өйләрдә бүген дә кешеләр яшәп ята, без дә аларда булдык, биредә, чыннан да, радиация нормадан бик күпкә артык иде. Әгәр теләсә, Россия хөкүмәтенә Татар Караболагы авылының бүгенге көндә дә радиация эчендә яшәвен исбатлау өчен берничә сәгать вакыт җитәр иде. Бу авылга, аның урын өстендә газапланып, тилмереп яткан кешеләренә карагач, «Чыннан да, Россия үз халкы өстеннән атом геноциды алып бара икән», дигән кискен фикергә киләсең...

Татар Караболагы - бик борынгы, тарихи татар авылы. Рәсми мәгълүматлар буенча, бирегә татарлар 1553-1556 елларда, көчләп чукындырудан качып, Идел-Кама буйларыннан күчеп килгән булырга тиешләр. Әмма безнең фикеребезчә, бу татар авылы тагы да борынгырак чорлардан яшәп килә. Төбәктән табылган борынгы төрки-татар курганнары, каберлекләр, шәһәрлек урыннары, мәгарәләрдә сакланып калган торак урыннары безгә шулай дип әйтергә нигез бирә. Галимнәрнең әйтүенчә, бу тирәләрдә борынгы кешеләр моннан 100 мең ел элек яши башлыйлар. Аллаки күле буенда табылган борынгы торак урыны да шул хакта сөйли. Шуның билгесе булып, биредә элеккеге кешеләр табынган 12 торараташ тора. Бу ташларның берсн Әби-таш дип йөртәләр. Биредәге мәгарәләрдә дә шундый ук сурәтләр табыла. Кешеләр биредә борынгыдан ук тимер эшен беләләр, ул хакта да археологик табылдыклар сөйли. Моннан мең ел ярым еллар элек исә биредә татарларның борынгы бабалары булган гуннар, ягъни, скифлар хуҗалык иткән. Бу хакта Татар Караболагы авылы янындагы борынгы курган күпне сөйли алыр иде. Урал профессоры Бирюков әйтүе буенча, бу - борынгы скифларның каберлек-курганы. Биеклеге - 5, аркылысы 10 метр зурлыкта булган бу курганны вакыт давыллары да, хәтта атом афәте дә

җимерә алмаган. Кешеләр китә, ә ул һаман горур басып, кала бирә...

Татар Караболагы авылы менә шушы борынгы традицияләрне, гадәтләрне барысын да үзенә сеңдергән. Авыл заманында бик мәгърифәтле, һөнәрле, тирә-юньдә бер көчле татар авылы булган. Татар Караболагында әле 1717 елны ук мәчет һәм мәдрәсә булган, ул биналар бүген дә исән, мәчет һәм мәктәп бинасы булып файдаланалар. Әле моннан 50 ел элек кенә дә Татар Караболагы авылы гөрләп торган, картлар әйтүенчә, ул чагында авылда 5 меңгә якын кеше яшәгән. Шунысы да игътибарга лаек - бу авылдан укымышлы кешеләр бик күп чыккан, һәр йортта диярлек югары белемле белгеч булган. Хәзер аларның исән калганнары кайсы-кайда таралып беткән... Авылның урта мәктәбендә заманында 800-900 бала укыган. Хәзер исә бу мәктәптә нибары 60 бала укый, шул сәбәпле, инде урта мәктәпне яптыру турында югарыда сүзләр йөри. Авылда балалар бетүгә таба бара, быел 11 классны нибары ике бала тәмамлаган, беренче класска исә өч кенә бала бара. Тагы ике елдан беренче класска укырга барырга бер генә бала да юк. Балаларның бетүе үзе үк инде авыл өстеннән ниндидер зур афәт узуы турында сөйли... Җанга, күңелгә тигән тагы бер нәрсә бар - югарыдан килгән әмер буенча, саф татар авылында мәктәптә укулар рус телендә алып барыла. Татар теле атнага бер дәрес бары тик предмет буларак кына керә, ягъни, татар балалары үз ана телләрен чит тел өйрәнгән кебек өйрәнәләр. Күп татар авылларында исә бу да юк... Бу хәллә үзе үк Россиянең татарларга каршы милли, дини һәм атом геноциды алып баруы турында сөйли...

Татар Караболагы авылы социаль яктан да бик ташландык хәлдә. 7 чакырымга сузылган авылда ник бер күпер булсын! Авылда һәм авыл тирәсендә юллар бөтенләй каралмаган, ташландык хәлдә. Район үзәгеннән авылга атнага бер тапкыр автобус йөри, халык больницаларга барып, күренә алмыйча кире кайтып китә... Тоташы белән рак һәм нурланыш авыруларыннан череп яткан авылга нибары бер медпункт һәм бер фельдшер. Анда да кирәкле дарулар юк. Без аларга Казаннан көчле дарулар алып килгәч, халык елады, чөнки алар моңа хәтле бер аспиринны ике кешегә бүлеп

эчә торган булганнар... Авылда көчле эшсезлек, яшьләр, эш эзләп, шул ук «Маяк» берләшмәсенә, радиация эченә барып керергә мәҗбүрләр. Авыл халкы хокукый яктан да бер ярдәмсез. Тирә-күрше урыс шәһәрләреннән килеп, ярдәмсез татар карт-карчыкларын талап китү очраклары күп икән. Авылда тәртип сакларга ник бер милиционер булсын! Күренеп тора - район җитәкчелеге өчен бу авыл юк. Анда тилмереп үлем көтеп ятучы йөзләгән атом корбаны юк. Аларның проблемалары юк. Чөнки кәгазьдә авыл үзе дә юк. Чөнки бу авыллар өчен җавап бирергә тиешле кешеләрнең намусы юк. Бу хәлне башкача аңлатып булмый.

1957 елгы «Маяк»та шартлау, иң беренче булып, аннан 40 чакырымнарда булган Татар Караболагы авылына да китереп бәрә. Радиация тузаны, көне-сәгате белән, Караболак елгасы өстенә килеп төшә, авыл тирәсендәге сазлыккүлләрне, Татар Караболагы авылының үзен дә каплап китә. Әлбәттә, кешеләр бу хакта берни дә белми, халыкның бәрәңге алган, яшелчә җыйган бер вакыты була. Яз җитүгә, аларны күрше Урыс Караболагы авылына алып китәләр. Бу урыс авылы радиациядән зыян күргән, дип исәпләнә һәм аны... татарлар кулы белән күчертәләр, ягъни, авылдан урысларны башка чиста урынга чыгарып җибәрәләр дә, радиацияле биналарны татарлардан сүттерәләр, җиргә күмдерәләр. РАДИАЦИЯЛЕ УРЫС АВЫЛЛАРЫНДА ТАТАРЛАРНЫ ЛИКВИДАТОРЛАР ИТЕП ФАЙДАЛАНАЛАР. Татарларны мыскыллау шул дәрәҗәгә барып җитә ки, хәрбиләр урыс авылының радиацияле чиркәвен шартлаталар һәм татарлардан шул кирпечләрне Татар Караболагы авылына кайтартып, аннан дуңгыз фермасы төзеттерәләр. Шулай итеп, Татар Караболагы авылына тагы радиация чыганагы керә, мең еллар буе ислам дине тоткан татар авылына хәрам чыганагы - дуңгыз малы килеп керә... Хәер, бу мәхлукларның да күбесе соңыннан бик сәер чирләр белән үлеп, кырылып бетә... Дуңгыз булып дуңгыз да радиация агуына чыдый алмый...

Ул елларда радиация нәтиҗәләрен бетерүдә, ягъни, ликвидаторлар итеп хәтта Татар Караболагы урта мәктәбе балаларын да файдаланалар. Аларны һәр көн радиацияле, ташландык Урыс Караболагы авылына агач утыртырга

куып китерәләр. Ул балаларның инде күбесе юк, авыл читендәге зиратта, ә исәннәр, соңгы көчләрен җыеп, үзләренең ликвидатор булып эшләүләрен исбатлау өчен көрәшәләр, суд юлларын таптыйлар. Хөкүмәт аларга бу статусны бирмәс өчен барысын да эшли, чөнки ликвидаторлар өчен азмы-күпме ача-льгота каралган. Әмма ликвидатор статусы алу өчен 45 ел элек радиацияле зонада эшләвеңне исбатларга кирәк, аның өчен бик күп белешмәләр җыярга һәм туктаусыз судлашырга кирәк. Бик күпләр бу эшнең ахырыга хәтле барып җитә алмый, егылып, үлеп кала... Югыйсә, бу кешеләрнең 1958 елның май аенда радиацияле зонада эшләүләрен исбатларга менә шушы бер шаһит, менә шушы бер белешмә дә җитә бит. МАРИЯ МАКСИМОВНА КУЛИКОВА ул елларда урманчы булып эшләгән һәм 1958 елның маенда Урыс Караболагы авылында агачлар утырту белән ул үзе идарә иткән. Хәзер Мария Максимовна Чиләбе өлкәсенең Кәсле районы, Төбәк (Тюбук) авылында яши. Бу хакта ул менә нәрсәләр әйтә.

МАРИЯ МАКСИМОВНА КУЛИКОВА, элеккеге урманчы:

«...1958 елның маенда, җир җылыну белән үк, мин җитәкчем Таран кушуы буенча, Рус Караболагы территориясенә утыртырга агач үсентеләре китерә башладым. Бөтен эшләр дә җитәкчеләрнең телдән биргән боерыклары буенча эшләнде, бернинди приказ һәм кәгазьләр тутырылмады. Татар Караболагы авылы шоферлары да үсентеләрне алырга бернинди юлламасыз киләләр иде. Беренче агачларны без юл буйлап утырттык, мөгаен, инде күчерелгән Рус Караболагы авылы урынындагы шомлы бушлыкны каплау өчен шулай эшләнгәндер. Анда солдат саклап торган бер генә бина калган иде. Миңа аның элеккеге кибет икәнлеген әйттеләр, радиациядән пычранган товарларны кая куярга белмиләр икән. Агач утырту өчен һәр көн Караболак урта мәктәбеннән 3-10 класс балаларын куып китерәләр иде. Сугыштан соңгы бу гади һәм тыңлаучан авыл балаларының өс-башларына карау кызганыч иде. Кечкенә балалар ялана-яклап үсентеләр ташыдылар, ә олыраклар махсус көрәкләр белән, яланкуллап аларны траншеяларга утырталар иде. Ул траншеяларны Татар Караболагы авылы тракторчысы

әзерли иде. Балалар шунда ук ашыйлар иде, суны исә Карабулак елгасыннан эчтеләр. Мин хәзер генә белдем һәм тетрәнеп киттем — без балалар белән актарынган ул җирләрдә радиация 1000 Ки/кв. м, радиация фоны - 1000 микрорентген/сәгать булган икән бит!..»

Менә шушы йөзләгән татар баласыннан хәзер берничә кеше могҗиза белән исән калып, могҗиза белән, суд юллары аша, ликвидаторлык статусы ала алганнар. Әмма хөкүмәт алардан көчлерәк булып чыккан, судлашып, аларның бу статусларын юкка чыгарган. Ликвидаторлар моңа каршы тагы судка биргәннәр һәм берничә кеше бу статусны яңадан кайтара алган.... Менә шулай итеп, «Маяк» һәм Россия дәүләте, бөтен көчләрен куеп, радиациядән газап күргән халыкка каршы көрәшә. Мондый хәл бары тик Россиядә генә булырга мөмкин. Ничек үз халкыңны шул хәтле күрә алмаска мөмкин икән?! Ничек шул месkeннәрдән соңгы тиеннәрен дә тартып алырга мөмкин?! Әйе, монда, чын мәгънәсендә, Россиянең үз халкына каршы игълан ителгән һәм игълан ителмәгән сугышы бара... Бер якта - дәүләт, икенче якта мең газаплар күргән чирле халык, аягүрә үлеп баручы татарлар...

ИСМӘГЫЙЛОВА (ГАТАУЛЛИНА) ГӨЛШАРА (ГӨЛЧӘҺРӘ) НАСЫЙБУЛЛА КЫЗЫ СӨЙЛӘГӘННӘРДӘН (1946 елгы):

«Ул вакытта мин 5нче класста укый идем. 1957 елның көзендә, сентябрь аеннан башлап, мин башка укчылар белән бергә яшелчә җыйдым. Әмма 1957 елның 29 сентябреннән соң бөтен җыйган яшелчәбезне - бәрәңге, кәбестә, чөгендерне чокырга күмәргә мәҗбүр иттеләр, ул чокыртарншеялар шунда ук, радиациядән пычранган кырда казылган иде. Шулай итеп, 1957 елның 29 сентябреннән алып, 1957 елның ноябренә хәтле, ягъни, беренче карга кадәр, мин радиациядән пычранган территориядә авыл хуҗалыгы продукцияләрен юк итүдә (ликвидациядә) катнаштым. Без перчаткаларсыз эшләдек, кулларыбыз канап, сыдырылып беткән иде, борыннарыбыздан кан ага башлады, туктаусыз йөткерә идек. Бик нык тузан иде, без яулыкларыбыз белән авызларыбызны капларга тырыштык. Без үзебезнең укытучыларыбыз җитәкчелегендә, класслап

эшләдек. Кырга безне милиционерлар кертеп җибәрә иде. Бу хакта 2002 елның 27 октябрендә булган судта милиционер-ликвидатор Халиков Шакирҗан күрсәтмә бирде. Безнең белән бергә эшләгән барлык укытучылар да, һәм күп кенә классташларыбыз рак авыруыннан үлделәр. Алар: Дәүләтшина Мәрьям, Нигъматуллин Нурулла, Гайсин Әгъзам, Мөхәммәтшин Хәлил, Нигъмәтуллин Хәлил һәм башка бик күпләр... Алар безнең белән юк инде...

1958 елның языннан 1963 елга кадәр, язгы-җәйге айларда, мин радиациядән зарар күргән урыннарда агач үсентеләре утыртуда һәм аларны эшкәртүдә катнаштым. 1958 елның язында без юк ителгән Рус Караболагы авылы янында, ике як юл буйлап, агач утырттык, актарылып ташланган авыл урыны күренмәсен өчен шулай эшләткәннәрдер, мөгаен... 1958 елның июль аенда мин бик каты авырый башладым - авыз-борынымнан шаулап кан китте, эчем туктаусыз китте, температурам айга якын 40 градус булды, бик нык башым авыртты, тәнем берни сизмәде. Авылда врачлар юк иде, мин көзгә хәтле шулай яшәү белән үлем арасында бәргәләндем. Ул елны әни кара янган, мазутка-корымга чорналган үле бала тапты, әни дә радиацияле кырда эшләгән иде...

Хәзер миндә 4нче дәрәҗә яман шеш авыруы. Бер бөерем 40 процентка гына эшли, туктаусыз баш авыртуы, буын сызлаулары газаплый, йөрәгем чирле. Болар барысы да радиация тәэсире бит. Әти рактан үлде, әни яман шештән газаплана, исән калган бөтен туганнарымда бавыр-бөер авырулары... Радиация тәэсире балаларыма, хәтта оныкларыма да күчте, аларда генетик яктан үзгәрешләр сизелә... Россия хөкүмәте, безне, татарларны, менә шулай терелләй череп үләргә хөкем итте. Бу хакта бөтен дөнья белергә тиеш - безне татар булганыбыз өчен радиацияле җирләрдә үләргә калдырдылар, БЕЗНЕҢ ӨСТӘ АТОМ ТӘҖРИБӘСЕ УЗДЫРДЫЛАР...»

Менә минем кулымда бер фотосурәт. Ул 1955 елда төшерелгән. Ул вакытта Гөлчәһрә Исмәгыйлова 3нче класста укыган. Рәсемдә - 29 бала һәм укытучы. Алар өстеннән 1957 елгы атом афәте үтеп киткән, бу гөнаһсыз балаларның бөтен гомерләрен чәлпәрәмә китереп ташлаган. Рәсемдә

төшкән 29 баланың инде 18е рактан һәм йөрәк, тамыр чирләреннән газапланып үлгән, калганнырының барысында да диярлек яман шеш. Рәсемдәге укытучы да инде юк, рактан үлгән. Ул еллардагы укытучылар барысы да инде рактан үлеп беткән... Гөлчәһрә һәр балага күрсәтеп, аның яшәү һәм үлем тарихын сөйли... Ә аларга бит әле 60 яшь тә юк... Алар күргән газаплар өчен, аларның гомере өчен кем җавап бирер?!

## ГӨЛЧӘҺРӘ ИСМӘГЫЙЛОВА СӨЙЛИ

Минем классташларым -

Өске рәттә сулдан беренче бала - САЛИХОВА МӘЙСӘРӘ, ябык кына кыз иде, моннан 15 ел элек бик җәелеп, шикәр чиреннән, йөрәк авыруларыннан бик газапланып, интегеп үлде, 2 баласы калды.

ФӘХРТДИНОВА НУРСАЙЛӘ - исән, әмма бик нык авырый, кан басымы бик югары, чәчләре коелды.

САҖИДӘ - 2 ел элек үпкә рагыннан үлде.

АБДРАХМАНОВА ФӘРЗӘНӘ - исән, әмма бөтен җире авырый, бала таба алмый, чәчләре коелды.

МӘРЗИЯ - үлде, ашказаны рагыннан.

ГӨЛЧӘҺРӘ - монысы мин үзем, хәзергә исән, яман шеш белән көрәшәм, үзем медсестра булгач, нәрсә булып бетәсен беләм.

САЙФУЛЛИНА САНИЯ - исән, баласы юк, бик югары кан басымы, нык чирли.

ГАЙСИН ӘГЪЗАМ - үлде, рак.

ДӘҮЛӘТШИНА МӘРЬЯМ - үлде, үпкә рагыннан.

КАРИМСКИЙ ЖАН - үлде, үпкә рагыннан.

НИГЪМӘТУЛЛИН НУРГАЛИ - үлде, рак.

НИГЪМӘТУЛЛИН ХӘЛИЛ - үлде, йөрәк.

МӨХӘММӘТШИН ХӘЛИЛ - үлде, бөер рагыннан.

АБДРАХМАНОВА ТАЙРӘ - үлде, бәби таба алмады.

ГӨЛФИРӘ - үлде.

НИГЪМӘТУЛЛИНА ГӨЛФИРӘ - үлде, операция өстәлендә, бөерләре эшләми башлый, шикәр чире, буыннар тотмый.

НАҖИЯ - исән, нык авырый.

КИНҖӘБАЕВА ГӨЛФИРӘ - үлде, рак.

ФӘЙЗУЛЛИНА ДИЛӘ - исән, нык авырый.

ЗАРИПОВА АСИЯ - үлде, рактан.

ХӘБИБУЛЛИНА ГӨЛСӘЙРӘ - исән, бик нык башы авырта.

БАРИС - үлде, рактан.

САФИН РИФКАТЬ - язмышын белмим.

РИФКАТЬ - үлде, йөрәк.

ЙОСЫПОВ ВӘЛИ - исән, кан басымы бик түбән, нык авырый.

РИФКАТЬ - язмышын белмим.

КИНҖӘБАЕВ МИННЕГАЛИ - исән, еш авырый.

ГАББАСОВА МӘРЬЯМ - үлде, 7 класста бөтен чәче коелды.

ФӘРӘҮЗӘ - үзе исән, ире рактан үлде.

ҖАМАЛЕТДИНОВА ГӨЛФИРӘ - исән, еш авырый.

ҖАМАЛИЕВА ГӨЛСӘЙРӘ - исән, көчле анемия, азканлык.

МӨХӘММӘТШИН РИФКАТЬ - үлде, яшьтән үк, рактан.

КИНҖӘБАЕВ СӘГЫЙТЬ - үлде, рактан, бөтен авырулары бар иде, кибеп үлде.

ҖӘЛӘЛӘТДИНОВ - үлгән, дип ишеттем.

ШИРВАН - үлде.

НӘҖМЕТДИНОВ РАВИЛ - исән, 2 группа инвалид, рак, бик нык авырый.

Укытучы абый да күптән үлде. Укытучылар барысы да үлеп бетте...

Бу татарлар - Россиянең атом корбаннары... Россия империясенең татар халкына каршы игълан ителмәгән сугыш корбаннары... Хәзер сүзне тагы исән калган атом корбаннарына бирик.

### РИЗВАН ВӘЛИУЛЛА УЛЫ ХӘБИБУЛЛИН СӨЙЛӘГӘННӘРДӘН:

«1957 елның 29 сентябрендә без, Караболак урта мәктәбе укучылары, Рус Караболагы авылы янындагы Жданов исемендәге колхоз кырларында бәрәңге ала идек. Сәгать 4 ләр тирәсендә барыбыз да көнбатыш яктан көчле шартлау тавышы ишеттек һәм кинәттән җил исә башлаганын тойдык. Кичке якта кыр өстенә сәер томан төште. Без,

әлбәттә, бернәрсә дә белмәдек һәм эшебезне дәвам иттек. Алдагы көннәрдә дә эш дәвам итте. Берничә көннән безгә җыйган бәрәңгеләребезне юк итәргә куштылар. Моның өчен тракторчылар чокыр казыдылар, ә без яланкул килеш ул агуланган бәрәңгеләрне чиләкләргә тутырып, чокырга илтеп ташлый идек. Ниндидер саклык чаралары күрү турында безгә беркем берни әйтмәде, чөнки җитәкчеләр үзләре дә ахырга хәтле ни булганын аңлап бетермәделәр.

Кышка таба минем бик нык башым авырта башлады. Мин авыртуга түзә алмыйча идәндә тәгәрәгәнемне хәтерлим, чигәләрем кыршау белән тарттырган кебек иде, борынымнан кан китте, мин бөтенләй күрмәс хәлгә килдем. Минем әниемне, Зөһрә Галимәрдән кызы Хәбибуллинаны, ак кан авыруыннан Чиләбегә алып киттеләр. Техникумда укыганда, миндә начар кан таптылар. Минем өлкән абыем 46 яшендә үлде, сеңелем, шушы радиация авариясе аркасында, бала таба алмас булды, моны бик авыр кичерде, һәм ул да 46 яшендә үлеп китте. Минем күп классташларым инде үлде. Минем оныгым һәм энемнең оныгы «олигофрения» диагнозлы. Менә ничә еллар инде Чиләбе өлкәсе хакимияте мине судлар буенча тилмертеп йөртә, минем суд аша алган ликвидаторлык статусымны юк итәргә тели.»

АБДУЛЛИНА ЗЕМФИРА, 1940 елгы.

«Мин шартлау вакытында колхозда эшли идем. Радиацияле кырдан бәрәңге, яшелчә җыйдым, шарлау вакытында кырда калган радиацияле саламның өске катын җиргә төшереп, яндыруда катнаштым, көлен җиргә күмдем. 1958 елның җәендә Рус Караболагы авылында радиацияле кирпечләрне чистартып, чүп-чарын чокырга күмүдә катнаштым, яхшыракларын машинага төяп, үзебезнең авылга кайтардык, өстән шулай куштылар. Мин шул елларда ук бик көчле нурланыш алган булганмын. Хәзер миндә яман шеш, бөтен хатын-кыз органнарым операция белән алып ташланган, үземдә көчле кан басымы, колакларым начар ишетә. Мин бу авыруларымның радиация белән бәйле булуы турында махсус белешмә дә ала алдым. Әмма шуңа карамастан, суд юлы белән минем ликвидаторлык статусын юк иттеләр. Хөкүмәт һәм атомчылар мине үлем чигенә китереп җиткерделәр, әмма һаман гаепләрен танырга теләмиләр».

ГАЛИУЛЛИНА ГӨЛСӘЙРӘ:

«Шартлау вакытында миңа 23 яшь иде, мин икенче балама авырлы идем. Әмма шуңа карамастан, мине дә радиацияле кырга куып чыгардылар, борынга җиткән корсагым белән шул агу арасында казынырга мәҗбүр иттеләр. Мин бу хәлләрдән могҗиза белән генә исән калдым, хәзер үзем дә, балаларым да чирле. Бу хакта махсус белешмәләрем дә бар. Шуңа карамастан, моннан 5 ел элек, судлашып, Чиләбе хакимияте минем ликвидаторлык статусымны тартып алды. 5 ел буе мин ликвидаторлык акчасын алмасам да, компьютерда алган булып торганмын һәм миңа зур налоглар китереп салдылар һәм пенсиямнән тотып калдылар. Мин тормышымны очын-очка чак ялгап барам, хөкүмәт мине чирле ясады, талады, мыскыл итте... Бу татар хатыны берни аңламый, берни эшли алмас, дигәннәрдер инде... Башта безне радиацияле авылда калдырып черетттеләр, хәзер соңгы саулыгыбызны һәм сумнарыбызны да тартып алалар. Татар булганыбыз өчен безне шулай мыскыл итәләр ахыры...»

Радиациягә каршы көрәш активисты, бөтен суд эшләрен башлап йөрүче, Озерский шәһәреннән торып, авыру авылдашларына ярдәм итәргә алынган Гөлчәһрә Исмәгыйлова мең тапкыр хаклы - ТАТАР КАРАБОЛАГЫ АВЫЛЫН РАДИАЦИЯ НӘТИҖӘЛӘРЕН ӨЙРӘНҮ ӨЧЕН КҮЧЕРМИЧӘ КАЛДЫРГАННАР. ТАТАРЛАР АТОМ ТӘҖРИБӘСЕ ҮТКӘРҮ ӨЧЕН КИРӘК БУЛГАННАР. Бу хакта инде хәзер Чиләбе экологлары да, Мәскәү журналистлары да ачыктан-ачык сөйли. Менә «Московский комсомолец» газетасыны» Урал (Екатеринбург һәм Свердловский өлкәләре) өчен чыгарылган махсус саны. Анда, ачык итеп, татарлар өстендә тереләй атом тәҗрибәсе уздырылуы турында фикер әйтелә. Әмма бу материал газетаның Чиләбе өлкәсе өчен булган кушымтасында бөтенләй бирелми, югыйсә язмада сүз нәкъ менә Чиләбе өлкәсендә эшләнгән ГАСЫР ҖИНАЯТЕ турында бара бит. Мәкаләнең татарларга караган өлешен укучыларга тәкъдим итәбез:

«Нигездә руслар гына яшәгән Рус Караболагы авылын берничә көн эчендә юк итәләр, кешеләрен куркыныч урыннан башка җиргә күчерәләр. Ә аның адашына, ягъни, татарлар яшәгән авылга, бөтенләй кагылмыйлар да, аны радиоактивлы җирдә иза чигәргә калдыралар.

Җирле хакимиятнең һәм совет яшерен органнарының ни өчен шулай сайлап кына эш итүләренә җавапны Татар Караболагында әле һаман тапмыйлар. Дөресерәге, алар бу хакта сорамыйлар да, чөнки «Маяк» фаҗигасен кичергән күп кенә картлар русча начар сөйләшәләр һәм русчаны авырлык белән генә аңлыйлар. Хакимият шушы милли чарасызлыктан файдаланган да инде һәм авылны виварийга, ягъни, радиациянең кеше организмына озак вакыт һәм комплекслы тәэсир итүен өйрәнү объектына әйләндергәннәр... Даими рәвештә нурланыш алып торган халыкны өйрәнү нәкъ менә илленче елларда, Уралда башлана. Бу тәҗрибәне «Маяк»ның радиоактив болыты астына эләккән һәм Теча елгасыннан радиоактив калдыклы суны эчкән кешеләр өстендә уздыралар. Галимнәрне куркынычсыз урынга күчерелгән кешеләргә караганда, радиациядән зарарланган урында яшәп калучылар күбрәк кызыксындыра. Шуңа күрә күзгә күренми торган ак үлемнән үләргә татар авылы Караболакны калдыралар, Теча елгасы буена урнашкан, халкы, нигездә, татарлардан торган зур Мөслим авылын башка урынга күчермиләр. Бу хәлне белеп эшләгән геноцид, ягъни, махсус үтереп бетерү дип әйтмичә мөмкин түгел.

Бу фәнни эшләр белән тулы бер Мәскәү институты шөгыльләнә. Һәр җәйне диярлек Чиләбе өлкәсенә башкала доцентлары һәм кандидатлары килә, алар тереләр һәм мәетләр өстендә тәҗрибә уздыралар. Алар яңа күмелгән каберләрне ачып, мәетләрнең сөякләрендә күпме цезий һәм стронций тупланганын үлчиләр. Махсус аппаратлар ярдәмендә, алар исәннәрнең тәннәрендә күпме радиоактив пычрак җыелганын һәм эчке нурланышның нинди тизлектә барганын тикшерәләр.» *(«МК», 2002, № 24.)*

Мәскәү галимнәренә без өстәмә мәгълүмат бирә алабыз - алар тәҗрибә үткәргән Мөслим һәм Татар Караболагы

авылы кешеләре инде рактан үлеп бетеп баралар. Хәзер бу авылларда өченче, дүртенче буын нурланыш авырулы кешеләр туа тора, үлә тора... Менә Татар Караболагыннан гына да кайбер яңа мәгълүматлар. 1957-58 елларда радиация пычрагын җыештыруда катнашкан РӘЙСӘ ХӘСӘНОВА язмышы:

- Беренче баласы 6 ай торганнан соң үлә;
- Икенче баласы туу белән үлә;
- Өченче баласы - туганчы ук үлә;
- Дүртенче баласы бер ел торып үлә;
- Бишенче баласы туу белән үлә;
- Соңыннан сул ягыннан калкансыман бизе алына. Моның радиация нәтиҗәсе икәнен табиблар кире какмыйлар.;
- Уң як калкансыман бизендә шеш табалар;
- Аның бердәнбер исән калган баласының баласы булмый.

Рәйсә Хәсәнованың Чиләбе судына язган гаризасыннан өзек:

«...Әлбәттә, мин үлгән булсам, беркемгә дә мәшәкать булмас иде, әмма мин яшим һәм газапланам, минем бердәнбер кызым да газап чигә, мин үземнән соң беркайчан да сәламәт нәсел калмасын белеп тә газапланам...»

Чиләбе өлкәсендә моннан 45 ел элек кенә түгел, бүген дә татарлар өстеннән тәҗрибә үткәргәннәре сизелә. Россиянең башка өлкәләрендә радиациядән зарар күрүчеләр җиңел генә тиешле статусларын алганда да, биредә аны бирмәс өчен хакимият көне - төне судлашырга әзер. Бигрәк тә, татарлар белән, Татар Караболагы авылы халкы белән. Нәрсә бу - 45 ел элек эшләгән җинаятьне һаман танырга теләмәүме, әллә татарларны ахыргача изү, сыту, юк итү сәясәтеме?

Тарих өчен тагы бер язманы китапка кертеп калдырырга булдык, ул - Татар Караболагы авылы халкының Чиләбе өлкәсе губернаторы СУМИН ПЕТР ИВАНОВИЧКА хаты:

«Хөрмәтле ПЕТР ИВАНОВИЧ!!!

Зур канәгатьләнү белән шуны белдек, Сез ГАРТМАНны өлкәнең социаль хезмәт җитәкчелеге вазый-

фасыннан азат итәргә җыенасыз икән. Бу исә Татар Караболагы авылы ликвидаторлары өстенә килгән бәхетсезлекләрнең сәбәпчесе Сез булмаган ахыры, дип уйларга нигез бирә. Чөнки инде тиешле таныклыклары булган йөзләгән ликвидаторны юк итү кампаниясен Сезнең исем белән бәйли иделәр...

Соңгы елларда ликвидаторларга каршы алып барылган рәхимсез кампания Чиләбе өлкәсе тарихында кара тап булып калыр. Тарих тикшерер һәм үз ноктасын куяр - кешеләрнең газапларына нинди түрәләр сәбәпче булган. Хезмәт кешесенең кулыннан ашый торган түрәләр халыкка каршы эш йөртергә тиеш түгел. Сезнең, ниһаять, моны аңлавыгыз яхшы булган.

Халык бит ул чагында бу эшләрнең куркыныч икәнен белмәде һәм радиоактив пычрак астында калды, үз гәүдәсе белән башкаларны, шул исәптән, бу җансыз түрәләрне дә каплап, ликвидаторлык эшләрендә катнашты. Әмма тормыш азагында халыкка тагы да зур кимсетүләрне күрергә язган икән - аларның ликвидаторлык таныклыкларын да тартып ала башладылар. Шушы көнгә хәтле яши алган фәкыйрь һәм авыру кешеләр туктаусыз суд эшләрендә катнашырга тиешләр. Шаһитлар сүзе буенча карар чыгарган судьяга ышанмаучылык белдерделәр. Болай эшләүчеләрнең исәпләре бик гади, чөнки авыру һәм ярлы кеше, нигездә, карт-коры, бу суд эшләрен ерып чыга алмый - я ул үлә, я барысына да кул селти. Һәм шулай булып чыкты да. Хәтта пенсия алдындагы элеккеге ликвидаторлар да, Чиләбе өлкәсендә хаклык булуына ышанмыйча, кулларын төшерделәр.

Гартманның намусында дистәләгән авыруларның язмышы, аларны бит еллар буе суд юлларында йөрергә мәҗбүр иттеләр. Аның гаебе белән, күпләр бу тормыштан вакытсыз китеп бардылар, күпләр каты авырый. Судларда шундый хәлләрне дә күрергә туры килде - Гартманнан килгән япьяшь малай, инде ничәнче тапкыр, рак авырулы кешенең ликвидаторлык статусын юкка чыгарырга тырыша. Моның өстенә, Гартман күрше өлкәләрнең судларына да бирелдә яшәүче ликвидаторлларның таныклыкларын юкка чыгуру өчен үз кешеләрен җибәрә башлады. Безгә билгеле булган-

ча, судларга нык басым һәм эштән алу белән янаулар бара. Әмма барлык судьялар да бу басымга буйсынмадылар, кайберләре, төрле юллар белән булса да, ликвидаторларның законлы хокукларын яклый алдылар. Тик андый очраклар санаулы гына.

Безнең Шәрыкъта бер мәкал бар - «Кешегә ком белән бәрсәң, таш белән җавап алырсың», диләр. Бу авыру кешеләрне геноцидка тиң булган кимсетүе Гартман ханымның үзенә кире әйләнеп кайтмасмы икән? Аның үзенең һәм якыннарының да сәламәтлеге шушы хәлгә калмасмы? Бит Аллаһ барысын да күрә һәм барысы өчен дә тиешенчә бирәчәк!!!

Соңгы вакытта Чиләбе өлкәсенең Кыштым, Кәсле һәм Коншак районнарындагы социаль тәэминат бүлекләрен СУМИННЫҢ СОЦИАЛЬ МЫСКЫЛЛАУ органнары, дип атый башладылар. Без, Петр Иванович, шуңа өметләнәбез, ул урынга яңа кеше килү белән, бу структурага яхшы исеме дә кире кайтыр. Чөнки КЕШЕ ТУРЫНДА КАЙГЫРТУ - АНЫҢ ТӨП ЭШЕ БУЛЫРГА ТИЕШ БИТ.

*Хөрмәт белән — Татар Караболагы авылы халкы».*

Һәм без исән калган бу татарларның үзләре белән дә очрашырга булдык. Менә алар салкын, шыксыз клубта безнең каршыда тезелеп утырганнар... Кайсы - аяксыз, кайсы - кулсыз, телсез һәм күзсез... Күпләр өйдә чирләп, тора алмыйча, үлем көтеп ята икән... Милләттәшләребезне бу хәлдә күреп, безнең җаннарыбыз елады. Бу авылда да инде бөтен нәселләре, гаиләләре белән үлеп бетүчеләр бар икән. Исән калганнар, әрнеп, шул хакта сөйли, бездән ярдәм сорый... Клубка авыл интеллигенциясе - укытучылар, мәдәният хезмәткәрләре, дин әһелләре дә җыелган.

АБДРӘХИМОВА МАНСУФА, укытучы:

«Минем бөтен туганнарым рактан авырый яки инде үлеп бетте... Күбебез диагнозыбызны да белми үлә... Без биредә беркемгә дә кирәк түгел... Апам Салихова Саҗидә рактан үлде, аның ире Сабирҗан рактан үлде, икенча апам Сафина Мәүҗидә аяксыз утыра, аның ире Хәкимҗан күзсез, аяксыз калды, племяннигым Исмәгыйлев Марс 31 яшендә үлеп китте, бертуган абыем Гыйматов Мөкарам

тора алмыйча ятып үлде... Без монда барыбыз да үлеп бетәбез инде...»

ЙОСЫПОВ ӘСГАТЬ, пенсионер:

«Мин сезнең каршыда чуен аяк белән утырам, бер аякны кистеләр, инде икенчесен кисәргә җыеналар... Ул елларда мин радиацияле зонада лесник булып эшләдем... Бөтен лесниклар аяклары череп үлде... Миңа соңгы көнгә хәтле диагнозны дөрес куймадылар, диагноз билгеле булгач, инде соң, берни эшли алмыйбыз, диделәр, операциядән баш тарттылар... Бөтен нәрсәмне сатып, балалар ярдәмендә, 25 миллион (мең) сум акча түләп, операция ясаттым, аякны кистердем... Хатын 30 ел инде аяксыз ята... Без шушындый авыр хәлдә булсак та, радиациядән зыян күргән исәпләнмибез, льготалар юк, дарулар бушка түгел...»

ЙОСЫПОВ СӨНГАТУЛЛА, пенсионер:

«Мин 80нче еллардан бирле үлгән кешеләрнең исемлеген алып барам, мең ярым булды инде... Безнең авыл күчерелергә тиеш булган, чит ил белешмәләрендә ул «күчерелгән» дип язылган... Бу мәсьәлә буенча мин инде кайда гына бармадым - 15 кешелек делегация Чиләбегә дә барып карадык, безне бөтен җирдән куалар, тыңлыйсылары да килми... Башкорт корылтаенда да бу хакта сөйләдем, чакырдым - килмәделәр... Безнең хәзер бөтен өмететебез Татарстанда, Шәймиев безгә булышмасмы икән?»

Әйе, Башкортстанның да, район һәм өлкә җитәкчеләренең дә бу авыру татар-мөселманнар өчен Мәскәү белән араларын бозасылары килми. Шуңа күрә алар бу проблемаларга кагылмаска тырышалар, Татар Караболагы авылын, аның рактан кырылучы халкын күрмәмешкә салыналар. Менә шушы хәлләрдән соң да, инде авыл халкы рактан үлеп бетеп барганда да, аларның радиациядән зарар күрүләрен Россия хөкүмәте танырга теләми. Татар Караболагы авылы халкы белән бергә, безнең дә Россия хөкүмәтенә һәм «Маяк» берләшмәсенә берничә җитди сорабыбыз бар.

!. Әгәр Татар Караболагы авылы 1957 елда радиациядән зарар күрмәгән икән, ни өчен аны 1959 елда башка урынга күчерергә дигән карар чыгарыла?

2. Ни өчен 1958 елда радиация 45 кюри булган Урыс Караболагы авылы күчерелә, ә радиация 68 кюри булган Татар Караболагы авылы күчерелмичә калдырыла?

3. Татар Караболагы авылы халкы радиациядән зарар күрмәгән икән, ни өчен алар организмында радиация 46 сантизиверт, ә аның янындагы Мусакай татар авылы кешеләрендә хәтта - 110 сантизиверт? Бу бит - дөньядагы иң зур радиация күрсәткече!

4. Ни өчен гомер буе сау-сәламәт булган мөселман-татарларның бүген 90 проценты - гарип, чирле, үлем көтеп ята?!

5. Ни өчен Татар Караболагыннан чыккан тиресне хәтта шәһәр бакчаларына кертү тыелган, радияциле булган өченме? Ул чагында биредә кеше ничек яшәргә тиеш?

6. Ни өчен Татар Караболагы авылы халкыннан хәтта ликвидаторлык таныклыгын да кызганалар, АЛАР БИТ БАРЫСЫ ДА НУРЛАНЫШ АЛГАН РАДИАЦИЯ КОРБАННАРЫ?! Алар өстендә коточкыч тәҗрибә уздырылганы инде ачык күренеп тора, БУ ҖИНАЯТЬ, ГЕНОЦИД ӨЧЕН КЕМ ҖАВАП БИРЕР?!

Мөслим авылы белән чагыштырганда, Татар Караболагында сәяси активлык алай ук көчле түгел. Әмма биредә дә халыкның хокуклары өчен көрәшүчеләр, үзләрен һәм башкаларны яклап, суд юлларында йөрүчеләр, дөреслек эзләүчеләр бар. Аларның күпчелеге атомчыларның ябык шәһәрләрендә - Озёрскийда һәм Снежинскийда яши, аларның «За Караболку без радиации» дип аталган оешмалары да бар. Хәзер сезнең игътибарыгызга шушы актив татарлар тарафыннан Чиләбедә уздырылган экологик конференция өчен махсус хәзерләнгән

«Татар Караболагы проблемаларының бүгенге торышы» дип аталган язманы тәкъдим итәбез:

«Безнең бүгенге проблемаларыбызның төбендә ике сәбәп ята: Минсредмашның экономик хәле һәм «Маяк» берләшмәсе авариясе тирәсендәге серлелек. Авария нәтиҗәләрен бетерүне финанслау Минсредмаш өстенә йөкләтелгән иде, әмма бу структура, акчаны экономияләү максатыннан, җирле һәм үзәк хакимиятләрнең бөтен

карарларын үтәүне суза килде, ә кайберләрен бөтенләй үтәмәде дә. Бу хәл Татар Караболагы авылын күчермәүгә китерде. Серлелек мохите исә шундый хәлгә китерде, халык радиацияле җирдә яшәүнең куркыныч икәнен бөтенләй аңламады. 1957 елдан алып халык радионуклидлар 1000 Ки/кв км артык булган урында яши башлады. Нәтиҗәдә, авыл йортларында радиация бүгенге көндә 3 мәртәбә артты, стронций-90 буенча ул хәзер 3,5 Ки/кв км тәшкил итә. Халыктан яшерү, сер ясау шуңа китерде, күпләр үзләренең чын диагнозларын белмәделәр, нәтиҗәдә, авариядән соң халыкның ниләр белән авырулары беленмичә, өйрәнелмичә калды. Колхозның 3995 гектар җирләре яраксызга чыгарылды. Авыл территориясенең радиациядән пычрану проблемасын иртәме-соңмы барыбер хәл итәргә туры киләчәк, чөнки стронций-90 белән агулану һәр елны 2 процентка арта бара. Заманында яраксызга чыгарылган радиацияле җирләр өлкә җитәкчеләре тарафыннан яңадан көтүлек һәм печәнлекләр итеп халыкка кайтарылып бирелгәч, радиация белән агулану тизлеге тагы да арта.

Авылны бетерү өчен беренче адым 1959 елда аны Кояш совхозына бүлекчә итеп тапшыруда булды. Шулай итеп хакимият, бу совхозларны оештырганнан соң, икенче эш итеп, Караболак кебек авылларны башка урынга күчерергә уйлаган иде. Әмма соңыннан бу планнар онытылды. Авылларны бетерү буенча икенче адым туксанынчы елларда ясалды. Бу, нигездә, Кремльдә хакимияткә сәүдә-капитал тарафдарлары килү белән бәйле иде, алар өчен авыл хуҗалыгы продукцияләрен чит илдән кертү файдалырак булды. Әгәр өлкә түрәләре авылны радиацияле җирләрне чистарту планына кертә алган булсалар, әле авыл хуҗалыгын саклап калып булган булыр иде. Үлеп барган Татар Караболагы - өлкә җитәкчеләренең реабилитация өчен бирелгән бюджет акчаларын урынсызга куллану нәтиҗәсе дә ул...

Караболак авылының иң авырткан җире - бала вакытта ликвидация эшләрендә катнашучыларның проблемасы һаман хәл ителмәве. Безнең бөтен тырышлыкларыбызга карамастан, Сумин «ликвидаторларны юк итүче» структу-

раларын туктата алмады. Чиләбе өлкәсендә рәсми рәвештә танылган беренче кече яшьтәге ликвидатор пәйда булды.

Кулланылган җирләрнең, авылның, Караболак тугайларының радиациядән пычрану проблемасы да әле һаман хәл ителмәгән. Бу проблеманы авылны бөтенләе белән яки тулысынча күчереп, елгага юлны ябып, чиста су саклагычлар булдырып хәл итәргә мөмкин.

Караболаклылар өчен иң җитди проблема - аларның радиациядән зарар күрде дигән статуслары булмау. Нәтиҗәдә, хәтта рак авырулы кеше дә ниндидер ташламаларга дәгъва кыла алмый. Алдагы елларда бу мәсьәлә буенча нормаль закон проекты эшләү көтелми. Хәзер законга өстәмәләр кертү буенча губернатор каршында эшче төркем оештырылды, әмма бу эш ахырына кадәр җиткерелермеюкмы - хәзергә аңлап булмый. Тупланган радиация дозасы буенча законга өстәмәләр кертү караболаклар өчен әллә ни файда бирмәячәк, чөнки өлкәнең санэпеднадзоры Караболак халкында тупланган радиация дозасын 90нчы елларга караганда 2 тапкыр киметеп күрсәтергә тырыша.

Караболак шундый урынга урнашкан, анда туфракта уран тоннага 5-10 грамм туры килә, бу исә 1нче группалы иң югары күрсәткеч, дигән сүз. Безнең территориядә югары радон потенциалы да шуның белән бәйләнгән. РГПдан күренгәнчә, Татар Караболагы өчен еллык доза 6 мЗв икән. Әмма 7.3 НРБ-99 пунктыннан күренгәнчә, «...Табигый чыганаклардан нурланыш алучы җирле халык өчен тиешле доза билгеләнми». Әмма физика һәм медицина күзлегеннән караганда, бу - абсурд. Табигый чыганаклардан һәм техноген чыганаклардан алынган нурланыш берние белән дә аерылмый! Шулай итеп, 70 еллык гомере эчендә Караболак кешесе тагы 40 сантиЗиверт радиация дозасы ала. Ничек бу өстәмәне исәпкә алмаска мөмкин? Икенче яктан, НРБ-99ның 6.1 пукты производство шартларында табигый нурланышны 5 мЗв/год белән чикли.

Безнең авылның язмышы белән кызыксынган өчен, Караболаклар исеменнән «Яблоко» партиясенә зур рәхмәтләребезне әйтәсебез килә. Әмма авыл халкы арасында күчерү мәсьәләсе буенча сорашу-опрос аннан-моннан гына уздырылган булып чыкты. Без, мәсәлән, бу хакта

авыл халкының күпчелеге күчерүгә каршы тавыш биргәч кенә белдек. Бу - кешеләр белән ничек эшләргә ярамаганлыгы турында ачык мисал. Нигә җәмәгать оешмалары һәм инициатив группалар бу эштән читтә калган, ә сорашу белән җирле хакимият шөгыльләнгән һәм үзенә ничек кирәк, шулай кыландырган?. Алар күчерелгән очрактаниләр буласын кот чыгарлык итеп тасвирлаганнар, һәм, әлбәттә, боларны ишеткән теләсә кем күченүгә каршы тавыш бирер иде. Президент Путин телевизордан Караболак һәм Мөслим авылларын күчерәчәкбез, дип әйткән иде. Әмма без президент карарлары аның түрәләре тарафыннан үтәлми торган илдә яшибез. Хәзер дә түрәләр, медиклар, дозиметристлар, радиобиологлардан торган бер төркем табылачак, алар авызлары күбекләнгәнче, Караболак авылын күчерү - була торган эш түгел, абсурд, дип исбатларга тотыначаклар. Һәм күчерүгә каршы меңләгән дәлил табылачак. Менә аларның иң төп дигәннәрен карап китик:

Беренче аргумент: Аны Шойгу һәм өлкәнең кайбер түрәләре файдалана - имеш, Татар Караболагында радиациядән пычырану нибары 0,5-0,9 КИ/кв км стронций икән. Шойгуның бу дәлилен урынсыз дип табабыз. Билгеле булганча, атом энергиясен тыныч шарталарда файлалану буенча 1-нче халыкара конференциядә инглизләр Чемберлен, Лаутит, Мартин, Скот-Россель стронций-90 буенча пычрану ноктасын 2 КИ/кв км дан башларга тәкъдим иттеләр, бу очракта ул җирләрне авыл хуҗалыгы өчен дә файдаланырга мөмкин. 57нче елгы авариядән соң Минсредмашның комиссиясе шушыны механик рәвештә күчереләсе торак пуктларның чикләрен билгеләүгә күчереп куйдылар. Аварияның беренче елларында Караболак авылы халкы эчке һәм тышкы нурланышны башка радионуклидлардан да алуларын әйтергә кирәк. Рәсми рәвештә расланган буенча, Караболак җирләренең радиация белән пычрануы стронций-90 буенча 38 КИ/кв км тәшкил итә. Әмма радиациядән гомуми пычрану 20 тапкырга артыграк, ягъни, 700-800 КИ/кв км иде бит. Авариядән соң беренче елларда караболаклылар нәкъ менә шушы урыннарны файдаландылар. Нәкъ менә гомумпычрану мәгълүматларына таянып, хакимият күчерү мәсьәләсен хәл итәргә тиеш иде.

Күчерү мәсьәләсен стронций-90нан чыгып кына хәл итәргә тырышуның ялгыш юл икәнен халыкта бүген радиация дозасының билгесе күрсәтеп тора. Караболаклыларда радиация дозасының төп өлешен стронций-90 түгел, башка радионуклидлар алып тора.

Күчерүгә каршы булган икенче дәлил булып бу операциянең экономик яктан файдасызлыгы тора. Кайбер билгеле кешеләрнең бу мәсьәлә буенча әйткән сүзләрен китерәбез: «1-2 ел элек күчерелгәннәр алып өлгергән радиация дозасы белән күчерүләр китергән экономик зыянны чагыштырып карасаң, стронций-90 4-10 КИ/кв км булган урыннардан күчерүнең мәгънәсез һәм кирәксез эш икәнлеген аңлыйсың. (Костюченко, Батурин, Перемыслова, Аклеев, Романов, Волобуев, Даванков, Козлова, Чуканов, Штинов)». Әлбәттә, әгәр син сау-сәламәт булсаң, синең туганнарың да сәламәт һәм исән булса, салкын канлы булып, шундый дәлилләр дә китерергә була. Әмма мин, шул еллар сәбәпле дүрт туганымны югалткан кеше буларак, мондый дәлилләүне кеше ашаучылык белән тиңләр идем. Ул елларда бу мәсьәлә белән шөгыльләнгән радиобиологларның төп ялгышлары шунда, алар бары тик нурланыш авыруының килеп чыгышын кисәтүгә генә йөз тоттылар. Безгә исә, Караболак балаларына, 57-58 елар үзенең канлы понослары, баш авыртулары, югары температура, йөрәк уйнаулар, чәч коелулар, күз күрүе начарюлар белән дә истә калды. Әмма бу хакта сөйли башласаң, УНПЦРМ хезмәткәрләре мондый билгеләрне кире кагалар.

Күчерүгә каршы өченче дәлил итеп шуны китерәләр - имеш, күчерү халыкның үзе өчен бик зур психологик удар булачак. Һәм 50нче еллар ахырында халык күчерүне ничек кабул иткәнне мисал итеп китерәләр. Әлбәттә, радиацияле урыннардан халыкны системасыз, теләсә ничек күчерә башлау үзе үк кыргыйлык булган. Күрше авылларда хәтта кешеләрнең үз-үзләрен үтерү очраклары да булган. Хакимият ел буе беренче күчерелгән кешеләрне билгесез хәлдә тоткан. Аннан аларны шитовой йортларга керткәннәр. Әлбәттә, безнең көннәрдә халыкны башка урынга күчерү планлы һәм ачык рәвештә, халыкның үз күзәтүе астында узарга тиеш.

Караболакларның үз хокуклары өчен көрәшләрендә экологик һәм хокук яклау оешмалары арасындагы ыгы-зыгы да нык комачау итә. Билгеле булганча, бу ыгы-зыгы чит ил ярдәм акчаларын бүлешү аркасында килеп чыккан. Моның нәтиҗәсендә без - зарар күргәннәр зарар күрә. Суд эшләрендә бу оешмалардан җитди хокукый ярдәм юк. Зарар күрүчеләр сезнең берләшүегезне сорыйлар. Хөкүмәтне» радиациядан авыручылар исемлеген тарайтуына каршы, Дума депутатларының МРОТ урынына 100 сумлык түләү инициативаларына каршы, ликвидаторларны юк итүгә каршы бергәләп көрәшергә була иде бит! Әлбәттә, экология турында Россиядә иң беренче булып дәүләт кайгыртырга тиеш. Россиядә «Яблоко» кебек партиянең булуы бездә халыкны радиациядан саклауда дәүләт механизмлары да барлыкка килеренә өмет уята.

Безнең оешма сезгә ике тәкъдим белән чыга:

1. «Маяк» берләшмәсе эшчәнлегеннән зарар күрүчеләргә истәлек һәйкәле кую буенча фонд булдырырга. Бергәләп акча җыеп, бу һәйкәл ясауны Шемякин яки Неизвестный кебек зур художникларга тапшырырга кирәк. Бу бөтен дөньяда һәм Россиядә зур резонаннс тудырыр иде. Аны Чиләбе һәм Екатеринбург автоюллары кисешкән урында, радиоактив эзнең почмагына куярга кирәк. Мин, мәсәлән, бу һәйкәлне ана образында күрәм, ул үзенең яшь ярымлык баласын атом болытыннан капларга тырыша. Радиобиологлар әйтүенчә, бу яшьтә бала радиациядан иң зур зарар күрә икән.

2. Радиациядан зарар күргән кешеләрнең хокукларын бозган түрәләрнең символик клубларын төзәргә кирәк, ягъни, «радиаяциядән кеше ашаучылар клубы». Әгәр бу клуб әгъзаларының исемлеген һәр көн матбугатта игълан итеп торсаң, бәлки түрәләр «ликвидаторларны юк итү» кебек кампанияларга катнашудан тыелырлар иде. Бу клубка беренче әгъза итеп без Д. И. Ильинны, Чирковны тәкъдим итәбез, алар халыкны күчерүгә һәм кече яшьтәге ликвидаторларга каршы «уңышлы» эш алып бардылар. Сүзебезне исбатлау өчен, бер мисал китерәбез. Менә 1957 елны» 17 мартында Д. И. Ильин Минсредмашка нинди белешмә яза: «Теча елгасының суыннан һәм елга төбеннән алган анализ-

ларга таянып, төньяк канал аша Теча елгасын юдыруны һәм сусаклагычларның ташымавын тәэмин итеп, шундый нәтиҗәгә килергә мөмкин - Мөслим авылын һәм елга буендагы башка торак пункларын күчерергә кирәк түгел, шулай ук Теча елгасы ярларына саклагыч чаралар куярга да кирәк түгел». Үз карьералары хакына дистә меңләп кешенең сәламәтлеген корбан иткән мондый чиновникларга карата йомшак булырга ярамый. Безгә, гомумән, йомшак булырга ярамый, чөнки без зарар күргәннәрнең хокукларын яклаучылар. Әле халыкның радиациядән нинди зур зарар күрүен киң җәмәгатьчелек белеп тә бетреми. Әйтик, менә кем белә, әле без апрель аенда гына бала вакытта ликвидатор булган Ибәтуллин Насыйбулланы җирләдек, ә ул инде шул чакта ук чәчсез калган иде. Гомеренең соңгы елларын ул бик газапланып уздырды һәм тамырлары, йөрәге тартышып, тилмереп үлде. 1998 елда ул үзен ликвидатор итеп тануларын сорап, судка гариза бирергә тырышып карады, әмма суд хәтта аның гаризасын кабул итүдән дә баш тартты, Вяткиннан шундый яшерен күрсәтмә барлыгын әйткәннәр. Караболаклылар Снежинский шәһәр судына шундый гаризалар китергәч тә, судья Двоеглазов мондый гаризаларны алмаячагын әйтте. Шушы хәлләрдән соң караболаклар судларга гариза бирмәс булдылар...

Радиациядән зарар күргән халыкның хокукларын бозган һәм радиация куркынычсызлыгы буенча закон һәм нормативларны бозган берәр чиновникка күргәзмә суд оештыруны тәкъдим итәбез.

Радиациядән зарар күргәннәргә түләү мәсьәләсендә дә хәл ителмәгән нәрсәләр бар. Чернобыль һәм Маяк законнары буенча, бу түләүләр МРОТка күчерелергә тиеш. Әмма хакимият, зарар күргәннәрне тагы бер тапкыр мыскыллау өчен, МРОТка 100 сум акча күчерүне уйлап тапкан. Радиациядән зарар күрүчеләргә бу мыскыллауны юк итү буенча Россиянең Конституция судына мөрәҗәгать итәр вакыт җитте.

Безгә Россия президенты белән очрашуны сорар вакыт та җитте, чөнки Россиядә радиация куркынычсызлыгы буенча хокук бозу очраклары, хәл ителмәгән мәсьәләләр бик күбәйде. Беренче проблема - «Маяк» производство

берләшмәсе эшчәнлегеннән зарар күрүчеләр буенча закон проектының 15 ел буе дәүләт тарафыннан эткәләп йөртелүе. Икенче проблема - дәүләт структураларыны» ликвидаторларны юк итү буенча аңлы рәвештә алып барган көрәшләре. Өченче проблема - радиация куркынычсызлыгы буенча дәүләтнең ачык сәясәте булмау. Без, Караболак халкы, моны бигрәк тә ачык тоябыз. Без үзебезгә карата бер генә файдалы ярдәм дә күрмәдек. Татар Караболагы авылы - ВУРС (Восточно-Уральский Радиационный След) территориясендә иң зур зарар күргән күчерелмәгән авыл. 1956 елда туган кешеләрнең, әгәр алар 70 яшькә хәтле җитә алсалар, радиация дозалары 152 сантиЗиверт булачак. Әмма шуңа карамастан бу авыл 2010 елга хәтле төзелгән реабилитация чаралары планына кертелмәгән. Радиациядан зарар күргәннәрнең хокукларын яклау буенча азмыкүпме эш башкарылса да, ул дәүләт тарафыннан түгел, чит илләрнең ярдәмендә эшләнгән эшләр. Путин трибунадан җәмәгать оешмаларын яклау, Россиядә гражданнарның активлыгын көчәйтү, җәмгыятьнең халык тарафыннан контрольдә булуы, Россиянең шундый эчке төзелешкә омтылуы турында сөйли. Әгәр радиациядән зарар күрүчеләрнең хокукларын яклаучы һәм радиация куркынычсызлыгы буенча Россиянең бөтен оешмалары бу мәсьәләләрне тикшереп, дәүләт программасы кабул итү буенча мөрәҗәгать белән чыксалар, президент сайлаулар алдыннан мондый очрашудан баш тартмас иде. Президент белән сөйләшү Караболак кебек күп кенә авылларның мәсьәләләрен хәл итүгә бер этәреч булыр иде.

*«Радиациясез Караболак өчен» оешмасы. НИГЪМАТУЛЛИН ФӘРИТ НУРУЛЛА УЛЫ, ГАТАУЛЛИНА (ИСМӘГЫЙЛОВА) ГӨЛЬШАРА (ГӨЛЧӘҺРӘ) НАСЫЙБУЛЛА КЫЗЫ, ИБӘТУЛЛИН ФӘУКАТЬ НУРМӨХӘММӘТ УЛЫ. 1 июль, 2003 ел».*

Соңгы 5 ел вакыт эчендә авыл активистлары мондый хатларны кайда гына язмаганнар, кемнәргә генә җибәрмәгәннәр, нинди генә буш җаваплар алмаганнар... Ул хатлар, ул җаваплар тау-тау... Менә шуларны күргәч, Россия бюрократиясенең нинди таш-тимер кыя икәнен аңлый-

сың, аның артына яшеренгән Россия хөкүмәтенең кешеләргә карата ни дәрәҗәдә кансыз һәм сансыз булуын күреп, тетрәнәсең... Россия президентлары Ельцинга, Путинга, Россия дәүләт Думасына, прокуратурага, судларга, Россия Конституция судына, кеше хокуклары яклау комитетларына татарларны» тилмереп, ялварып язган хатлары... Инде бөтен дөнья күреп торган, кире каккысыз дәлилләр, галимнәрнең, «бу җирләрдә яшәргә ярамый» дип биргән белешмәләре, авыл халкының тулысынча рактан авыруы һәм үлеп бетеп баруы - Россия өчен болар берсе дә дәлил булып тормый... Россия дәшми, Россия күрми, Россия татарларга ярдәм итми...

## ТАТАР КАРАБОЛАГЫ АВЫЛЫ ХАЛКЫНЫҢ РОССИЯ ПРЕЗИДЕНТЫ БОРИС ЕЛЬЦИНГА ЯЗГАН ХАТЫ:

«Сезгә Уралдан, Чиләбе өлкәсенең Татар Караболагы авылы халкы, 1957 елны «Маяк» химкомбинаты шартаудан зарар күргән корбаннар мөрәҗәгать итә. Сезгә шуны да исегезгә төшерәбез, без Чиләбе өлкәсе картасында да, Кунашак районы картасында да юк, һәрхәлдә, без шунда җан асрасак та. Хәзер без Сезгә моның ни сәбәпле шулай булуын аңлатырга тырышырбыз, әлбәттә, әгәр ышансагыз, чөнки безгә беркем дә ышанырга теләми.

1957 елның каһәрләнгән ул 29 сентябрь көненнән соң инде 42 ел вакыт үтеп китте, әмма үлем һәр көнне безнең арабыздан 5-6 кешене алып тора. Кешеләр радиация белән бәйле рак, лейкоз, йөрәк, тамыр, тире авыруларыннан үләләр, инде өченче буында төрле гариплләр туып тора, бу хәлләр безгә ул куркыныч көнне бер генә секундка да онытырга ирек бирми.

1957 елның 29 сентябрендә Татар Караболагы авылы халкы, олысыннан-кечесенә кадәр - авырлы хатыннар, имезүче аналар, мәктәпкәчә яшьтәге һәм мәктәп балалары барысы да кырда, бәрәңге, яшелчә җыюда эшлиләр иде. Әлбәттә, беркем бернәрсә белмәде һәм кыр өстеннән, Татар Караболагы авылы өстеннән үтеп киткән сәер томанга да беркем игътибар итмәде. Без шулай сентябрь һәм октябрь айларында һәм 1957 елның ноябрь аена кадәр, беренче кар

төшкәнче шулай кырда эшләдек, һәм, әлбәттә, безнең җирләребез дә, кырларыбыз да, без җыйган уңыш та, без үзебез дә радиациядән зарар күрүебезне белмәдек. Тиздән, шул ук 1957 елда, безне» коеларыбызны тракторлар белән күмеп киттеләр, ә авылда калган 2-3 коега «Коедан су эчәргә ярамый!» дип, ә елга буендагы такталарга «Караболак елгасының суын эчү һәм файдалану тыела. Елгага хайваннарны һәм кош-кортны якын җибәрмәскә!» дип язылган иде.

Хәрби киемле кешеләр өйдән-өйгә йөреп, гаилә составын һәм эре мөгезле терлекләрне язып чыгып киттеләр, ә Татар Караболагы авылын башка урынга күчерергә вәгъдә бирделәр.

Бөтен җиргә милиция постлары куйдылар, Татар Караболагы авылына керү һәм аннан чыгу катгый рәвештә тыелды. Бездән 2 чакырымнар булган Рус Караболагы авылын шунда ук күчерделәр. Татар Караболагы авылы халкы, котлары чыгып, вәгъдә ителгән күчерүне көтте. Авылның төп халкы булмаган кешеләр үзләре үк чыгып качты. Өсләренә ак маскахалатлар, битләренә противогазлар кигән «сәер» кешеләр радиацияне тикшереп йөрделәр, приборлар нормадан йөзләгән тапкыр артык күрсәтә иде. Әмма меңләгән кеше яшәгән Татар Караболагы авылын күчерү хакимият өчен файдалы булмаган, ахыры. Бу Чиләбе өлкәсе өчен дә, Кунашак районына да шактый кыйммәткә төшкән булыр иде. Күчерәсе урында, безнең Жданов исемендәге татар колхозын Кояш совхозы дип үзгәртеп кенә куйдылар. Ә Хөкүмәт һәм Мәскәү алдында Караболак авылы күчерелде, дип хисап бирделәр, әмма кайсысы күчерелгән - урыс авылымы, татарымы - ул хакта җентекләп тормаганнар. Шулай итеп, 3 мең кешелек татар авылы, зур бер татар цивилизациясе җир йөзеннән юкка чыкты. Кем өчендер дәүләт сере, әмма безнең өчен 1957 елгы «Маяк» шартлавы туган җирләребездә 300 елга тормышны өзде, өметне бетерде. Билгеле булганча, радиация сазлыклы, түбәнсу урыннарда озак саклана. Шуңа күрә Бугай сазлыклары, куркыныч җанвар кебек, радиация таратып яталар, ә бу сазлыктан безнең Караболак елгасы башлана. Бу елга кайчандыр тирән сулы иде, хәзер инде кибеп бара. Менә 42 ел инде без

шушы Караболак елгасыннан су эчәбез, анда су керәбез, терлек-туарны, кош-кортны шунда җибәрәбез, чөнки безнең башка суыбыз юк. Нәтиҗәдә, радиация белән бәйле авырулар коточкыч арта бара. Безнең сорауларыбызга каршы Чиләбе өлкәсе, Татар Караболагы авылында туфракта радионуклидлар нормадан артык түгел, дип җавап бирә.

Беренчедән, безне аларның беркайчан да килеп тикшергәннәре юк.

Икенчедән, без, Татар Караболагы авылы халкы, бу җирләрдә яңа гына яши башламадык, шартауга хәтле дә монда идек, 1957 елгы «Маяк»тагы шартлаудан соң да, инде менә 42 ел, дәүләт гаебе белән, радиация йотабыз.

1957 елда «Маяк» шартлап, 42 елдан соң, без Чиләбе өлкәсе Дәүләт архивыннан һәм «Маяк» комбинаты архивыннан яшерен материалларны эзләп таба алдык. Анда Чиләбе өлкәсе башкарма комитеты рәисе урынбасары Мамонтов Е. В. га облисполкомның баш инженеры Э. Раск язган радиация нәтиҗәләре буенча хисап докладны бар. Анда: «1959 елның 25 июнендә НИИРГ ясаган нәтиҗә буенча, Багаряк һәм Татар Караболагы авылларыында, Караболак елгасында һәм тугайларында югары зурлыкта радиациядән пычрану күзәтелә, шулай ук бу торак пунктларда яшәүчеләрнең радиация белән бәйле авырулардан чирләүләре арта бара. Алга таба Багаряк һәм Татар Караболагы халкының биредә яшәүләре куркыныч, һәм аларны кичекмәстән күчерү кирәк. Күчерү 78,5 миллион сумга төшәчәк», диелгән. Әмма бу акчалар кайда киткән соң?

Бездән күптән инде Кояш совхозы баш тартты. Тирәюньдә йөзләгән чакырымнарда үле кыр, аларны шайтан таягы каплаган, менә дистә еллар инде бирегә бер нәрсә дә чәчелми, чөнки безнең ашлыкны беркем кабул итеп алмый. Авылның исән калган кешеләре (әгәр аларны шулай дип атарга ярасa), паспортларында мөһер торса да, шаһитлар булса да, үзләренең Татар Караболагында яшәүләрен исбат итә алмыйлар Чөнки 1957 елгы «Маяк»тагы шартлаудан соң, авыл халкының радиация пычракларын чистартуда катнашу фактын күрсәтмәс өчен, 1957-1958 еларда мәктәпне һәм авыл советы бинасын махсус ут төртеп яндырдылар. 1нче класстан башлап мәктәп балалары Рус Караболагы авылы территориясендә, Жданов исемендәге

колхоз кырларында, радиацияле җирләрдә эшләделәр, аларның бу хезмәтләрен бер урында да теркәмәделәр, хезмәт кенәгәләре дә бирмәделәр. Баш идарә начальнигы урынбасары Говорухин А. А әйтүенчә, имеш, «Маяк» архивларында һәм өлкәнең социаль яклау комитеты архивларында Татар Караболгы авылы халкын, мәктәп балаларын ликвидация эшләренә тарту буенча әмерләр юк икән. Ул чагында Татар Караболагы авылы халкы да, бигрәк тә, балалар, бернинди приказлар да таләп итмәделәр шул, колхоз председателе яки мәктәп директоры кайда барырга кушса, шунда бардылар.

Рус Караболагы авылы территориясе генә түгел, безнең бөтен Жданов исемендәге колхоз җирләре радиация белән агуланган иде. Ул чагында, 1958 елның язында, Рус Караболагы авылында чиркәүне шартлата башладылар, әмма, ни сәбәпледер, ахыргача шарлатып бетерә алмадылар. Шул кирпечләрне без кырып, чистартып, үзебезнең авылга ферма салырга ташыдык. Без бит боларны үз белдегебез белән түгел, начальство әйткәнгә эшләдек. Безне салам җыеп яндырырга да мәҗбүр иттеләр. Ни өчен? Дистә еллар инде безнең дәүләт Хиросимадагы атом шартлавын сөйли, шул ук вакытта Уралда Татар Караболагы авылының менә инде 42 ел буе радиацияле җирдә яшәп ятуын дәшмиләр. Дәүләт хәтта өлешчә дә безгә ярдәм итәргә теләми, әмма радиация аркасында югалткан сәламәтлекне инде ярдәм белән дә кире кайтарып булмый. Россия Федерациясенең исенә шуны төшерәбез - БЕЗ 42 ЕЛ БУЕ РАДИАЦИЯЛЕ ҖИРЛӘРДӘ ЯШӘГӘНЕБЕЗ ӨЧЕН, АГУЛАНГАН КАРАБОЛАК ЕЛГАСЫ ӨЧЕН ДӘҮЛӘТТӘН ТАТАР КАРАБОЛАГЫ АВЫЛЫНЫҢ ҺӘР КЕШЕСЕНӘ ТҮЛӘҮ ДӘГЪВӘ ИТӘ АЛАБЫЗ. Әмма безнең югалган сәламәтлегебезне инде берни белән дә кире кайтарып булмаячак...

Хәзер безнең белән чит ил галимнәре дә кызыксына, аларның беләсе килә - радиация тере организмга ничек тәэсир итә икән, һәм сөяк-җелекләренә хәтле радиация үтеп кергән кешеләр ничек үз гомерләрен яшәп бетерәләр... Шулай итеп, Мөслим авылы халкы кебек, Татар Караболагы авылы кешеләрен дә «тәҗрибә куяннары» кебек, тере организмга радиация тәэсирен өйрәнү өчен калдырдылар. Соң булса да, безгә ярдәм итүегезне, авылга махсус тикшер-

үчеләр җибәрүегезне, безне Закон белән яклавыгызны сорыйбыз. Без барыбыз да үлеп бетәбез бит инде...»

Әмма Мәскәү татарларга ярдәмгә ашыкмый. Коры җавап, өстән төшерү өчен генә язылган буш сүзләр... «Сезнең хатыгызны, тикшереп, чара күрү өчен, Чиләбе өлкәсе хакимиятенә җибәрдек...» Чиләбе исә татарларның җан газаплары белән язган хатларын район үзәге Кунашакка җибәрә, район исә җирле үзидарәгә төшерә. Кояшның татарларны күрә алмаган җитәкчесе бер кычкырып көлә дә, шуның белән эш бетә...

Заманалар үзгәрә, президентлар алышына, һәм татарлар инде Россиянең яңа патшасына, ярдәм сорап, яңа хат язалар...

**ТАТАР КАРАБОЛАГЫ АВЫЛЫ ХАЛКЫНЫҢ РОСИИЯ ПРЕЗИДЕНТЫ ВЛАДИМИР ПУТИНГА ЯЗГАН ХАТЫ:**

«Сезгә менә инде йөзләрчә тапкыр могҗиза белән исән калган Урал татарлары - Чиләбе өлкәсенең Татар Караболагы авылы халкы яза. Исегезгә төшерәбез - без Чиләбе өлкәсе карталарында юк, хәтта судлар да безнең барлыкка ышанмый, әмма без бар.

Безнең хөкүмәт үзен гел якшы яктан күрсәтергә тырыша, имеш, ул башка халыкларга булыша. Кайдадыр бәла-казалар булса, кызганып, аны телевизордан күрсәткән булалар, радиодан сөйлиләр. Ә үзебезнең ил эчендә булган радиацион шартлаулар сәбәпле кешеләрнең газапланып үлүләре һәм тилмереп яшәүләре турында Президент та, министрлар да күрмиләр дә, ишетмиләр дә. Менә 42 ел инде без, Татар Караболагы авылы халкы, 1957 елда «Маяк»та булган радиацион шартлау аркасында шулай газапланып яшибез.

(Бу урында Борис Ельцинга язган тарихи мәгълүмат китерелә, шуңа күрә, аны күчереп тормыйбыз. - Ф. Б.*)*

Коншак районы архивында бер яшерен документ бар, анда 1957 елның 1 ноябренә Татар Караболагы авылының һәм Жданов исемендәге колхоз җирләренең ни дәрәҗәдә радиация калдыклары белән агулануы хәбәр ителә. Шулай итеп, барлыгы 3995 гектар җир, 3217 га авыл хуҗалыгы җирләре, 2374 га сөрү җирләре, 727 га печәнлекләр, 29 га көтүлекләр радиация белән агуланган, булып чыкты. Жданов исемендәге колхозның бөтен радиацияле җирләре авыл

хуҗалыгы өчен яраксыз булып чыкты. Ә кешеләр менә шушы үле җирдә инде 42 ел яшәп яталар...

Дәүләтнең безнең алда гаебе бик зур. Безне, Татар Караболагы авылы халкын, «Маяк» шартлаганнан соң радиация белән генә агулап калмадылар, ә тәҗрибә куяннары урынына шул үле җирдә яшәргә дә калдырдылар. Хакимиятнең иң зур җинаяте тагы шунда, ул безне, белә торып, кешеләре күчерелгән радиацияле Рус Караболагы авылына радиация калдыклары җыярга җибәрде. Рус Караболагы авылының соңгы кешесе чыгып китүгә, 1958 елның 1 апреленнән башлап, без ломнар һәм бульдозерлар белән кирпеч биналарны җимерә башладык: 2 таш йорт, май заводы, кибет, мәктәп, чиркәүнең кирпеч коймалары һәм үзе... Без шулай ук радиацияле кырларда салам, печән кибәннәрен яндырдык, агачларны төпләп, яндырдык, аннан ул җирләрне тирән итеп сөрдерделәр. Аннан бу җирләргә бездән яшь агач үсентеләре утырттырдылар...

Безнең шуны беләсебез килә - безне ул радиацияле кырларга өстәмә нурланыш, чир алырга кем җибәргән, кем шушы эшкә әмер биргән? БУ БИТ - ГАСЫР ҖИНАЯТЕ, ТАТАР КАРАБОЛАГЫ АВЫЛЫ КЕШЕЛӘРЕННӘН, ТАТАРЛАРДАН КӨЛҮ, МЫСКЫЛ ИТҮ! Шуңа күрә дәүләтнең бу җинаятен без судлар аша исбатларга тиеш түгел, ә бәлки Россиянең демократик судлары безне якларга тиеш. Дәүләт Татар Караболагы авылы кешеләре алдында түләп бетерә алмаслык бурычлы - югалткан сәламәтлегебез өчен, күргән газапларыбыз өчен, ишеткән мәсхәрәләребез өчен...

БЕЗ - УРАЛ ТАТАРЛАРЫ! Без 1957-1958 елларда документларыбызның да ни өчен юк ителгәнен, яндырылганын яхшы аңлыйбыз. Без радиациядән үлеп бетмәсәк тә, хөкүмәт, шулай итеп, безне күптән күмеп куйды инде, аның өчен без юк. БЕЗНЕҢ НИНДИ ҖӘҺӘННӘМДӘ ЯШӘВЕБЕЗНЕ БӘЛКИ СЕЗ БЕЛМИСЕЗДЕР ДӘ. УРАЛ ТАТАРЛАРЫНЫҢ ИСӘН КАЛГАН НӘСЕЛЕ СЕЗГӘ МОНЫ БЕРКАЙЧАН ДА ГАФУ ИТМӘЯЧӘК. ТАТАР КАРАБОЛАГЫННАН БЕР ГЕНӘ КЕШЕ ИСӘН БУЛСА ДА, БЕЗ РАДИАЦИЯ ҖИНАЯТЕНЕҢ ТЕРЕ ШАҺИТЛАРЫ БУЛЫП ТОРАБЫЗ.

Татар Караболагы авылы халкы, 1957 елгы шартлау нәтиҗәсендә, ихтыярсыздан радиация калдыклары белән агуланды, әмма татарлардан кала барысын да күчереп бетерделәр. Чиләбе өлкәсе хакимияте әйтүенчә, БУ - КЕШЕ ОРГАНИЗМЫНА РАДИАЦИЯНЕҢ ТӘЭСИРЕН МАХСУС ТИКШЕРҮ, БУ - ТАТАР-БАШКОРТ ХАЛКЫНА КАРАТА ЭТНОЦИД ҺӘМ ГЕНОЦИД.

Без Россия Хөкүмәтеннән һәм Россия Президентыннан түбәндәгеләрне таләп итәбез:

1. Россия Федерациясенең 1998 ел, 26 ноябрьдә кабул ителгән 175-ФЗ номерлы «О социальной защите граждан РФ подвергшихся радиации вследствии радиационного взрыва на ПО «Маяк» в 1957 году» дип аталган законының 1 статьясы, 4нче пукты нигезендә, без, Татар Караболагы авылы кешеләре дә, Мөслим авылы кебек, радиацияле территориядән күчерелергә тиешле Россия гражданнары булып исәпләнәбез.

2. Судлар аша яки судларсыз, 1957 елгы шарлаудан соң радиацияле урыннарда эшләгән Татар Караболагы авылы кешеләрен ликвидаторлар итеп танырга.

Уралда татар халкы радиациядән үлеп беткәнче, безгә ярдәм итүегезне сорыйбыз.

Хәзергә каләм тота алырлык һәр Татар Караболагы авылы кешесе бу хатка кул куя.»

Әмма заманалар үзгәрсә дә, Караболак татарларына карата берни дә үзгәрми. Аларны күчерергә дип беркем килми, радиацияле җирдә яшәгәннәре өчен, аларга ташлама акчалары бирелми, ул гына да түгел, суд белән, булган азмаз льготаталарын да тартып алалар...

Татарлар тагын Мәскәүгә ярдәм сорап хат язарга мәҗбүр булалар...

### ТАТАР КАРАБОЛАГЫ АВЫЛЫ ХАЛКЫНЫҢ РОССИЯ ФЕДЕРАЦИЯСЕ ГЕНЕРАЛЬ ПРОКУРОРЫ УСТИНОВКА ЯЗГАН ХАТЫ:

«Безнең судларда татар халкына карата булган геноцид һәм этноцид, безгә карата булган гаделсезлек, татар халкының хокуклары кысылу һәм бозылу һәм Россия судларында булган законсызлык безне соңгы чиккә җиткерде.

Белгәнегезчә, 1957 елгы «Маяк»тагы шартлаудан соң, бездән ярты чакырым ераклыкта булган, безнең белән бер елга суын эчкән Рус Караболагын күчерделәр. Ә безне, Караболак татарларын, тәҗрибә куяннары кебек, бөтен дөньяның тикшерү лабораторияләре өчен калдырдылар. Югыйсә, без, татарлар да, 1957 елгы «Маяк»тагы шартлаудан соң зарар күргән торак пунктлар исемлегенә кертелгән идек бит. Һәм 1959 елның 29 сентяберендә 546 номерлы яшерен приказга кул да куелган булган. (№ 77 СС от 17.11.59 г.) Ул приказ «О немедленном выселении жителей села Татарская Караболка в деревню Аширова, Аливкуловского района, 8-е отделение Тахталымского совхоза Кунашакского района» дип атала.

«Маяк»та шартлаганга кадәр, безнең һәм русларның паспортларында авыл исеме бер иде - Караболак. Шуңа күрә, русларны күчергәч, без дә юкка чыктык. Хөкүмәт безне онытты, безне Чиләбе өлкәсе картасыннан сызып ташладылар, шулай итеп, халык җир йөзеннән дә юк иттелә... Без инде болай да үлемгә хөкем ителгәнгә күрә һәм дөньяда юк дип исәпләнгәнгә, хөкүмәт татар халкын радиацияле җирләрне чистартуда кол итеп файдаланырга булды. Безнең ризалык турында беркем сорап тормады, безнең нинди җәһәннәмдә эшлисебезне беркем аңлатмады. Без ялланкул, яланаяк радиацияле пычрак җирдә эшләдек, битлекләр кимәдек, безгә эшләгәнебезгә бернинди документлар бирмәделәр, шулай итеп, «дәүләт сере»н сакладылар... Ә без «тәҗрибә куяннары» булып тордык, шушы хәлләрнең корбаны булдык, зур түрәләр өчен без «дәүләт сере» идек... Әмма без сезнең исегезгә төшерәбез, әфәнделәр, БЕЗ ӘЛЕ ҮЛЕП БЕТМӘДЕК, менә инде 45 ел картада бөтенләй булмаган, өстенә РАДИАЦИЯ дигән аждаһа сулап торган радиацияле Татар Караболагы авылында яшибез. Бүгенге көнгә, ягъни, 2000нче елның 17 августына, Росгидрометның югары квалификацияле белгечләре әйтүенчә, без яшәгән Татар Караболагы авылында һәм суын эчкән Караболак елгасында стронций-90 ның күләме бер квадрат километргa 5-7 кюри булып тора, кайбер урыннарда хәтта 20 кюрига хәтле җитә! Ышанып булмыймы? Безгә дә ышанып бетмиләр, безгә хәзер бөтен дөньяның галимнәре килә.

Әмма безне Президент белән үзебезнең хөкүмәт кенә ишетергә дә, күрергә дә теләми. Безнең милләтебез инде үлеп бара, өченче, дүртенче буын гариплләр туа. Хәтта Россия Федерациясенең «О социальной защите граждан подвергшихся воздействию радиации в результате взрыва на ПО «Маяк» в 1957 году и, непосредственно участвовавших в работах по ликвидации последствий аварии» дип аталган Законыннан соң да безнең Хөкүмәт радиациядән зарар күргән Татар Караболагы авылын исенә төшермәде һәм ликвидаторлар алдында үзенең бурычын онытты. Аның каравы, бөтен матбугат чараларында Хиросима һәм Нагасакидагы шартлауны искә алдылар һәм матәм игълан иттеләр. Безнең Хөкүмәт түрәләре бигрәк «изге» инде, шулай бит?!

Һәм менә 45 елдан соң, Россия суд юлларында йөреп, күпме мыскыллау һәм түбәнсетү күреп, без, Татар Караболагы авылы ликвидаторлары үзебезнең хаклы икәнебезне исбатлый алдык. Ягъни, үзебезнең 1957 елгы «Маяк» шартлавыннан соң ликвидация эшләрендә катнашуыбызны документлар һәм шаһитлар ярдәмендә раслый алдык, моны Россия Федерациясенең 2000 елның 14 декабрендә кабул ителгән Законы да кире кагарлык түгел иде. (Статья 45, глава 27, часть 2 ГПК № 35.) Безнең ликвидация вакытында эшләвебезгә документлар 1957-1958 елларда мәктәптә һәм авыл советында «махсус янгын» вакытында юкка чыгарылганлыктан, ул чагында Хөкүмәт безгә бернинди документ та бирмәде, ә 45 елдан соң таләп итә.

1998 елда, Озерский шәһәр суды карары белән, Чиләбе өлкә суды тикшерүеннән соң, 45 ликвидаторга таныклыклар бирделәр. Һәм авыру кешеләр, үлем алдыннан булса да, шул мескен акчалар белән файдаландылар, ә 3 кеше, шул акчаларга ышанып, вакытынннан алда эшеннән дә китте. Әмма без тиз сөенгәнбез икән. Ике елдан соң Чиләбе өлкәсе суды рәисе Вяткин Ф. М., өлкә хакимияте башлыгы Сумин П. И. җитәкчелегендә һәм өлкәнең социаль яклау бүлеге начальнигы Гартман Н. А. ярдәмендә, безне кисәтеп тә тормастан, Озерский судының карарын юкка чыгарды.

Беркем дә радиация җәһәннәмендә эшләргә теләмәгәндә, без дәүләткә бушка ярдәм иттек, шуның өчен, 45 елдан соң булса да, Хөкүмәт үзе гафу үтенеп, бернинди судсыз, безгә бу ликвидаторлык таныклыкларын бирергә

тиеш иде. Аның урынына безне, концлагерьдагы кебек, суд залларында газаплыйлар, ә без җинаятьчеләр түгел бит. Менә без тагы 5 ел инде судлар белән «сугышабыз», инде ничә тапкыр исбатланган фактларны исбатлыйбыз, түбәнсетүләргә түзәбез. Хөкүмәт нәкъ шуны көткәнчә, 4 ликвидатор бу җәзаларга түзә алмыйча, үлеп киттеләр, чөнки безнең сәламәтлегебез инде болай да беткән. Акча юклыктан һәм авырулар сәбәпле, без Мәскәүгә хәтле барып җитә алмыйбыз, ә безнең документлар, мәгънәсез җаваплар белән, Чиләбедән кире кайта. Без 45 ел буе шушы каргалган, агуланган җирдә яшибез, һәм инде күбрәккә дә хакыбыз бар. Бер генә дәүләттә дә, бер генә закон буенча да инде бер тапкыр исбатланып бирелгән таныклыкны көчләп кире тартып алмыйлар! ТҮРӘ ӘФӘНДЕЛӘР, БЕЗ ҖИНАЯТЬЧЕЛӘР ТҮГЕЛ БИТ, Ә СЕЗ ЭШЛӘГӘН ҖИНАЯТЬНЕҢ ШАҺИТЛАРЫ ГЫНА!»

## ӘЙЕ, БУ ТАТАРЛАР — АТОМ КОРБАННАРЫ...

Татар Караболагы авылы - Россия дәүләтенең экологик, этник геноциды нәтиҗәсе... Татарлар шушы гасыр җинаятенең тере шаһитлары... Шуңа күрә Россия өчен аларның булмаулары, үлеп бетүләре кирәк. Шуңа күрә Россия бу татарларга ярдәм итми, ул гына да түгел, яңа радиация белән аларны тончыктырып, агулап тора. Шуңа күрә Россиядән ярдәм көтү - ул үтерүчедән мәрхәмәт көтү белән бер.

Инде бу хакта бөтен дөнья белергә тиеш - халыкара судлар, кеше хокукларын яклау оешмалары, экологлар, табиплар, галимнәр, сәясәтчеләр...

Бүгенге көндә бер күбәләкне, бер бөҗәкне саклап калу өчен халыкара оешмалар төзелә, зур акчалар тотыла, зур сүзләр сөйләнә...

Ә монда кеше хәтле кеше, милләт хәтле милләт терелэй Россиянең атом казанына салып кайнатыла!

«Маяк» берләшмәсе алга таба да үзенең эшчәнлеген шулай дәвам итә икән, мондый куркыныч, мондый газаплы үлем бер татарларга гына түгел, бөтен тирә-якка яный. «Маяк» берләшмәсе - бөтен дөнья өчен иң куркыныч, иң пычрак атом чүплеге... Шуңа күрә бүген сүз бары тик «Маяк» берләшмәсен яптыру турында гына барырга тиеш.

ТАТАР ФАҖИГАСЕ БӨТЕН ДӨНЬЯ ӨЧЕН ГЫЙБРӘТ БУЛЫРГА ТИЕШ.

...Татар Караболагы авылы үзенең тагы бер моңсу, хәвефле көзенә кереп килә... Аларны атом утына салып кайнаткан чорның 46нчы көзенә... Ул елны да халык, берни белми, бәрәңгесен алган, яшелчәсен әзерләгән, кышка дип, мал-туарын симерткән... Ул елны да кызлар, алдагы туйларын көтеп, кич утырып, чигү чиккәннәр, егетләр абзаркура яңартканнар, яңа йортларга нигез салганар... Әле беркем дә алда аларны нинди җәһәннәм газаплары көтеп торганны белми... Авылдан ерак түгел булган атом шартлавы аларны тереләй утта яндырасын, яшьтән үк бөтереп, кабергә кертәсен, баласыз, нәселсез, саулыксыз калдырасын, күпләрне тере гарип ясыйсын, бөтен авылның рак чиреннән кырыласын, исәннәрнең җүләрләнеп йөрисен әле беркем дә белми... Дистә мең еллар шушы җирдә яшәгән, борынгы сөн-гуннарның бөек нәселен дәвам иткән, Төрки каганатлар, Алтын Урда дәүләтләренең варислары булган Караболак татарлары, Атлантида кебек, бу дөньядан инде китеп бара иде...

## ТАТАР КАРАБОЛАГЫ АВЫЛЫНЫҢ СОҢГЫ КАҺАРМАНЫ, МИШӘР ХАТЫНЫ ГӨЛЧӘҺРӘ ИСМӘГЫЙЛОВАНЫҢ АТОМ ФАҖИГАСЕНӘ 45 ЕЛ ТУЛУ УҢАЕННАН АВЫЛДАШЛАРЫ АЛДЫНДА СӨЙЛӘГӘН ЧЫГЫШЫ:

*(2002 ел, 29 сентябрь.)*

*«ҮТКӘННӘРЕМ АВЫР ӘКИЯТ МИНЕМ...»*

Чыгышыма сүз башы итеп мин үзебезнең татар шагыйре Һади Такташның «Мокамай» шигыреннән әнә шул юлларны алдым... Әйе, моннан 450 ел элек, Иван Грозный Казанны алганнан соң, көчләп чукындырудан качып, Болгар җирләреннән бирегә килеп урнашкан татарларның язмышына зур фаҗига һәм авырлыклар туры килде. Куе урман эчендә, кечкенә генә елга буенда алар кыргый табыгатьтән һәм күрше кабиләләрдән зур тырышлык белән меңнәрчә гектар җирләр яулап ала алганнар, нык авыл һәм хуҗалык корганнар, патша чорын, революцияне, колхозлаштыруны, төрле сугышларны, репрессияләрне, радиа-

ция афәтен башларыннан кичергәннәр. Әмма алар өчен бүген иң газаплысы - авылның күз алдында үлеп баруы, бетүе...

Караболак халкы! Авылдашларым! Сезнең исемнән бүген бирегә килгән кунакларга рәхмәт әйтергә рөхсәт итегез. Башкалар, ахырысы, курыктылар һәм Чиләбе хакимиятенең бу күңелсез юбилейны күрсәтү белән мавыкмаска, дигән киңәшләрен тыңлаганнар. Әйе, без бүген моннан 45 ел элек булган авыр хәлләрне искә төшерәбез. Әйе, бүгенгесе көндә Россия белән аның атом-төш коралы булганга гына хисаплашалар. Әмма Россиянең бу чагыштырмача бәйсезлеге безнең сәламәтлегебез хакына яуланды. Атом-төш коралын ясауда күрсәткән ашыгычлык, кабалану соңыннан ВУРС һәм Теча проблемаларын китереп чыгарды. Советлар Союзы кыска вакыт эчендә атом калканын булдырды, әмма моның өчен без үзебезнең сәламәтлегебез һәм гомерләребез белән түләдек.

Әйдәгез, бу авария фаҗигасенең беренче көннәрен искә төшерик. Безгә бит бернәрсә дә хәбәр итмәделәр, без үзебезнең бакчаларыбызда, кырларда, урманнарда, өйләребездә коточкыч радиациядән тончыктык. Ничек итеп яшь балаларның, бернинди саклык чаралары күрмичә, яланкуллап, радиацияле бәрәңге-яшелчәне җиргә күмүләрен искә төшерик.

Алар бит шунда ук ашап, радиацияле елга суы да эчтеләр... Ничек итеп безнең авылны һәм елганы «ябып» куюларыын да искә төшерик... Ничек итеп 57 елның көзендә безне күчерергә әзерләүләрен искә төшерик... Ничек итеп без бу чорда баш әйләнүләрдән, күңел болганудан, канлы эч китүләрдән газаплануны да искә төшерик... Чәчләре коелган балаларны искә төшерик... Аларны дәваларга алып китүләрен, шуннан соң гына кайберләрендә яңадан чәч үсүен күпләр белмиләрдер дә... Безнең авылдашларны радиациядән дәваларга алып китүләрен дә бөтен кеше белмидер... Авылдашларның радиациядән үлүләрен дә күпләр белмидер, чөнки без аларны башка чирләрдән үлә, дип уйлый идек... Чөнки бездән дөреслек яшерелгән иде, хакимият тарафыннан дөрес диагноз кую тыелган иде. Авариядән соң 270 кеше авырды, дип әйтү ул ялган, ул

вакытта ук авыручылар һәм үлүчеләр саны 2 тапкыр күбрәк иде. Бу саннарны хокук яклаучыларга һәм экологларга ачарга кирәк әле. Шул радиацияле кырларны сөргән һәм инде дөньядан киткән авылдашларыбыз алдында, әйдәгез, башларыбызны иик. Шул агулы җирләрдә йөзләрчә гектар агач утырткан һәм иртә дөньядан киткән урман хуҗалыгы хезмәткәрләре хәтере алдында баш иик. Радиация пычракларын җыештырган һәм бик яшьтән дөнья куйган ликвидатор балалар алдында башларыбызны иик. Үзебезнең авыру аналарыбызны, хатын-кызларны искә төшерик, мөселман тәртипләре буенча тәрбияләнгән, сабыр, тыңлаучан, күп балалы гаиләләрне зур түземлек белән өстерәп барган ул апа-сеңелләр дә күбесе дөньядан китте инде... Радиация, нурланыш авыруыннан тыш, тагы бик күп авыруларның чыганагы булып тора. Иң беренче чиратта ул - рак, ягъни, яман шеш. Аннан тыш, ашказаны-эчәк авырулары, туры эчәк, йөрәк-тамыр авырулары, умыртка-буын чирләре, иммунитет белән бәйле авырулар, нерв системасының бетүе һәм хәтта күз авырулары... Бүген бигрәк тә нәни караболаклыларны исә алыйк, - алар я үле тудылар, яки бик иртә үлделәр, бүген авырулардан газап күрүче сабыйлар да бар... Дәүләт бүген бирегә җыелган гади кешеләр алдында зур бурычлы. Караболак проблемасын һаман хәл итмичә суза килү аның халыкара мәйданга чыгуына китерергә мөмкин. Түрә әфәнделәр, әйдәгез, без үз өебездә килешүгә килик инде, проблемаларыннан чыга алмаган Россия өчен тагы бер проблема тудырмыйк.

Мин бүген Караболак өчен иң мөһим булган мәсьәләләргә тукталырга телим.

**1.** Татар Караболагы территориясенең радиациядән пычрану дәрәҗәсе.

РосГидрометның хөкүмәт раслаган картасы буенча, авыл эчендә 7 кюри/кв км куелган. Бу карта турында без алар белән сөйләшкәч, алар бу тикшерүләрнең өстән-өстән генә булуы турында әйттеләр. Елга тугайлары да, хәтта Кече Татар Караболагы (Мусакай) территориясе да тикшерелмәгән, ул авылда, Халыкара Симпозиумда әйтелгәнчә, радиация 17 кюри/ккв км тәшкил итә. Ә зур һәм кече Караболак исемнәре алар шартлы гына, без бер авыл кешеләре

булып исәпләнәбез, паспортларыбызда да туган урыныбыз булып Караболак күрсәтелгән. 2000 елның 8 декабрендә Подтесов уздырган комиссия утырышында Караболак территориясендә радиация 2О кюри/кв км дип әйтелде, димәк, РосГидрометның да картасына төзәтмә кертергә кирәк. Татар Караболагында радиация дәрәҗәсен өйрәнгән тагы 4 оешма бар - Чиләбедәге ФИБ, Озерскийдагы шундый ук больница, «Маяк» һәм ОНИС, һәм Чиләбе санэпеднадзоры - аларда бик җитди материаллар бар. Хәзер радиациядән сер ясалмый, шуңа күрә без бу материалларны таләп итә алабыз. Шулай ук СССР хөкүмәте архивларында Урта Машина төзү Министрлыгы архивларында да Караболак буенча материал булырга тиеш. Бәлки биредә утыручы кайбер кунаклар безгә аларны алырга ярдәм итәрләр?

Елга буенча басылып чыккан материаллардан күренгәнчә, елгага юл ябылырга тиеш. Бүгенге көндә Татар Караболагы авылындагы бакча һәм ишегалларында да радиация белән пычрану арткannан-арта бара. Радиация печән, тирес, утын, авыл хуҗалыгы продукцияләре белән әнә шулай йортларга кайта! Хәзер мин сезгә шундый саннар әйтәм, аларны ишеткәч, чәчләрегез үрә торыр. 1997 елда Чиләбенең санэпеднадзоры ясаган рәсми хисап буенча, Кече Караболак җирләрендә радиация белән агулану - 38 ки/кв км, ә Олы Караболакта - 18 ки/кв км. Бу бит - без җиләк, гөмбә җыя торган урыннар, анда безнең малларыбыз йөри, балалар су коена, аннан без утын ташыйбыз, печән чабабыз, су эчәбез, һавасын сулыйбыз, кыскасы, без шунда яшибез. Безнең организмыбызга кергән барлык нәрсә - шуннан. Безнең авырулырыбыз, иртә үлем, балаларның саусызлыгы нәкъ шуның белән аңлатыла. Хәтерегезгә төшерәм - радиация 2 ки/кв км булганда, хакимият реабилитация чараларын күрергә тиеш, ә инде радиация 3 ки/кв км булганда, Чернобыль законы буенча, торак пункт башка урынга күчерелергә тиеш. Ә без биредә 38 һәм 18 саннарына ия!!! Бу - радиация эзе үткән иң югары күрсәткеч. 1997 елда Чиләбе санэпеднадзор тикшерүе буенча, Караболак кешеләрендә тупланган радиация 21 дән 96 сЗв (сантизиверт) тәшкил итә. Бу - радиация эзе үткән ВУРСта и» югары күрсәткеч. Исегезгә төшерәм, Россия законы буенча, ради-

ация дозасын 7сЗв алган кешеләр зарар күргән булып исәпләнә һәм льготалар ала.

**2.** Караболак халкының сәламәтлеге. Сәламәтлеккә иң зур зарар килгән вакыт авариядән соң беренче айлар һәм беренче еллар булды. Караболакта һәр гаилә, һәр нәсел 50нче еллар ахыры, 60нчы еллар башында туган авыру балаларга ия. Минем нәселемдә генә дә алар дүртәү. Ә Караболак буенча алар күпме? Күп нәрсәләр турында, без, гомумән берни дә белмибез, чөнки кешеләр вакыты җитмичә төшкән яки үле туган балалары турында әйтмиләр иде. Аларның да бәхетле булырга хаклары бар иде бит, әмма бу балалар яки үле туды, яки аларның тормышлары тоташ газапка әйләнде. Беренче еллар ликвидаторлары, бигрәк тә, сөякләре ныгып бетмәгән ликвидатор балалар зур зарар күрделәр. СССРның дәвамчысы булган бүгенге Россиянең мәкере бу бала ликвидаторларга каршы көрәштә бигрәк тә ачык күренде. Дәүләт бу балаларны радиация пычрагында эшләргә мәҗбүр итте, шулай итеп, аларның сәламәтлегенә әйтеп бетермәслек зыян салды, һәм, ахырда, ликвидаторлык таныклыкларын юк итә башлады. Әле алар пенсия яшенә дә җитмәгән иделәр, хәзер инде күпләре бу дөньяда юк. Күпләр суд юлларында йөргәндә үк үлеп киттеләр. Караболакның сигез зиратындагы кабер ташларыннан газаплы карашлар Чиләбе түрәләрен теге дөньяда да эзәрлекләрләр әле. Гаепле ике фамилияне мин хәзер үк әйтәм - болар СУМИН һәм ГАРТМАН. Караболак халкының сәламәтлеге буенча дөрес мәгълүматларны әйтеп булмый, чөнки СССРда радиация буенча дөрес диагноз куярга рөхсәт ителмәде, хакимият үз җинаяте өчен җавап бирергә теләмәде. Кайбер оешмалар бу юнәлештә эш алып бардылар, әмма безгә аларга юл ябык. Эш шуның белән дә катлаулана - архивлар юк ителә. Кайбер мәгълүматлар буенча, мәсәлән, «Маяк» архивында 1976 елга кадәр булган, радиация белән бәйле (ВУРС) күп документлар юк ителгән. Без соңгы 45 елда Караболак халкының гомер озынлыгы буенча мәгълүматларны булдырырга уйлыйбыз. Монысын бездән бер генә түрә дә яшерә алмый инде. Россиянең һәм халыкара экологик, хокук саклау оешмаларының безгә бу эштә ярдәм итүләрен сорыйбыз.

**3.** Ликвидаторларны юк итү мәсьәләсе.

Ликвидаторларны юк итү буенча оятсыз кампания бөтен ил буенча таралды, әмма бары тик Чиләбе өлкәсендә генә ул бөтенләй кешелексез һәм гарип төс алды. Гартманның йомышчылары Чиләбе өлкәсе буенча гына түгел, тирә-күрше өлкәләрдә дә суд протестлары белән чабулап йөриләр. Чиләбе өлкәсендә дистәләгән кешегә эшләрен судта караудан баш тарттылар, хәтта гаризаларын да кабул итмәделәр. Бер генә мисал китерәм. Татар Караболагының 20ләп ликвидаторын Коншак район судына чакыртып, штраф салу белән куркытып, дәгъвәләреннән баш тарту турында гариза яздыралар. Бу - чыкылдап торган законсызлык билгесе. Әгәр дә сез безнең ликвидаторлык эшләре яңадан каралсын, дисәгез, бергәләп Золотов исеменә гариза язарга кирәк, ышанам, ул чагында Коншакның бу суд хезмәткәре үз урыныннан пуля кебек очачак. Караболак мәктәбендә һәм Кояш совхозында оештырылган янгында безнең бөтен документларыбыз юк ителсә дә, без үзебезнең 1957 елгы авария нәтиҗәләрен бетерүдә катнашуыбызны исбат итә алабыз. Күп кенә кече һәм олы яшьтәге ликвидаторларның таныклыклары юк, әмма нык торырга кирәк. Үз хокукларыбыз өчен көрәшне туктатырга ярамый, алар безгә конституция һәм закон белән каралган. Сез, бу афәттән исән калучылар, илгә иң кадерле булган нәрсәне - сәламәтлекне бирдегез. Һәм дәүләт сезгә үзе салган бу зыянны капларга тиеш. Сез инде яшь түгел, авыру, сезнең балаларыгыз һәм оныкларыгыз да авыру. Сезнең күпчелегегез эшсез, я бик аз хезмәт хакы яки пенсия ала. Сумин һәм Гартманның кереме белән чагыштырганда, бу - диңгездә бер тамчы, әмма шуны онытмагыз - аларны бу тәхеткә сез утырттыгыз, алар сездән бәйле булырга тиеш, киресенчә түгел!!! Бу ташламалар сезгә аз булса да гомерегезне озайтырга ярдәм итәчәк.

**4.** Елгадагы хәл буенча.

Елганы тикшерүләр күрсәткәнчә, аның тугайларында бик күп радиация тупланган, бер квадрат километрга дистәләрчә кюри. Һәм бу радиацион агулану арта бара. Елына 2 кюри радиацияне Караболак территориясеннән агып килә торган елга калдыра, аның бер өлеше тугайларга һәм

елга ләменә утырып кала, аннан кеше организмына, хайваннарга, бакчаларга үтеп керә. Бу 2 кюри Караболакка радиация болыты үткән җирләрдән агып төшә. Икенче яктан елганы Төньяк проект харап итә, ул Теча каскадын Караболак белән бәйли. Аның әле ни дәрәҗәдә эшләвен без белмибез. Бәлки ул радиацияле суны Караболакка агызу яз көннәрендә яки яңгыр вакытларында гына буладыр - без белмибез. Моны әле өйрәнергә кирәк. Елгага өченче зур зыян - ул Кәсле шәһәреннән канализация суларын бирегә агызу. Моны Чиләбе түрәләре ел буе кире кагып килделәр, хәзер инде танынылар. Аннан Караболак елгасына промышленность һәм бәдрәф пычраклары, чистарту үтмәгән хәлдә, агып төшә, дигән шик бар. Елгадан килгән сасы исне шуның белән аңлатырга мөмкин, Бугай сазлыкларыннан томан рәвешендә килгән күгәрек тә шуның нәтиҗәсе булырга тиеш, менә дистә еллар инде июль аенда безнең бакчаларда үсемлекләр корый бит. 2001 елны елгада булганнан соң кыз баланың һәм Зәбир авылы хатынының үлүе дә суның канализиция һәм радиация белән пычрануына бәйле. Быел авылда үлгән ир-атның үлеме дә шуңа охшаш, диделәр. Бугай сазлыгында бик куркыныч инфекция яки химия калдыклары оялаган булырга да мөмкин. Моны әле тикшерергә кирәк. Без бу үлем турында сөйләп, кызның әнисен борчыйсыбыз килми, әмма Мәскәүгә җибәрелгән анализлар нәрсә күрсәткән, нинди диагноз куелган, бу хакта белергә кирәк. Моңа санэпеднадзор җавап бирер.

**5.** Караболакларга каршы эшләнгән җинаять.

Авариядән соң эшләнгән беренче җинаять - дәүләтнең бу хакта дәшмәве, бу хәлләрнең сәламәтлек өчен куркыныч икәнлеген әйтмәүләре, кайчакта хәтта махсус адаштыру, бутаулары. Хәтерлисезме, безне 1957 елны күчерергә әзерли башлагач, нефть табылу турында «җырладылар» бит. Төп зыянны халык менә шул беренче айларны һәм елларны күрде. Әгәр безгә элементар нәрсәләр турында вакытында әйткән булсалар, күпләр бүген дә исән булырлар иде, бу хәтле авырулардан газапланмаслар иде. Хәтерлисездер, үзләре безгә махсус ябык киемнәрдән килгәннәр, үзләре һаман нефть турында сөйләгән булалар!!!

Икенче зур зыян - дөрес диагноз куюның тыелуы булды. Бу - аерым тема, ул документларны эзләп табарга һәм

фаш итәргә кирәк. Әгәр туганнары кешенең нинди авыру белән чирләгәнен белмәсәләр, аны ничек дәваласыннар соң?!

Өченче зыян - хакимиятнең күчерү турында карарын үтәмәве.

Беренче карар 1957 елның көзендә кабул ителә. Татар Караболагын, Рус Караболагы белән бергә, 1958 елның язына күчерергә тиеш булалар. Бөтен хәзерлек чаралары күрелсә дә, бу эш эшләнмичә кала. Күчерү турында икенче карар 1959 елны кабул ителә. Һәм кешеләрне, череп бетәргә, тагы шул җирләрдә калдыралар.

Дүртенче зарар - шартлаудан соң Караболакның ике мең ярым гектар җире яраксызга чыгарыла, әмма 60нчы еллар уртасында аны яңадан халыкка файдаланырга бирәләр. Караблак халкының һәм елганың радиациядән тоташ агулануы башлана, үлем чире аларга утын, печән, җиләк, гөмбә, авыл хуҗалыгы продуктлары белән килә. Хәзер, ягъни, 2000нче елда ул җирләрдә радиация 100 ки/кв км га җитә, ә радиация фоны - сәгатькә 150 микрорентген, 60нчы елларда ул күпме булды икән?!

Бишенче зыян - бөтен дөньяда тиңе булмаган ҖИНАЯТЬ. УЛ - БАЛАЛАРНЫ РАДИАЦИЯ ПЫЧРАГЫН ҖЫЕШТЫРУДА ФАЙДАЛАНУ. Беренче мизгелдә радиация фоны сәгатькә 1000 микрорентгенга җитә иде, радиациядән пычрану берничә йөз ки/кв км булды. Нәкъ менә шунда көтүе белән балаларны кудылар. Алар, өлкәннәр белән бергә, радиацияле авыл хуҗалыгы продуктларын юк иттеләр, Рус Караболагы авылындагы чиркәүне сүтүдә катнаштылар, 1958 елның языннан башлап, һәр елны радиацияле җирләрдә агач утырттылар. Бу җинаять, Чиләбенең бүгенге җитәкчеләре тарафыннан бу кечкенә ликвидаторларга карата кылган мәкерләре сәбәпле, тагы да тирәнәя төшә. Түрәләрнең кансызлыгы, судлар, таныклыкларын юк итү, каршылыклар аларны инде ахыргача кабергә куып кертә. Ә бит аларга хәзер тынычлык, дәвалану кирәк, ә кеше нинди акчага ул даруларны алсын соң, ничек санаторийларга барсын, бу коточкыч тормышта ул әле гаиләсен дә туйдырырга тиеш бит. Һәм туктаусыз суд юлында чабарга...

**6.** Һәм соңгысы - Караболак буенча закон юнәлешендә эшләү.

Монда законда күрсәтелгән ике юл бар. Беренчесе - закон нигезендә Караболак өчен башка күчүчеләргә һәм эвакуацияләнгән кешеләргә бирелгән статусны ласларга, чөнки Караболакта радиация белән зарарлану аларга караганда да зуррак һәм авылны күчерү турында карар бар. Икенче - кешеләрдә тупланган радиация дозасы буенча. Әмма тупланган радиация буенча Теча законпроекты йомшак эшләнгән. Анда башка төрле саннарны салырга кирәк, әйтик, 50 сЗв һәм 70 сЗв - зур ташламалар белән, дип. Югыйсә, болай килеп чыга - кеше 90 сЗв доза туплый (безнең Караболакта күпләрнең шулай), ә нибары 200 сум акча ала, һәм сәламәтлеге дә инде юк. Бу хәл закон кабул иткәндә үзгәрергә тиеш.

Кадерле авылдашлар! Мин сезне актив булырга, үз хокукларыгыз өчен ахыргача көрәшергә чакырам. Россия дәүләте безнең өстә атом геноциды уздырды, әмма безнең рухыбызны үтерә алмады. Без, Урал татарлары, 7 миллион татар халкының бер өлеше, без ялгыз түгел - Аллаһ безнең белән, милләтебез безнең белән! Шуңа күрә Россия безне атом казанына салып кайнатып та, юк итә алмады, без, Караболак татарлары, каберләребездән чыгып булса да, аннан җавап таләп итәчәкбез! ИТӘЧӘКБЕЗ!!!»

Татар Караболагы авылы турындагы сүземне йомгаклап, сезнең игътибарыгызга бер исемлек тәкъдим итмәкче булам. «Маяк»ның яшерен архивларыннан зур авырлык белән алынган бу исемлектә Мөслим, Татар Караболагы, Багаряк авылларына караган мәгълүматлар бар. Бу - 1959-1960 елларда шушы авылларда алып барылган радиацион тикшерүләр буенча документлар исемлеге. Ягъни, безнең кулыбызда төп документлар, ул тикшерү нәтиҗәләре хәзергә юк, әмма тикшергәнлеккә белешмә бар. Аңлаган кешегә алар да күп нәрсәләр турында сөйли. Исемлекне «Маяк» архивыннан алынган тәртиптә тәкъдим итәбез.

**АРХИВ № 1**

Группа фондов НТД

ПЕРЕСЕЛЕНИЕ жителей деревень Челябинской и Свердловской областей из зоны аварии на комбинате 29.09.57 г.

Составлен архивистом группы фондов НТД ПО «Маяк» СПИРИДОНОВОЙ Л. А. Инв. № Арх. 329. 1993 г.

ПОСТАНОВЛЕНИЕ № 45 комиссии т. Одинцова от 7 января 1959 г.

Имеется резолюция т. Мишенкова:

«... Жителей живших ранее на Течи не переселять, т. к. это вызовет требование к переселению и у остальных жителей и, следовательно, и опытной станции в целом. Временные нормы необходимо применять для всех жителей поселка». (Мишенков Г. В. директор Госхимзавода имени Д. И. Менделеева в 1957-1960 гг., Ф. Б.) (ф.1, оп. 30 «в», ед. хр. № 38, л. 9).

РЕШЕНИЕ

Исполкома Челябинского облсовета от 5 мая 1959 г., о запрещении строительства на берегах реки Теча. В соответствии с постановлением СМ СССР от 20.03.57г. № 229-145 и рекомендацией института биофизики АМН СССР, исполком решает:

1. Запретить строительство производственных помещений, служебных зданий, жилых домов и культурно-бытовых объектов на берегах реки Теча на всем ее протяжении в пределах Челябинской области, в том числе в райцентре Бродокалмак, селах Русская Теча, Н. Петропавловская, Муслюмова.

Председатель обл. исполкома Г. Бездомов, (ф. 1, оп. 30 «в», ед. хр.38, л.41)

МАТЕРИАЛ ЦЗЛ

О загрязненности села Багаряк и д. Татарская Караболка. (ф. 11, оп. 8, ед. хр. 13, лл. 42-53)

РЕЗУЛЬТАТЫ обследования деревни Татарская Караболка Кунашакского района Челябинской области. (ф. 11, оп. 8, ед. 13, лл. 19-22)

ОТЧЕТ

Института радиационной гигиены, МСО-71 и др. о санитарно-радиационном обследовании села Багаряк и села Татарская Караболка и о состоянии здоровья населения с. Багаряк. Данные клинического обследования населения села Багаряк. (ф. 11, оп. 8, ед. 13, лл. 59-61, 81, 99).

РЕЗУЛЬТАТЫ

Обследования деревни Татарская Караболка Кунашакского района Челябинской области по состоянию на май 1959 г. (ф. 15, оп. 1, ед. 152, лл. 26-29)

РЕЗУЛЬТАТЫ

В-съемки с. Багаряк по состоянию на июнь 1959 г), (ф. 15, оп. 1, ед. 152, лл. 33-37)

ОТЧЕТ МСО-71

О санитарно-радиационном обследовании с. Багаряк Челябинской области, (ф. 15, оп. 1, ед. 152, лл. 46-50)

ДАННЫЕ клинического обследования населения села Багаряк Челябинской области, (ф. 15, оп. 1, ед. 152, лл. 51-66)

ДАННЫЕ клинического обследовании с. Татарская Караболка Кунашакского района Челябинской области, (ф. 15, оп. 1, ед. 152, лл. 67-78)

ДОЗИМЕТРИЧЕСКИЕ ДАННЫЕ ЦЗЛ

О загрязненности с. Багаряк и д. Татарская Караболка за период с декабря 1957 г. по июнь 1959г., (ф. 15, оп. 1, ед. 153, лл. 142-155)

ПОРУЧЕНИЕ директора комбината главному инженеру о создании комиссии по вопросу о дальнейшем проживания населения в селе Багаряк (протокол № ХМ/527/ Р от 11.02.60 г.,) (ф. 1, оп. 32, ед. 1, л. 21)

ПРОТОКОЛ совещания при зам. Министра т. Чурине А. И. от 09.02.60г. по вопросам произведения мероприятий в зоне радиоактивного загрязнении (решение Челябинского облисполкома № 546 сс от 29.09.59) о переселении жителей населенного пункта Татарская Караболка; о сооружении плотины у населенного пункта Караболка, (ф. 1, оп. 32, ед. 1, лл. 23-27)

**АРХИВ № 2**

инв. № Арх-332

ОБЗОР документов по аварии 1957 года на комбинате. Составлен архивистом группы фондов НТД ПО «Маяк» СПИРИДОНОВОЙ Л. А., 1994г.

ПРИКАЗ по ГХЗ № 107 от 17.04.58г.

О создании комиссии для оценки имущества граждан населенного пункта Караболка, (ф. 2, оп. 18, ед. 2, л. 19 н/с)

ПОСТАНОВЛЕНИЕ № 1 комиссия Одинцова В. Т. от 25.11.57 по результатам измерений загрязненности продуктов питания и фуража в д. Татарская Караболка, (ф. 2, оп. 13, ед. 5, лл. 180-181, 174-177)

ПОСТАНОВЛЕНИЕ № 11 комиссия Одинцова В. Т от 30.12.57. о рассмотрении состояния загрязненности сельхозпродуктов в деревне Татарская Караболка, (ф. 11, оп. 13, ед. 5, лл. 253-261), (ф. 15, оп. 1, ед. 139, лл. 1-9)

ДОЗИМЕТРИЧЕСКАЯ ХАРАКТЕРИСТИКА ГОРОДА

от мая 1959г., (район соцгорода и поселка № 2, состояние воинских частей в городе, совхоза № 2, водоемов, д. Кажакуль, Тат. Караболка, с. Багаряк, Чупрова, 7 пуктов Челябинской области, 44  по Свердловской области, (ф. 1, оп. 30 «в», ед. 55, лл. 263-271)

МАТЕРИАЛ ЦЗЛ Звереву А. Д., Бурназяну А. И., Бездомову Г. А. О загрязненности с. Багаряк и д. Татарская Караболка от 13.07.59г., (ф. 1, оп. 30 «в», ед. 36, лл. 162-175)

СПРАВКА о состоянии реки Караболка в результате ее загрязнения радиоактивными веществами (дозиметрическое обследование СЭС и службой внешней дозиметрии проведено в мае и сентябре 1959г.), (ф. 11, оп. 8, ед. 13, лл. 220-232)

РЕЗУЛЬТАТЫ обследования МСО-71 реки Теча и рек загрязненной полосы: Караболка, Боевка, Багаряк, Синара по состоянию на апрель-май 1959 года, (ф. 15, оп. 1, ед. 153, лл. 108-117)

СПРАВКА ЦЗЛ от 05.08.59г. О радиоактивной загрязненности рек Синары и Караболки за 1958-1959гг., (ф. 11, оп. 8, ед. 13, л 119)

РЕЗУЛЬТАТЫ обследования реки Теча и рек загрязненной полосы: Караболки, Боевки, Багаряка, Синары по состоянию на апрельмай 1959г., (ф. 1, оп. 30 «в», ед. 30, лл. 130-139)

ПИСЬМО ЦЗЛ в МЗ СССР от 11.01.60г. Данные распределения радиоактивности в русле, пойме и бортах долины рек Теча и Караболка, (ф. 11, оп. 10, ед. 15, л. 26-28).






# ДҮРТЕНЧЕ БҮЛЕК

## Аждаһа авызында

Сезгә атом бомбасы ясый торган шәһәрдә булырга туры килгәне бармы?

Җир асты һәм җир өсте саклагычларында 2 миллиард кюрига кадәр атом калдыклары саклаган, суда, һавада, туфракта радиация уйнап торган урында, ягъни, «Маяк» берләшмәсе урнашкан Озреский шәһәрендә булырга туры килде безгә. Бу урынның бөтен дөньяда иң куркыныч, радиациядән иң нык пычранган җир икәнен белсәк тә, милләттәшләребез хакына, без анда бардык. Чөнки хакимият белән радиациядән зарар күргән татарлар арасында судны нәкъ менә «Маяк» берләшмәсе урнашкан Озерский шәһәренә билгеләгәннәр иде. Халык яклаучылары буларак, бу суд процессында Бөтендөнья татар конгрессы башкарма комитеты әгъзасы буларак - мин һәм конгрессның юристы, адвокат Роза Фәрдиева да катнаштык.

Әмма, күпме генә эзләсәгез дә, сез бу шәһәрне Россиянең бер генә картасыннан да таба алмассыз, һәрхәлдә, ул инде ярты гасыр яшәп килсә дә. Башта ул «Десятая площадка» шартлы исемен йөртә, аннан - «почтовый ящик 21», аннан соң - Челябинск-40 (халык телендә - «Сороковка»), соңрак - Челябинск-65. Бары тик 1994 елда гына шәһәргә рәсми төстә Озерский исеме бирелә. «Маяк» комбинаты белән шәһәр бергә төзелә башлый, 1946 елдан башлап, Урал тауларының урман-сазлыклы бу урынында моңа

кадәр тиңе булмаган зур төзелеш башлана. Ни өчен атом бомбасы өчен плутоний нәкъ менә монда, биредә эшләнергә тиеш була соң? Белгечләр моның серен бу тирәдә су запасы күп булу белән генә бәйләп аңлаталар. Безгә калса, атом комбинатының нәкъ биредә төзелә башлавының башка сәбәбе дә бар. Төп сәбәп уран рудасы белән бәйле буларга тиеш. Плутонийны, ясалма юл белән, ураннан алалар, ә уран теләсә кайда очрамый. Элеккеге Советлар Союзында, ул, мәсәлән, башта Таҗикстаннан биргә кайтартылган, сугыштан соң уран рудасын Көнчыгыш Германия һәм Чехославакиядән дә ташыганнар. Әмма көне-төне реакторлар эшләп торсын өчен, дөньяда иң күп атом-төш коралы җитештерү өчен үз ураның булу кирәк. Биредә, ягъни, янәшәдәге Урал тауларында, уран ятмалары табылган булырга тиеш. Һәм алга таба нәкъ шушы хәл биредә атом комбинаты төзелүгә китергән. Әлбәттә, Мәскәүдән ерак булуы, шартлый калса, башкалага һәм үзәк регионнарга артык зур зарар килмәячәге дә үз ролен уйнагандыр. Биредә эшче көчләрнең күп булуы, карусыз һәм тырыш татарларны теләсә нинди зарарлы эшкә җигеп булу уе да үлем комбинатын биргә салырга этәреч булгандыр...

Атом реакторлары төзелә башлаганчы, бу хәвефле урыннан 100 чакырым радиуста кешеләр башка урынга күчерелергә тиеш булалар. Әмма хакимият моның белән маташып тормый, ә бары тик тирә-юньнән ышанычсыз дип саналган яки кайчандыр хөкем ителгәннәр генә куып чыгарыла. Шулай итеп, бу тирәдән 1161 гаиләне, ягъни, 2939 кешене Урал тау араларына - Златоуст, Йөрүзән якларына сөрәләр, алар арасында 16 яшькә кадәр 746 бала була. НКВД чекистлары аларны берничә сәгать эчендә өйләреннән куып чыгарып, бернәрсәләрен алдырмыйча, 300 тимер юл вагонына төяп, тау арасына илтеп ата... Бу операция белән Бериянең шәхси палачы, сугыш вакытында Кырым татарларын, чечен-ингушларны илләреннән сөргән генерал И. М. Ткаченко идарә итә... Атомга юл кешеләрнең күз яшьләре өстендә салына, аннан ул кеше сөякләре белән түшәлә...

Шәһәр иске бистә урынына төзелә һәм 1947 елда ук, СССР Министлар Советы карары нигезендә, ябык зона, дип

игълан ителә. Ул чәнечкеле тимер чыбык белән әйләндереп алына, анда вышкалар куела, ул каланчаларда кораллы хәрбиләр сакта тора. Бу зонада балык тоту, җиләк һәм гөмбә җыю, ау тыела, шул эш өстендә тотылган авыл халкын төрмә көтә...1954 елга хәтле биредә хәтта сайлаулар да уздырылмый, имеш, кеше санышнан чыгып, чит ил шпионнары биредә яшәүчеләрнең төгәл санын беләргә мөмкиннәр. Шул исәптән, 1956 елга хәтле бәйрәм демонстрацияләре дә уздырылмый. Биредәге бөтен власть Берия «служба»сы кулында, ягъни, чекистлар карамагында була. Берия үзе дә бирегә берничә тапкыр килеп китә, аны беренче чиратта шәһәр төзелеше, кешеләр язмышы түгел, атом реакторының төзелеше генә кызыксындыра. Сталин беренче атом бомбасын ашыктыра, шуңа күрә ил сугыштан соң җимерелеп ятса да, бөтен көчне шушы «Маяк» төзелешенә бирәләр. Бу эшкә дистә меңләгән кеше, хәрбиләр, тоткыннар тартыла, илнең төрле почмакларыннан вагон-вагон төзү материаллары, металл, җиһазлар килә.

1948 елның 19 июнендә, ниһаять, СССРда беренче промышленность атом реакторы эшли башлый. Бу «нечкә» эш белән «атом атасы» академик Курчатов үзе идарә итә. Шулай итеп, атом бомбасы өчен ураннан плутоний әзерләү промышленность юлы белән, күпләп эшләнә башлый. Ач, ярлы, хәерче ил бөтен көчен атом казанына сала... Ил, котырынып, корал ясау юлына баса. Бу эш зур дәүләт сере итеп саклана, шуңа күрә комбинатта һәр көн саен булып торган аварияләр турында да халыкка берни әйтмиләр. Илнең мифик «атом калканы» өчен биредә эшләүчеләрне һәм бу тирәдә яшәүчеләрне корбан итеп бирәләр. 1949 елның 29 августында исә казах далаларында. Семипалатинский тирәләрендә, беренче совет атом бомбасы сынала. Сталинның, Бериянең, атомчы академикларның шатлыклары эчләренә сыймый, атом болыты таралып өлгермәс борын, алар кочаклаша, үбешә башлыйлар... Соңыннан бу Семипалатинский шартлавы меңнәрчә, хәтта миллионларча совет кешеләрендә рак, йөрәк авырулары булып бәреп чыгар, бу тирәдәге халык чебен урынына кырыла башлар... Әмма «Илне атом афәтеннән саклыйбыз» дип үз-үзләрен алдаган

сәясәтчеләргә, хәрбиләргә, атомчыларга халыкның газап чигүе дә тәэсир итмәс... Беренче атом реакторы артыннан, 1950 елда «Маяк»та икенче реактор, 1951 елда өченче, дүртенче, бишенче атом реакторлары, 1952 елда алтынчы реактор сафка баса. Болар өчен күпме чыгым, күпме уран рудасы, күпме эшче көчләр кирәк бит! Җитмәсә, комбинатта һәр көн диярлек авария өстенә авария булып тора, тирәюньне атом калдыклары каплап китә, 30-40 яшьлек белгечләр тәгәрәп үлә... Авария саен диверсия эзлиләр, кешеләрне төрмәләргә озаталар, атом серен тышка чыгармас өчен халыкны корбан итәләр... Бу хакта «Маяк»та эшләп чыккан хезмәт ветераннары менә нәрсә яза:

*«В печати описывается только три радиоционные аварии на ПО «Маяк». Имеющейся у администрации ПО «Маяк» список содержит десятки радиационных аварий. Не кажется ли вам странным налечие при этом тысяч лучевых больных? Не стыкуются цифры количества радиационных аварий с количеством пострадавших. На самом деле только на радиохимическом заводе 25 произошли сотни радиационных аварий с тяжкими последствиями. В этом числе была и самопроизвольная цепная реакция». (Письмо ветерана «Маяк»а В. С. Сладкова, проработавший без малого 50 лет на радиохимическом заводе 235) - (Владислав Ларин. «Комбинат «Маяк» - проблема на века». Москва, 2001)*

Әмма «Маяк»та иң куркыныч һәм иң көчле авария 1957 елның 29 сентябрендә була. Бу хакта 90нчы еллар башына кадәр берни дә әйтмиләр, үзгәртеп кору чоры килгәч тә, халыкка авария турында бик аз мәгълүмат бирәләр. Рәсми мәгълүматлардан күренгәнчә, 1957 елның 29 сентябрендә «Маяк» комбинатында радиоактив калдыклар тутырылган саклагыч шартлаган. Әмма хәзер кайбер белгечләр әйтүенчә, ул чагында «Маяк»та атом-төш шартлавы булган. Бу махсус оештырылган сынау-шартлаумы, әллә атом бомбасының очраклы шартлавымы, яки атом реакторының җимерелүеме - моны бары тик аерым кешеләр генә белә булыр. Әмма, ни булса да, бу шартлау-

ның нәтиҗәсе коточкыч була. Атом болыты бер чакырым биеклеккә күтәрелә һәм 1000 чакырым җирне агулап уза. Шартлаудан соң, Урал таулары өстендә атом аҗаганы уйнап тора, моның нәрсә икәнен белмичә караган кешеләр шунда ук сукыраялар... Шартлау кичке 4 тулып, бишенчедә була, кояшлы күк йөзе кинәт кенә карала һәм шәһәр караңгылык эчендә кала. Сакчы этләр күккә карап улый башлый, кошлар кинәт кенә сайраудан туктап кала... Кешеләрнең башларына исә кисәге-кисәге белән радиоактив калдыклар ява... Тиздән бу кешеләр барысы да нурланыш авыруыннан үлеп бетәләр...

Хәзер галимнәрнең әйтүенчә, 1957 елда «Маяк»тагы атом шартлавы һәм дөньяга радиоактив калдыклар таралуы Чернобыльгә караганда күпкә көчле һәм артык була. Бу хәлләрне күргән кешеләр соңыннан менә ничек тасвирлыйлар:

«Мощность взрыва, действительно, была огромной. Она оценивается в 70-100 тонны тринитротолуола... Взрыв полностью разрушил банку из нержавеющей стали, находившигося в бетонном каньоне на глубине 8,2 м. Бетонная плита перекрытия, весом 160 тонн, была сорвана с места и отброшена на 25 м. в сторону. Разорванные листы нержавеющей стали, из которых была сварена емкость, были разбросаны в радиусе 150 м от эпицентра взрыва.» *(Владислав Ларин. Комбинат «Маяк» - проблема на века. Москва, 2001г., стр. 43.)*

Бу атом шартлавыннан иң зур зыянны Озерский шәһәре үзе күрә. Тирә-юньдә агачларга хәтле бер яфраксыз кала. Биналар барысы да радиация белән пычрана. Хәтта шул чагында да халыкка дөресен әйтмиләр, саклык чаралары күрмиләр, шәһәрнең бер өлеше шул чагында радиациядән үлеп беткәндә дә, аннан дәүләт сере ясыйлар. Ә «Маяк»ның җимерелгән биналарын радиациядән чистартырга солдатларны һәм тоткыннарны куалар... Ул кешеләрнең дә күбесе тиздән якты дөнья белән хушлаша. Соңыннан бу хакта элеккеге хәрби, ликвидатор Николай Иванович Панасенко менә нәрсә яза:

«Когда после года бешенной работы на засыпке эпицентра взрыва, наш полк был построен перед отправкой нас по

домам, полковник Сюськин сказал: «Дорогие товарищи, вы сделали большое дело для нашей Родины. Вы сделали возможное и невозможное, и вам один год этой работы зачтется за пять и на пенсию пойдете, если доживете, в 50 лет. Вас, дорогие товарищи, Родина не забудет!» Мне 56 лет, а все, кто со мной рядом работал тогда, в 1958 году, уже умерли. Скоро и я умру, а жизни так и не видел». *(В. Новоселов, В. Толстиков. Тайна «сороковки». Екатеринбург, 1995, стр. 287.)*

1957 елгы атом шартлавы шәһәрне генә түгел, ул тирәдәге бик күп авылларны да агулап уза. Кешеләрнең кайберләрен, ашык-пошык, башка урынга күчерә башлыйлар, ә кайберләренә бөтенләй кул селкиләр, чөнки атом шартлавыннан зыян күрүчеләр йөз меңнәрчә була... Бернәрсә белмәгән авыл халкын НКВД солдатлары һәм тоткыннары чорнап ала... Ирләрне һәм хатын-кызларны аерым сарайларга бикләп куялар. Аларны шәп-шәрә калдырып чишендерәләр, өсләренә хлор сиптерәләр, киемнәрен утка ягалар. Авылдагы бөтен терлек-туарны бер җиргә җыеп, атып үтерәләр һәм чокырга күмәләр. Мескен авыл халкына берни аңлатмыйлар, аларның күбесе бу хәлләрдән акылыннан шаша... Асылынып үлүчеләр дә була... Кешеләргә өйләреннән бер нәрсә алырга рөхсәт итмиләр, күз алларында өйләрен ут төртеп яндыралар... Үзләрен исә икенче бер радиацияле урынга илтеп ташлыйлар, аларны такта йортларга урнаштыралар. Кышкы Урал салкыннарында бу русларның һәм башкортларның күбесе катып үлә, калганнары радиациядән җан бирә... Әмма болар турында сез рәсми мәгълүмат чараларыннан берни дә тапмассыз, бу фаҗигале хәлләр хакында могҗиза белән исән калган кешеләр үзләре сөйли... Алар «Маяк» тирәсендә һәр авылда бар әле - совет режимының, атомчыларның тере корбаннары, исән шаһитлары...

Шәһәр бүгенге көндә дә, закон нигезендә, ябык зона санала, махсус режим белән яши, чөнки аның территориясендә күпләп юк итү коралы, радиоактив матдәләр саклана. Чит кешеләргә шәһәргә керү мәсьәләсен бары тик Мәскәү ФСБсы гына хәл итә, хөкем ителгәннәр, органнар өчен шикле тоелган кешеләр бирегә керә алмый. Шәһәрдән

чыгып китү дә күрсәтелгән көндә булырга тиеш, юкса, алып китеп, ябып куярга да мөмкиннәр. Шәһәр тирәсендә видео-фото аппаратлар белән төшерү тыелган, моның өчен дә алып китәргә мөмкиннәр икән. Шәһәр капкаларында кораллы сакчылар тора, компьютер синең җиде бабаңны тикшерә, шикләнсәләр, тотып тентергә дә мөмкиннәр. Озерский шәһәре ярымутрауга урнашкан, аны бөтен яктан да диярлек диңгездәй Иртәш күле әйләндереп алган. Кешеләрнең әйтүенчә, күл астыннан электр чыбыклары китә икән, ягъни, су юлы буйлап беркем дә «Маяк»ка якын барырлык түгел. Шәһәрнең коры җир белән тоташкан урыны биек таш коймалар белән урытып алынган, ул коймаларга көчле электр тогы тоташтырылган... Дәүләт сере, атом бомбасы биредә әнә шулай кырык йозак астында саклана. Кешеләрне, аларның сәламәтлеген, табигатьне саклау өчен дәүләт шуның хәтле тырышса иде... Әмма Россиядә беренче урында кеше түгел, КОРАЛ тора шул.

Айлар буе әнә шулай ФСБда тикшерелеп, суд процессысында татарларны яклаучылар буларак катнашканга гына, без бу яшерен шәһәргә үтеп керә алдык. Шәһәрдә 80 меңгә якын кеше яши икән, шуларның 7-8 меңе татарлар булырга тиеш. Татарларның санын чама белән генә әйтүебезнең сәбәбе шунда, биредә алар турында төгәл санны беркем белми дә, бирми дә. Озерский шәһәрендә тирә-яктагы татар авылларыннан, бигрәк тә, Татар Караболагыннан күп кеше яши һәм эшли. Тирә-юньдә башка эш булмаганлыктан, татарлар үзләрен юк итә торган атом промышленностына барып бил бөгәргә мәҗбүрләр. Әмма татарларның биредә эштән башка, берниләре дә юк - алар ана телләрендә белем ала алмыйлар, сора-сорап йөреп тә аларга мәчет урынына хәтта бер бүлмә дә бирмәгәннәр. Шәһәр читендәге татар-мөселман зираты да инде рус зираты белән кушылып беткән, шуңа күрә мәет булса, татарлар аны авылларга алып китеп җирлиләр. Шул ук вакытта дәүләт руслар өчен зур милли театрлар, уку йортлары тота, биредә музыка мәктәбе, музыка училищесы, зур китапханә бар, биредә рус телендә 15 урта мәктәп эшли, 5 профтехучилище, колледж бар, Мәскәү институтының филиалы эшләп килә. Милли-мәдәни чаралар шулай югары куелган булуга карамастан,

шәһәрдә наркомания өлкәгә карагада 5 тапкыр артык. Белгечләр әйтүенчә, Озерский шәһәрендә яшәүчеләрнең 60-70 проценты психикаларына зыян килгән кешеләр. Бу наркоман һәм психикасы тотрыксыз кешеләр кулында уран, плутоний, атом бомбасы һәм меңләгән тонна атом калдыклары барлыгын белгәч, тәннәр өшеп китә. Чөнки Озерский шәһәрендә яшәүчеләрнең күпчелеге «Маяк»та эшли бит, атом бомбасы да алар кулында. Үзгәртеп кору елларында, Россия коралына ихтыяҗ кими төшкәч, «Маяк»та матди яктан хәлләр бик начарайган булган. Хәзер исә, бөтен дөньяның атом калдыклары бирегә агыла башлагач, «Маяк» та аякка басып килә. Биредә эшләүчеләрнең уртача хезмәт хакы хәтта 50-60 меңгә җитә, дип сөйлиләр, шуңа күрә, үлем куркынычы булса да, кешеләр бирегә ябышып ята, китмиләр. Әмма шәһәрнең бюджет системасында эшләүчеләр акчаны бик аз ала - айга нибары 600-700 сум. Шәһәр үзе бай күренсә дә, халык шактый фәкыйрь һәм авыр тәэсир калдырды. Дөресерәге, авырулар күп икән, дигән тәэсир калды. Чөнки миллиардлаган кюри атом калдыклары өстендә утырып, сәламәт калып булмыйдыр ул. Өлкәнең һәм шәһәрнең ялланган ялагай белгечләре, бер авыздан, Озерскийда тормышны җәннәт итеп күрсәтергә тырышсалар да, урамдагы халык үзе турында үзе сөйләп тора. Ә урамда авырулар, аякларын чак өстерәп йөрүчеләр, артык симез (100-150 килограммга хәте) яки артык ябык, кипкән, гарип-гораба кешеләр күп очрый. Биредә рак белән авыручылар, өлкәгә караганда, 20 процентка күбрәк икән. Безнең фикеребезчә, бу сан тагы да зуррак булырга тиеш, чөнки кем белән очрашып сөйләшсәң дә, үзе яки туганнары рак белән авыруы билгеле була. Радиация һәм рак авыруы бу шәһәргә, бу кешеләргә инде мәңгегә, китмәскә һәм бетмәскә дип кереп оялаган. Биредә рак белән радиация дөнья беткәндә генә бетәчәк, яки, биредәге радиация, атом афәте бөтен дөньяның башына җитәчәк.

Рәсми хакимият күпме генә яшерергә тырышса да, рак һәм радиация белән бәйле авырулар барыбер халыкка билгеле була. Дөресен әйткәндә, беренче атом бомбасы ясаучылар барысы да дип әйтерлек рактан үлеп бетәләр. 1956 елга хәтел биредә режим бик көчле була, шәһәргә бер кергән

кешене яңадан чыгармыйлар. Рак һәм нурланыш авыруы белән бик нык чирләп китүчеләр дә дәваланырга шәһәрдән читкә чыга алмыйлар. Үлсәләр дә, аларны ябык шәһәр территориясендә күмеп куялар. Ә яман шеш һәм нурланыш авыруы белән чирләү уран белән эшләүнең беренче көннәрендә үк башлана. Чөнки баштагы чорда комбинатта бернинди саклык чаралары да күрелми, радиактив матдәләрне чиләк белән ташып йөртәләр. Ә радиациянең бөтен пычрагын исә турыдан-туры елга-күлләргә ташлап баралар. Комбинат эшчеләре белән бергә, тирә-күрше авылларда яшәүчеләр дә кинәт күпләп үлә башлагач кына, Мәскәүдә атом бомбасы, уран, радиоактив калдыклар белән сак эш йөртергә кирәклеген аңлый башлыйлар. «Маяк»та эшләүчеләрнең һәр ай саен каннарын алып, тикшереп торалар, күпләрдә шул вакытта ук нурланыш тамгалары күренә башлый. Атом-төш нурланышының тәэсирен өйрәнү өчен, реактор зонасында шахталарда этләрне тота башлыйлар. 1949 елны беренче рәсми «нурланыш» авырулы кеше пәйда була, әмма врачларны алга таба бу диагнозны куймаска кисәтәләр һәм алар гомуми диагноз кую белән чикләнәләр. Менә безнең кулыбызда «Плутоний в девичьих руках» дип аталган китап. Анда сүз «Маяк» комбинатының химико-металлургия заводында, плутоний цехында эшләгән хатын-кызлар турында бара. Шунысын да әйтергә кирәк, иң куркыныч бу цехта күпчелек югары белемле химик хатын-кызлар эшли һәм атомның мәкерле, астыртын һөҗүмен беренче булып алар кабул итә. 1500 кеше эшләгән химико-металлургия заводында 400 кеше нурланыш белән хисапка куела, ягъни, һәр дүрт кешенең берсендә рак табалар.

«За все время работы на заводе было зарегистрировано приблизительно 400 человек, имеющих профессиональные заболевания. В основном, эти люди, работавшие на заводе в период 1949-1956гг. Сейчас, сорок лет спустя, в живых из них осталась половина. Большинство умерли в возрасте 40-45 лет. Из числа умерших 54 % погибли от злокачественных опухолей легких, печени и саркомы костей - это очень высокий процент раковых заболеваний.» (Л. П. Сохина, Я. И. Колотинский, Г. В. Халтурин. «Плутоний в девичьих руках», Екатеринбург, 2003, стр.135.)

Менә шулай, беренче атом бомбасы ясаучыларның күпчелеге, 50 яшькә дә җитмичә, рактан газапланып үлә. Аларның күпчелеге, әле үзләре исән чагында ук, Ленин ордены, Дәүләт премияләре алалар, зур исемнәргә лаек булалар, әмма яман чирдән котыла алмыйлар, нәселләрен дә шушы газапка дучар итәләр. Күрәсез, рактан, нурланыш авыруыннан бер Мөслим һәм Татар Караболагы авылы халкы гына кырылмый икән, бу гасыр чире, иң яшерен кабинетларга үтеп кереп, иң югары урында утыручыларны да чүпли тора. Әле күптән түгел генә «Маяк»ның генераль директоры Фетисов, 50 яшендә, баш мие рагыннан зур газаплар белән үлеп китә... Беркем бу чирне тотып кала алмый - электр тогы уздырылган биек таш коймалар да, миллиардлаган акча да, Караболак халкының чебен урынына кырылуын күзәтеп торган галимнәр дә... Бу яман чир атом белән, уран белән, радиоактив матдәләр белән бәйле һәр кешене эзләп табарга һәм үзене» мәкерле эшен эшләргә мөмкин. Һәм эшли дә инде...

Алга таба кешелек барыбер бер сорау алдында калачак - атом кораллары, атом прмышленносты, атом электростанцияләре кирәкме, яки кешенең сәламәтлегеме? Атом белән бәйле төбәкләрдә кешенең гомер озынлыгы хәзер 45 яшьтән узмый, анда үлүчеләр туучыларга караганда ике тапкыр күбрәк, рак авыруы, нигездә, радиация белән бәйле урыннарда тантана итә. Алга таба бөтен кешелекне дә менә шушы көн көтәргә мөмкин. Шуңа күрә Озерский шәһәрендә яшәүчеләрнең ясалма тынычлыкларын, калай әтәчләнеп, патриотланып маташуларын мин кабул итә алмыйм. Имеш, аларга берни дә янамый, имеш, алар өлкәдә иң чиста шәһәр, имеш, авыручылар да алай күп түгел... Бу - «Маяк»ның һәм рәсми хакимиятнең көчле пропагандасы нәтиҗәсе һәм чарасызлык билгесе. 2 миллиард кюри атом калдыклары өстендә утырганда, чит илләрдән 20 мең тонна атом калдыклары керергә торганда, борын астында гына атом электростанциясе төзелеп ятканда, тагы да кыска итеп әйткәндә, АТОМ БОМБАСЫ ӨСТЕНДӘ УТЫРГАНДА, ничек шулай идиотларча тыныч, шат һәм канәгать булырга мөмкин икән?! Дөресен әйткәндә, «Маяк» комбинаты 1957 елгы атом авариясеннән соң ук ябы-

лырга тиеш иде. Шул вакытта ук халыкка дөресен әйтеп, зирәк карар кабул ителгән булса, Чернобыль авариясе дә булмыйча калган булыр иде. Шушы хәтле зур афәтне, шушы хәтле куркыныч эшне яшерергә мөмкин идеме соң?! 57 елгы шартлаудан иң зур зыянны да шушы Озерский шәһәре халкы, «Маяк»та эшләүчеләр үзләре күрә бит! Һәм беренче булып, инде үзгәртеп кору чоры килгәч булса да, «Маяк»ны яптыру, ә анда эшләгән һәм шәһәрдә яшәгән кешеләргә гомерлек компенсация түләү мәсьәләсен дә алар куярга тиеш иде. Ә алар исә, бүген тук яшәү бәрәбәренә, мәңгелек чир алып яталар, гарип балалар, черек нәсел калдыралар, бөтен дөньяны куркыныч астына куеп, радиация белән агулап яталар... Алар да - Россиянең сугыш сәясәте корбаннары, үзләре дөньяга чыгарган җимергеч атом корбаннары... Әмма кеше бу дөньяда ни өчен яшәгәнен, үзеннән соң нәрсә калдыруын бер туктап уйларга тиеш бит инде, ил белән бергә эшләнгән фаҗигале хаталар бер төзәтелергә тиеш! Кеше гомере, кешенең сәламәтлеге, җан тынычлыгы кайчан да булса беренче урынга чыгарга тиеш бит!

Озерский шәһәрендә яшәүчеләрне һәм «Маяк» берләшмәсендә эшләүчеләрне нинди киләчәк көткәнен ачык күз алдына китерү өчен, Владислав Ларинның «Комбинат «Маяк» - проблема на века» китабыннан бер өзек китереп үтәбез:

«В 1973-1982гг. уровень заболеваемости раком оставался высоким в 3-5 раз (в небольшой группе женщин 60-69 лет - в 10 раз) соответствующие показатели остальных жителей Челябинска-65. В структуре злокачественных новообразований по прежнему первое место занимал рак легкого: у мужчин - 38,7 %, у женщин - 17,5 %; второе место - рак желудка у мужчин 16,0; и рак печени у женщин15,0%; третье место - рак кожи у мужчин и женщин (13,5 % и 12,6 % соответственно).

Было установлено связь частоты рака легкого с величиной поглощенной дозы от попавшего внутрь организма плутония. В последние годы отмечена тенденция к росту числа заболеваний раком печени и поджелудочной железы». (Москва, 2OO2 г., стр. *211 )*

Ягъни, «Маяк» берләшмәсенең төп продукциясе булган плутоний кеше организмына һава, су, ризык аша үтеп керә һәм, нигездә, бавырда (30% ) һәм сөяктә(50% ) туплана һәм аларны эчтән җимерә башлый. Плутонийның сөяктән тулысынча чыгып бетүе өчен 1500 ел вакыт кирәк!! Озерский шәһәрендә һәм «Маяк»та, аның тирәсендә бөтен җирдә - радиация, атом калдыклары, плутоний һәм стронций... Карап торышка шәһәр бик чиста һәм матур булып күренсә дә, бу матурлык артында адым саен үлем сагалап тора... Бу тирәдәге гүзәл күлләрдә кеше зурлыгындагы сукыр мутант балыклар йөзеп йөри, халык аны тотып ашый, биредә, һич башка җирдә булмаганча, җиләк, гөмбә котырып үсә - кешеләр аларны җыеп ашый... Биредә эчкән суда, ашаган ризыкта, сулаган һавада - радиоактив матдәләр, радиация... Кешеләр шул шартларда яши... Чиләбе галимнәре исә «Радиациянең кеше организмына уңай тәэсире» дигән темага фәнни эшләр язалар... Кешеләрне аңгырайту, сукырайту, алдау һаман дәвам итә...

Шәһәрнең чагыштырмача төзек һәм тәртипле булуы да күпләрдә ясалма тынычлык тудыра. Әйе, биредә урам тутырып йөргән наркоманнарны, сукбайларны, хәер сорашып утырган чегәннәрне күрмәссең, чөнки аларга шәһәргә керү тыелган. Бирегә, гомумән, хөкем ителгән кешеләргә керү тыелган. Шуңа күрә шәһәрдә наркоманнар саны өлкә белән чагыштырганда биш тапкыр күбрәк булса да, алар кулга эләкмәскә, күзгә чалынмаска тырышалар, чөнки хөкем ителсәләр, аларны бу шәһәргә башка беркайчан да кертмәячәкләр. Шуңа күрә күп җинаятьләр урамга чыкмый, өйдә, тимер ишекләр артында бара. Шуңа күрә, шәһәр халкының, шул исәптән, «Маяк»та эшләүчеләрнең дә яртысыннан артыгы - психик авыру. Курку, ярсу, туктаусыз хәвефләнеп яшәү эчкә киткән, башка бәргән... Ә шушы кешеләр кулында - атом ректорлары бит... «Маяк» һәм Минатом ситемасында эшләүчеләрнең кайбер авырулары турында Чиләбе экологы, физика-математика фәннәре кандидаты Светлана Лучич менә нәрсә яза:

«... На химико-металлургических заводах Министерства РФ по атомной энергии зарегистрировано около 2 тысяч носителей плутония с повышенным содержанием его

в организме и доказана прямая связь между плутонием и заболеванием раком легких. В структуре профзаболеваний работников Минатома 58 % занимают болезни, вызванные воздействием радиоактивных веществ. За последние 5 лет рост заболеваний злокачественными новообразованиями таких работников составил 28 %(это намного больше темпов роста по России). При этом резко увеличилось число больных, впервые выявленных в запущенной стадии, снизился процент этих заболеваний, выявленных на медосмотрах. Первичная заболеваемость психическими расстройствами среди работающих на ряде предприятий Минатома за последние годы возросла на 50 % . Это серьезная предпосылка к росту риска возникновения аварийных ситуаций по вине работников на особо опасных предприятиях. Снижается продолжительность профессиональной деятельности высоко профессионального персонала. У 80 % работников отмечается развитие вторичных иммунодефицитов, осложняющих течение профессиональных заболеваний. Распространенность врожденных аномалий среди детей в возрасте до 14 лет, проживающих в закрытых городах (ЗАТО) вдвое превышает показатель по России». (С. И. Лучич. «Популярные беседы по экологии». Челябинск, 2000, стр. 54.)

... Без, татарлар, Россия империясе тырнагында 450 ел яшәгән халык, аның ни дәрәҗәдә мәкерле һәм явыз икәнен бик яхшы беләбез. Бу илдә безнең һәр яшәгән көнебез - ул тормыш өчен көрәш, телебез, динебез, хокукларыбыз, ирегебез, сәламәтлегебез өчен бер дә бетми торган көрәш. «Маяк» җитештерү берләшмәсен дә, иң беренче булып, татарлар судка бирде, аның кешелек өчен нинди зур куркыныч тудыруы турында бөтен дөньяга хәбәр иттеләр. Менә бүген дә Россия хакимияте һәм «Маяк» берләшмәсе белән татарлар судлаша, татарлар үз хокукларын даулый, югалган сәламәтлекләре өчен империядән үх хакларын дәгъвә кыла. Хәзергә 5 татар хатыны, радиациядән зарар күрүләрен исбатлар һәм ликвидатор статусын кире кайтару өчен, судка мөрәҗәгать иттеләр, алга таба алар 50, 500 кеше булачак... Бер татарлар гына түгел, «Маяк» эшчәнле-

ге һәм радиация аркасында гомерлек чир алган, гарип булып туган, нәселсез калган меңнәр, миллионнар Россия хөкүмәте белән судлашачаклар әле. Хәзергә алар бишәү - ИСМӘГЫЙЛОВА ГӨЛЧӘҺРӘ, АБДРАХИМОВА ГАТИФӘ, СӘЙДУЛЛИНА МӘРЗИЯ, ГАЛИУЛЛИНА ГӨЛСӘЙРӘ, АБДУЛЛИНА ЗЕМФИРА. Аларның кайсы - 60та, кайсына әле 60 та юк, әмма барысы да рак авырулы. Бу хатын-кызлар барысы да Татар Караболагында туып-үсәләр, 1957 елгы «Маяк» шартлавыннан соң, радиация пычрагын җыештыруда катнашалар, шунда үзләренә гомерлек чир алалар. Язмыш аларны соңыннан шушы Озерский шәһәренә китерә, биредә эшләп, алар пенсиягә чыгалар. Моннан 5 ел элек алар судлашып, ликвидаторлык статусы алган булалар, әмма Чиләбе хакимияте бу авыру хатыннардан дәүләтнең шул ярдәм акчасын да кызгана һәм суд белән, аларның ликвидаторлык статусын юк итә. 5 ел буе бу татар хатыннары кайда гына язмыйлар, кемнәргә генә мөрәҗәгать итмиләр, әмма хакимият аларны бөтен җирдән куа, алар алдында бөтен ишекләрен ябып куя. Һәм алар, Татарстаннан меңнәрчә чакырым ераклыкта, Урал тау артында яшәгән татарлар, ярдәм сорап МИЛЛӘТКӘ, ТАТАР ХАЛКЫНА мөрәҗәгать итәләр, Татарстан Президентына һәм Бөтендөнья татар конгрессына хат язалар. Бу 5 татар хатыны артында бүген миллионлаган татар халкы, Татарстан торганлыгын Чиләбедә дә, судта да яхшы аңлап эш иттеләр. Хәер, без бу процессның сәяси юнәлештә булуын яшереп тә тормадык, ачыктан-ачык Россия хәкүмәтен татар халкына, татарларга каршы атом геноциды уздыруда гаепләдек.

## БӨТЕНДӨНЬЯ ТАТАР КОНГРЕССЫ ЮРИСТЫ, АДВОКАТ РОЗА ФӘРДИЕВАНЫҢ ОЗЕРСКИЙ ШӘҺӘР СУДЫНДА ЯСАГАН ЧЫГЫШЫ.

*(2003 ел, 30-31 июль):*

- Без биредә Бөтендөнья татар конгрессы исеменнән чыгыш ясыйбыз, татарлар кайда гына яшәсәләр дә, без аларга ярдәм итәргә тиешбез. Радиациядән зарар күргән Татар Караболагы халкы һәм Озерский шәһәрендә яшәүче татарлар, ярдәм сорап, безгә, Татарстанга мөрәҗәгать

иттеләр. Без берничә тапкыр килеп, бу мәсьәләне өйрәндек. Безнең тикшерүләр шуны күрсәтте - Татар Караболагы авылында күп кеше рактан авырый һәм үлә, бу исә турыдан-туры радиация белән бәйләнгән. Авылда хәзер дә радиация бик көчле. Әмма иң тетрәндергече шунда, кешеләргә, бигрәк тә, татарларга, үз вакытында дөресен әйтмиләр. Тирә-яктагы бөтен рус авылларын өч ай эчендә күчереп бетерәләр, ә татар авыллары, кешеләре белән бергә, шул радиацияле үле зонада калдырылганнар. Татар Караболагы авылы хәзер картада да юк, ул күчерелгән исәпләнә, әмма күчерелми. Безнең: «Бу татарлар өстендә атом тәҗрибәсе уздырганнар», дип әйтергә тулы хакыбыз бар. МОНЫ ТАТАР ХАЛКЫНА КАРАТА ГЕНОЦИД ДИП БӘЯЛӘРГӘ МӨМКИН. Менә бүген суд каршында утырган бу татарларны дәүләт бала вакытларында ук үзенең мәкерле максаты өчен файдалана. һәм аларны юк итә. Болар бит барысы да рак авырулы кешеләр. Өлкәнең социаль яклау комитеты, бу газап күргән кешеләрне яклыйсы урында, аларга карата җәза органына әйләнгән, ликвидаторларны юк итү юлына баскан. Без бу эшне зур гаделсезлек дип бәялибез һәм судтан радияциядән зарар күргән бу кешеләрне яклап хөкем чыгаруын сорыйбыз. Дәүләт алар алдында мең тапкыр бурычлы - аларның балачакларын, яшьлекләрен, сәламәтлекләрен, нәселләрен, хәтта гомерләрен дә юкка чыгарганы өчен. Бүген дәүләтнең үз хатасын аз гына булса да төзәтергә мөмкинлеге бар һәм мин ышанам, бүген суд бу кешеләрне яклап карар кабул итәр.

Һәм шулай булды да...

Озерский шәһәре судьясы Царькова Людмила Константиновна радиациядән зарар күргән 5 татар хатынын яклап, хөкем карары чыгарды. Күпләр бу карарны тыңлаганда, еладылар. Шушы нәтиҗәгә килү өчен еллар буе барган тигезсез көрәш, шушы юлларда күргән авырлыклар берсе дә юкка булмады. Иң мөһиме - бер генә мизгелгә булса да, империянең уртасында, атом аждаһасы авызында ДӨРЕСЛЕК ҖИНДЕ!!! Әлбәттә, бу суд карары белән дә бәхәсләшергә тырышып караучылар булыр, бәлки бу татарларга каршы тагы Чиләбе, Мәскәү аякка басар. Әмма без дә карап тормабыз, эш алайга китсә, Бөтендөнья татар кон-

грессы аша, халыкара судларга, дөнья җәмәгатьчелегенә мөрәҗәгать итәрбез! Татарларның ялгыз түгеллеген, берберләре өчен утка гына түгел, аждаһа авызына да керергә әзер торуларын без бар дөньяга исбат итәрбез. Шуны онытмасыннар - империя тарафыннан изелгән бу татарлар артында бүген, кыя булып, Татарстан Республикасы, миллионлаган татар халкы тора. Бу хәлләрне белгәннән соң, дөнья җәмәгатьчелеге дә атом корбаны булган татарларны яклар, иншаллаһ! Россия татарларга карата эшләгән 50 еллык геноциды өчен генә түгел, 500 еллык явызлыгы өчен дә җавап бирер әле...

Ә хәзергә - хуш атом шәһәре, дөньяның иң куркыныч һәм иң радиацияле пычрак урыны!

Хушыгыз, шушы аждаһа авызында яшәргә мәҗбүр булган милләттәшләрем!

Сезнең җәннәт кебек авылларыгызны, тәртипле татар тормышыгызны Россия империясе җәһәннәмгә әйләндерде. Сезнең бүгенге хәлегез бөтен дөнья өчен гыйбрәт булырга тиеш. Әгәр без бергәләп көрәшмибез икән, Россия бөтен дөньяны менә шулай атом казанына салып кайнатырга мөмкин. Әгәр шуңа ирек бирсәк. Бу язманы укыган һәр кеше үзен Мөслим, Татар Караболагы авылы татарлары урынына куеп карасын иде. Бу фаҗига, бу рак газаплары, вакытсыз үлем, гарип балалар, нәсел кору, тормыш агачы кору - иртәгә сезгә дә килергә мөмкин бит. Котырып корал җитештерү Россиянең бүген үз халкын кыра. МОҢА КЕМ ЧИК КУЯР?!

Озерский шәһәрен калдырып, урман-күлләр буйлап Екатеринбург-Чиләбе юлына чыгып киләбез. Бу тирәдәге матурлыктан күзгә яшьләр килә, табигатьнең бу хәтле кыргый гүзәллеген күреп, тын ала алмыйча торасың... Безне юл буе озата барган каен урманнары ниндидер зәңгәр нур белән, моң белән тулган... Зәңгәр күлләрдә күктәге ак болытлар чагыла, салмак кына тибрәлә... Ерактан, тантаналы дәһшәт белән, Урал таулары карап тора... Ул җиләк һәм чәчәкләрнең иге-чиге юк... Әйтерсең лә, бу җирләр җәннәтнең бер почмагы... Әмма син инде белеп торасың, бу җирләрнең астында - җәһәннәм. Бу җирләрнең астында - дистә чакырымнарга сузылган үлем индустриясе, «Маяк»

цехлары, миллиардлаган кюри атом калдыклары... Җәннәттәй бу җирләр астында - җәйрәп яткан атом диңгезе, ул инде һәр елны 80 метр тизлектә, Чиләбегә таба шуыша... Әнә, агачлар арасыннан, тырпаеп, «Маяк»ның кара торбалары йодрык селтәп кала... Карап торышка гына матур күренгән бу җирләр - дөньяның иң пычрак, радиациядән иң нык агуланган урыны. Биредән ерак түгел, металлургия үзәге булган Карабаш төтәп ята, аның җирендә хәтта инде үлән дә үсми, ул экологик бәла-казалы зонага кертелгән. Тиздән «Маяк» тирәсендәге җирләр дә шул хәлдә калырга мөмкин... Өлкәнең көньягындагы Магнитогорский шәһәрендә кыш көне кара кар ява, чөнки металлургия заводы төтене аны шундый хәлгә китерә... Чиләбе үзе дә, экология ягыннан, Россиядә иң пычрак шәһәрләрдән санала, чөнки шәһәр хәрби һәм метеллургия промышленносты газларыннан, төтеннән, радиоактив калдыклардан буыла. Бу хакта Чиләбе экологлары менә нәрсә яза:

*«По данным космических съемок, в Челябинской области суммарная площадь загрязнения тяжелыми металлами, радионуклидами и техногенными отходами 56 % всей территории области.» (С. И. Лучич. Популярные беседы по экологии. Челябинск, 2000, стр. 242.)*

Әйе, татарларның җәннәттәй борынгы җирләрен Россия империясе җәһәннәмгә әйләндерде. Моның өчен дә аңа әле җавап тотар вакыт җитәр, иншаллаһ!






# БИШЕНЧЕ БҮЛЕК

## Нәтиҗә – шуышучылар...

Әйе, атом эшчәнлегенең нәтиҗәсе - шуышучылар...

Мин аларны үз күзләрем белән барып күрдем. Чиләбе өлкәсендә радиация нәтиҗәсендә гарипләнгән, мутант балаларны тота торган ике махсус интернат бар, берсе - Чиләбедә, икенчесе Троицкий шәһәрендә. Мин Чиләбе шәһәрендәгесенә бардым. Биредә 4 яшьтән 18 яшькә кадәр 300дән артык бала тупланган, барысы да гарип, акылга җиңел, авыру. Алардан ата-аналары баш тарткан, чөнки, чыннан да, мондый авыруларны өйдә тоту мөмкин түгелдер. Өлкәдә гарип, авыру балалар саны арткannан-арта бара икән, шуңа күрә баланы бирегә урнаштыру өчен еллар буе чират торуларын әйтәләр.

Чиләбе шәһәренең 2нче номерлы балалар йорты җитәкчесе Олег Николаевич Блинков мине иң авыр хәлдә яткан балалар янына алып керде. Бу бүлек «шуышучылар» бүлеге дип атала, монда чын гарипләр, мутантлар, церебраль параличлы балалар ята. Араларында татарлар, башкортлар да бар. Бу күренеш - коточкыч. Монда хәтта тын да алып булмый, ачы ис бугазга ябыша... Сабый балалар өчен караватларда йөзләре саргаеп беткән 12-13 яшьлек үсмерләр ята... Аларның буйлары - ярты метр, аяк-кул урынына - ит кисәкләре... Әмма иң тетрәндергәне, иң имәнече - аларның йөзләре... Җыерчык баскан бу бала гарипләрнең йөзләре 70 яшьлек картларныкы кебек, азау тешләре сар-

гаеп, асылынып тора... Идәнгә төшерсәң, алар кортлар кебек, шуыша гына алалар, шуңа күрә бу балаларны «шуышучылар» дип йөртәләр... Алар арасында 16 яшькә җиткән гариплəр дə бар. Әйтик, Катя исемле кыз. Аның башы зур, үз яшенә туры килә. Гәүдәсе гарип, ярты гына метр, аяк-куллары урынына - ит кисәкләре... Әмма, ни фаҗига, Катя үз акылында, әнисен эзләтеп ята... Мин аның башыннан сыйпадым, «С Богом, Катя», дидем. Ул: «С Богом, с Богом!», дип җавап бирде... Ни фаҗига - ул һәр көн янәшәсендә шул корт-балаларны күрә, акылы белән үзенең кайда эләккәнен аңлый, әмма аяксыз-кулсыз, гәүдәсез килеш ул шулар арасында үләргә дучар ителүен дә белә... Шуңа күрә, тилмереп, әнисен эзләтә... Өлгерергә тырыша...

Церебраль параличлы балалар да гаять авыр тәэсир калдырды. Алар кәкерәеп, бөрешеп катканнар, карап торырга да куркыныч... Башка бүлекләрдәге балаларның да барысы да дип әйтерлек дивана, мутант, тиле. Врачларның әйтүенчә, бу балалар турыдан-туры атом радиациясенең ачы нәтиҗәсе. Радиация генетикага нык тәэсир итә, һәм, нәтиҗәдә, дөньяга гарипләр, ике башлы, балык койрыклы, җанварга охшаган балалар туа... Мин аларны күрдем дә, кешелекнең ахыры менә шулай аянычлы бетә икән, дип уйладым... Корт балалар, аяк астында шуышып, нидер мөгрәп, шыңшып калдылар... КЕШЕЛЕКНЕҢ АХЫРЫ ҖИРДӘ ШУЫШУ БЕЛӘН БЕТӘ ИКӘН... Болар барысы да - атом корбаннары бит...

Болары - туганнары... Ә ана карынында ук гарипләнеп, куркыныч төсләр алган, кара көеп каткан, үле туган балалар күпме? Болар да - атом корбаннары, радиация нәтиҗәсе бит! Кешелекнең, тумыйча ук, ана карынында ничек гарипләнеп үлгәнен күрәсегез килсә, «Маяк»тан ерак түгел урнашкан Аргаяш районына барыгыз. Медицина училищесында спиртлы савытларда үле туган гарип балаларның кипкән гәүдәләре саклана... Кайсының башы корсагына урнашкан, кайсы бер яки өч күзле, кайсының кул урынына - аяк... Аларның газаплары йөзләренә кара битлек булып ябышкан, гәүдәләре дөнья йөген күтәреп торган кебек, кәкрәеп каткан... Болар да бит, кеше кебек тусалар, кемнәрнеңдер бәхетле балалары булырлар иде, ә хәзер әнә,

пыяла савытка гарип йөзләрен терәп, кешелеккә мәңгелек каргышларын юллыйлар... АТОМ ПРОМЫШЛЕННОСТЫНЫҢ, «МАЯК»НЫҢ, АШКЫНЫП КОРАЛ ҖИТЕШТЕРҮНЕҢ ТӨП НӘТИҖӘСЕ МЕНӘ ШУШЫ — ПЫЯЛА САВЫТ ЭЧЕНДӘГЕ ГАРИПЛӘНДЕРЕЛГӘН КЕШЕЛЕК...

# СОҢГЫ СҮЗ

Чиләбе өлкәсенең Коншак районында радиациядән зарар күргән татар авылларының, татарларның тормышын якыннан өйрәнгәннән соң, шундый фикергә киленде:

1. Россия дәүләтенең 1948 елдан башлап, бүгенге көнгә хәтле татарларны радиацияле үле зонада тотуы ТАТАР ХАЛКЫНА КАРАТА УЗДЫРЫЛГАН ГЕНОЦИД, дип бәяләнергә хаклы. Бу бәя халыкара хокук нормаларына да туры килә, чөнки дәүләт татарларны белә торып, шул радиацияле шартларда яшәргә, ягъни, үләргә калдырган. Бу төбәктә яшәүче татарларның радиация нәтиҗәләре сәбәпле нәселләре кору да геноцидның бер билгесе булып тора. Шушыларга нигезләп һәм Берләшкән Милләтләр Оешмасының Конвенциясенә таянып, Россия Федерациясе татарларга каршы уздырылган геноциды өчен Халыкара Судка бирелергә тиешле.

### «КОНВЕНЦИЯ ООН О ПРЕДУПРЕЖДЕНИИ ПРЕСТУПЛЕНИЯ ГЕНОЦИДА И НАКАЗАНИЯ ЗА НЕГО»:

Статья 2.

В настоящей Конвенции под геноцидом понимаются следующие действия, совершаемые с намерением уничтожать, полностью или частично, какую-либо национальную, этническую, расовую или религиозную группу, как таковую:

а) убийство членов такой группы;

б) причинение серьезных телесных повреждений или умственного расстройства членам такой группы;

с) предумышленное создание для какой-либо группы таких жизненных условий, которые рассчитаны на полное или частичное физическое уничтожение ее;

д) меры, рассчитанные на предотвращение деторождения в среде такой группы;

е) насильственная передача детей из одной человеческой группы в другую.

(Принята в 1948г. Вступила в силу в 1951г.)

**2.** «Маяк» җитештерү берләшмәсе бүгенге көндә бөтен кешелек өчен куркыныч чыганагы булып тора. Бүгенге көндә анда бөтен җир шарын бер мизгелдә юк итәрлек 1 миллиард кюри атом калдыклары саклана. Шуңа карамастан, бирегә чит илләрдән атом калдыклары кертү башланды. «Маяк»та атом рекактолары бар көченә эшләвен дәвам итә, шул территориядә атом электорстанциясе төзү бара. Шулай итеп, бу төбәк өчен генә түгел, бөтен кешелек өчен «Маяк»ның потенциаль куркынычы арта бара. Югарыда әйтелгәннәрдән чыгып, шундый фикергә киленде:

- «Маяк» атом берләшмәсе эшләп торганда, биредә беркайчан да иминлек булмаячак. Атом радиациясе тәэсирендә меңләгән, миллионлаган кеше рактан, башка чирләрдән кырылачак, табигатькә төзәтә алмаслык зарар киләчәк, ул кара күмергә әйләнеп калачак. Димәк, кешеләр һәм табигать язмышы турында уйлыйбыз икән, АЛГА ТАБА «МАЯК» ҮЗЕНЕҢ ЭШЧӘНЛЕГЕН ТУКТАТЫРГА ТИЕШ. Я - атом берләшмәсе «Маяк», я - кешеләр һәм табигать. Мәсьәлә бары тик шулай гына куелырга мөмкин.

«Маяк» һәм ул урнашкан җирлек «Зона экологических бедствий» дип игълан ителергә тиеш. Анда һәр төрле атом, химия, бактериология коралы белән бәйле булган төзелешләр, шул исәптән, Көньяк Урал атом электростанциясе төзелеше дә кичекмәстән туктатылырга тиеш.

**3.** «Маяк» берләшмәсе эшчәнлегеннән зыян күргән кешеләрне, бигрәк тә, югарыда сүз барган Мөслим, Татар Караболагы, Усть-Багаряк авылы халкын, 50 ел буе үле зонада яшәүләрен искә алып, бернинди судларсыз, РАДИАЦИЯДӘН ЗАРАР КҮРГӘН, дип танырга, аларның хокукларын чернобыльчеләр белән тигезләргә һәм дәүләт тарафыннан бөтен ярдәмне дә күрсәтергә.

**4.** Күчәргә теләүчеләрне бу радиацияле зонадан үзләре теләгән чиста җиргә күчерергә, кешеләргә алга таба яшәү

өчен бөтен шартларын тудырырга. Күчү-күчмәү мәсьәләсен бары тик җирле халыкның үзе белән генә хәл итәргә, бернинди көчләү чаралары кулланмаска. Күчкән очракта кешеләрнең льгота-статусларына кагылмаска.

Россия менә шуларны эшли алырмы? Яки үҗәтләнеп, бөтен нәрсәдән дәүләт сере ясап, кешеләр өстендә атом тәҗрибәсе үткәрүен дәвам итәрме? Без бу мәсьәләгә дөнья җәмәгатьчелегенең дә катнашуын, үз сүзен әйтүен һәм ярдәм итүен көтәбез...

Татар халкына карата игълан ителмәгән сугыш бер Чиләбе өлкәсендә генә алып барылмый. Бүгенге көндә татарлар яшәгән бик күп урыннарда - Чиләбе, Курган, Свердловский, Ырынбур, Саратов, Ульян өлкәләрендә, Татарстанда, Башкортстанда, Удмуртиядә атом-төш коралы, радиация, химик һәм бактериологик корал белән бәйле бик күп урыннар бар. Бу тирәдә яшәүчеләр күпләп рак авыруыннан кырыла, биредә яшәүчеләрнең уртача гомер озынлыгы 57 яшьтән узмый, халыкның чир-зәхмәтләрдән башы чыкмый. ТАРИХИ ТАТАР ҖИРЛӘРЕНДӘ ТАТАР ХАЛКЫНЫҢ ГЕНОФОНДЫ ЮК ИТЕЛӘ. Безне, төрки-татарларны, үз туган җиребездә, үз йортыбызда бөтен яктан атом афәте чорнап алган. Без XXI гасырда барыбыз да Россия империясенең атом корбаннары булырга мөмкинбез...

САК БУЛЫГЫЗ, КЕШЕЛӘР!

САК БУЛ, КЕШЕЛЕК!!!

Безгә каршы игълан ителмәгән атом сугышы дәвам итә...

ГАЛИМНӘР ФИКЕРЕ:

«НА ДЕСЯТЬ ПОКОЛЕНИЙ ВПЕРЕД РОССИИ УГОТОВАНА РОЛЬ МИРОВОЙ ЯДЕРНОЙ СВАЛКИ, НА ЕЕ ТЕРРИТОРИИ БУДУТ РАЗМЕЩЕНЫ ДЕСЯТКИ ТЫСЯЧ ТОНН НЕНУЖНЫХ ЯДЕРНЫХ МАТЕРИАЛОВ... КО ВСЕМ ИЗВЕСТНЫМ БЕДАМ РОССИИ ДОБАВЛЕН РАСТЯНУТЫЙ НА СТОЛЕТИЯ РАДИАЦИОННЫЙ ГЕНОЦИД».

Сүз бит безнең җирләребез, безнең киләчәгебез турында бара... Безнең гомеребез, сәламәтлегебез, тормышыбыз турында бара...

Һәм без бергәләп, бу атом афәтенә каршы торырга тиешбез. Кешелек өстенә ажгырып килгән АТОМ АЖДАҺАСЫН ТУКТАТЫРГА ТИЕШБЕЗ... Юкса, УЛ безне туктатырга мөмкин... Моның ачы мисалы итеп без сезгә Мөслим һәм Татар Караболагы авылы кешеләренең фаҗигале язмышын күрсәттек... Мондый язмыш башка беркемгә дә насыйп булмасын иде...

*2003 ел,*
*май—август айлары.*

Бөтендөнья татар конгрессыннан Чиләбе өлкәсенә барып, радиациядән зарар күргән татарларның тормышын өйрәнгән төркем:

1. ФӘҮЗИЯ БӘЙРӘМОВА — язучы, Бөтендөнья татар конгрессы башкарма комитеты әгъзасы;
2. ҖӘМИЛ САФИУЛЛИН — юрист, Бөтендөнья татар конгрессының кеше хокукларын яклау комитеты әгъзасы;
3. РОЗА ФӘРДИЕВА — адвокат, Бөтендөнья татар конгрессы юристы;
4. ГӨЛНАЗ ХӨСНЕТДИНОВА — юрист;
5. АЛЬБЕРТ ГАРАПОВ — галим-эколог, Татарстанның атом-төш коралына каршылык оешмасы рәисе;
6. ФИРДҮС ГЫЙМАЛЕТДИНОВ — журналист, «Татарстан — яңа гасыр» телевидениесе хезмәткәре;
7. СЕРГЕЙ КУЗЬМИН— телеоператор, «Татарстан — яңа гасыр» телевидениесе хезмәткәре.



# КИТАПНЫ ЯЗГАНДА ФАЙДАЛАНЫЛГАН ХЕЗМӘТ:


1. Абсалямова Мунира. Укрощение монстра. Казань, 2001.

2. Атомная Арктика. Проблемы и решения. Мурманск, 2001.

3. Бәйрәмова Фәүзия. Дәверләр күчешендә. Әлмәт, 1998.

4. Джей М. Гульд, Бенджамин А. Голдман. Смертельный обман. Москва, 2001.

5. Источники радиационного загрязнения р. Теча и района расположения ПО «Маяк», Урал, Россия. Норвегия, 2000.

6. Кузнецов В. М. Ядерная безопастность. Москва, 2003.

7. Кунашак — земля предков. Челябинск, 2000.

8. Ларин Владислав. Комбинат «Маяк» — проблемы на века. Москва, 2001.

9. Лучич С. И. Популярные беседы по экологии. Челябинск, 2000.

10. На путях к духовно-экологической цивилизации. Казань, 1996.

11. Новоселов В., Толстиков В. Тайна «сороковки». Екатеринбург, 1995.

12. О близком нам крае замолвим мы слово. Челябинск, 2002.

13. Они превращают Россию в Международную ядерную свалку. Москва, 2001.

14. Петрушина Н. П. Здоровье потомком работников предприятия атомной промышленности — производственного объединения «Маяк». Москва, 1998.

15. Сивинцев Ю. В. Ядерная энергетика и экология. Москва, 1976.

16. Сохина Л. П., Колотинский Я. И., Халтурин Г. В. Плутоний в девичьих руках. Екатеринбург, 2003.

17. Тихонов Александр. Муслюмово — деревня на ядерной свалке. Челябинск, 1995.

18. Тритий — это опасно. Челябинск, 2001.

19. Это не жизнь! Жизнь, отравленная радиоактивными отходами. Гринпис, 2002.

20. Южно-Ураьская атомная — быть или не быть? Резонанс. Челябинск, 1991.

21. Ядерное оружие: мощный рывок к нулю. Новосибирск, 2002.

22. Якубовский В. Л., Нагибин В. И., Суслин В. П. Семипалатинский ядерный полигон — 50 лет. Новосибирск, 1998.






# СОДЕРЖАНИЕ:

**Глава первая.** Индустрия смерти ........................................4
**Глава вторая.** На ядерном архипелаге ..............................23
Татары, меченые атомом. ............................31
**Глава третья.** Жертвы атома ...........................................74
**Глава четвёртая.** В пасти дракона ..............................136
**Глава пятая.** Результат — ползучие ...........................156
**Заключительное слово** ..................................................159
**Использованная литература** ........................................163

# ЭЧТӘЛЕК:

**Беренче бүлек.** Үлем индустриясе ................................165
**Икенче бүлек.** Атом атавында .......................................181
Атом тамгалы татарлар ..............................188
**Өченче бүлек.** Атом корбаннары ....................................227
**Дүртенче бүлек.** Аждаһа авызында ..............................278
**Бишенче бүлек.** Нәтиҗә — шуышучылар .........................295
**Соңгы сүз** .........................................................................297
**Файдаланылган хезмәт** ..................................................301

Байрамова Фаузия Аухадиевна

# ЯДЕРНЫЙ АРХИПЕЛАГ
## или атомный геноцид против татар

# АТОМ АТАВЫНДА
## яки татарларга каршы атом геноциды


Научно-популярное издание
*(на русском и татарском языках)*

Ответственный за подготовку книги в печать
и издатель: ***Ж. С. Сафиуллин.***

Перевод с татарского: *Т. Бариев, М. Сафин*
Дизайн обложки и вёрстка: *Р. Ахияров*

Сдано в набор: 10.12.04 г.
Оригинал-макет подписан в печать: 12.01.05 г.
Печать офсетная. Шрифтовая гарнитура Tatschoolbook,
Формат 60х90 $^1/_{16}$. Бумага офсетная № 1.
Печатных листов 19.

Тираж 2000 экз. Заказ_______

Лицензия на полиграфическую деятельность
ПД № 01207 от 30.08.2001 г.

Отпечатано в типографии ГУП ПИК «Идел-Пресс»
420066, г. Казань, ул. Декабристов, 2.